ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№05 (376)
МАЙ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

KAZANFORUM-2023: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ

+7 (843) 225-22-33
poseydom.ru
info@poseydom1.ru

ПОСЕЙDOM

ТОРМЫШНЫ СӘНГАТЬКӘ ӘЙЛӘНДЕРГӘН ЙОРТЛАР ТӨЗИБЕЗ

Ландшафтына дизайн ясалган уңайлы территория, барбекю зонасы һәм балалар мәйданчыгы, күршеләрнең юклыгы, һавада күбрәк вакыт үткәрү мөмкинлеге – болар барысы да, һичшиксез, үз йорты белән яшәргә хыялланучыларны җәлеп итә. Ләкин мәсьәләнең башка ягы да бар. Шәһәр читендә йорт төзү билгеле бер белем-күнекмәләр һәм тәҗрибә таләп итә: эшне нидән башларга, нинди эзлеклелектә алып барырга, этапларны ничек бутамаска – болар исәпкә алынырга тиешле нәрсәләрнең бик аз өлеше генә. Ләкин мәсьәләне хәл итү юлы бар – эшне профессионалларга тапшыру.

Никита Глушков,
«ПосейДом» компаниясенең генераль директоры

225 төзелгән йорт

7 еллык тәҗрибә

Төзелеш эшләренең барлык төрләренә кимендә 5 ел гарантия

Төзелеш барышын онлайн-режимда видеокүзәтү

Юридик эшләрдә тулы ярдәм

«ПосейДОМ» төзелеш компаниясе идеаль йортның нинди булырга тиешлеген төгәл белә.

Җылы һәм уңайлы, чыдам һәм ышанычлы, уйлап һәм заманча технологияләр кулланып эшләнгән – мондый йорт хыялдан да яхшырак булачак.

Үз проектыгыз бармы? Җир кишәрлеге сайлау һәм ипотекага рөхсәт алудан башлап, йорт төзү һәм ландшафт дизайнына кадәр - теләсә кайсы идеягезне тормышка ашырырга булышачакбыз.

Яисә әзер өйләргә өстенлек бирәсезме? Безнең йортларда һәр деталь җентекләп уйланылган: аларда – панорамалы тәрәзәләр, бүлмәләрнең уңайлы иркен бүленеше, беркайчан да актуальлеген югалтмаячак заманча архитектура.

Ә бәлки сез күптәннән үз участогыгызны яшелләндерү теләге белән янып йөрисездер? Без 3D-визуальләштерү һәм техник планнарның тулы җыелмасы булган ландшафт проектын әзерләп кенә калмыйча, ул проектны ахыргача гамәлгә ашырачакбыз һәм бакчагызны карап-тәрбияләп торуны да үз өстебезгә алачакбыз.

Безгә кешеләрне бәхетле итү ошый.

Ә эшнең сыйфатлы нәтиҗәсе өчен генә түгел, үз финансларың өчен дә күңелең тыныч булу бәхет түгелме?

Бәяләр килешү имзалаган вакытта теркәп куела һәм, эшләр тулысынча тәмамлаганчы, үзгәрешсез кала. Моннан тыш, шәхси менеджерыгыз һәрвакыт теләсә нинди мәсьәлә буенча киңәшләр бирергә, профильле белгечләр белән очрашу оештырырга һәм төзелеш барышы турында тулы мәгълүмат җиткерергә әзер.

Быел эшләргә мөмкин булганны киләсе елга калдырмагыз.

Консультациягә язылыгыз һәм хыялыгызга таба бер адым ясагыз!

ТӨП ПАРТНЕРЫБЫЗ DUPLEX INTERIOR & LIGHTING DESIGN

8-800-770-79-53
duplexapartment.ru, zakaz@dpxap.ru

ДЮПЛЕКС ИНТЕРЬЕР ҺӘМ ЯКТЫЛЫК ДИЗАЙНЫ СТУДИЯСЕ:

- Коммерциячел һәм торак бина интерьерларының дизайн-проектларын эшләү
- Яктылык дизайны
- Комплектлаштыру һәм эш барышын контрольдә тоту
- Архитектурасын проектлау

Фотолар: «ПосейДом» компаниясе матбугат хезмәте. Реклама

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур.,
2 тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррире: Руфия Фазылова, Николай Коновалов
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Заһидуллин,
Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Рамил Гали
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: җәмәгать киңлекләре өчен шәһәр җиһазлары
һәм җайланмалары җитештерү буенча SIGN URBAN
компаниясенә нигез салучы Ләйлә Сафина
Фотога төшү урыны: Казан Кремленең Кабул итү урыннары
Оештыручысы: Wonderpeoplegroup

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–1167
Басарга кул куелды: 19.05.2023
Басмадан чыкты: 25.05.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

КАЗАН КУНАКЛАР КАБУЛ ИТӘ

Казан ундүртенче мәртәбә «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum–2023» Халыкара икътисадый форумын кабул итә. Форум Россия Президенты Владимир Путин карары белән федераль статус алды.

Быелгы форум кай ягы белән гаҗәпләндерәчәк соң?

«Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә Russia Halal Expo традицион күргәзмәсен агросәнәгать паркында оештырылачак Russia Halal Market ярминкәсе һәм ислам илләре аш-су осталарының бәйрәме тулыландырачак. Һәр кунак хәләл-индустрия дөньясына караган чараларда эксперт буларак та, сатып алучы, тамашачы сыйфатында да катнаша ала.

KazanForum Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкләгән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең нәтиҗәле икътисадый коралы булып тора. Аның сүзләренә караганда, «соңгы елларда һәм айлардагы төрле глобаль үзгәрешләр ислам икътисадына тискәре йогынты ясамый кала алмый. Әмма хәләл куллану чыгымнары, инвестицияләр һәм ислам финанс инструментларының үсеше фаразлана. KazanForum ислам дөньясына мөселман халкы яшәгән Россия төбәкләренең киң мөмкинлекләрен күрсәтәчәк».

2023 елгы форумда бүгенге көн бизнесында хатын-кызның үсә барган роленә аерым игътибар бирелә. «Хатын-кыз карашы» трегы кысаларында хәйриячелек, шәригать стандартлары буенча матурлык һәм сәламәтлек, гаилә һәм бизнес темаларына кагылышлы сессияләр оештырылачак. Моннан тыш, форумда Halal business women һәм Halal charity women премияләренең презентациясе узачак. Алар бизнес-мохиттә хатын-кызларның ролен, статусын, абруен күтәрү һәм ярдәм итү максатыннан гамәлгә куела.

KazanForum–2023 форумын хатын-кызлар өчен бик күңелле чара – Modest Fashion Day мода фестивален тәмамлаячак. Ул стиль, мәдәният, сәясәттән тыш, традицион кыйммәтләрне, дини карашларны берләштерүгә йөз тота.

Сезнең редакция.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 102 яшь

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик татарстанда


НАГРАДНОЙ ЛИСТ

БЕРЛИННЫ АЛГАН БАТЫР

Тарихи яктан расланган факт: штурмга өч көн кала, Берлинга беренче булып Гарәпша Шаһимәрдановның танкы бәреп керә. Густаф-Адольф штрасседа ул танкка каршы ата торган өч тупны һәм иллегә якын фашистны юк итә. Немец башкаласына капитан Шаһимәрданов тарафыннан оештырылган кыю разведканы хәрби җитәкчелек күрми калмый. 1945 елның 5 маенда танк бригадасы командиры Гарәпша Шаһимәрдановка Советлар Союзы Герое исемен бирү турындагы бүләкләү кәгазенә кул куя. Шаһимәрдановның бүләкләү кәгазендә санап үтелгән батырлыклары, һичшиксез, мондый олы бүләккә лаек була. Әлеге тарихи рейдтан соң Гарәпша тагын ике мәртәбә кыюлык күрсәтә: 1 май көнне Берлинерштрасседагы кичү өчен сугышта дошманның алты тубын һәм 95 солдат һәм офицерын юк итә. Шаһимәрдановка Герой исеме бирү турындагы документны 2 нче гвардия танк армиясе командующие һәм армия Хәрби советы әгъзасы раслый. Әмма... капитан Гарәпша Шаһимәрдановны I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләклиләр. Герой исемен бирмәс өчен, «югарыда» нинди саллы сәбәпләр тапканнардыр, анысы – табышмак. Шулай да 1941 елның 5 ноябрендә Саба районыннан үз теләге белән фронтка киткән тарих укытучысы Гарәпша Шаһимәрдановка бәхетле язмыш насыйп була: ул туган ягына исән-сау әйләнеп кайта.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

8. Гаделлек, хезмәттәшлек һәм рибачылыкны тыю
Ислам банкингы принциплары безнең тормышка ничек үтеп керә

10. Җылы урын. Инвестор сайлый
Кем ташламалардан файдаланып, уңышка ирешә

14. Дөньякүләм эпос
«Туган батыр» ни рәвешле әкият дөньясы белән чынбарлык арасында тәрәзә ача

18. Оксфорд инде трендта түгел
Ни өчен чит ил яшьләре Татарстанга укырга килә

24. Ислам дөньясының IT-башкаласы
Безне хәләл-индустрия статисты роле генә канәгатьләндерәме

34. Форумга хатын-кыз карашы
Гүзәл затларга кагылышлы чаралар

игелекле эшләр

48. Дөньяда иң шәп урын
Татарстанның иң матур районнарының берсе ничек яши

54. Гомерлеккә – гранитта
Мич табасына һәйкәл кайда пәйда булачак

58. Заманча киез итек
Кукмарада елына күпме итек басалар

66. Авылда кунакта
Тал чыбыгыннан кәрзин үрү серләре

мәңгелек кыйммәтләр

77. Милләттәшләребез
Казаннан Сембергә сәяхәт

82. Тарихи сәхифәләр
Тирән тамырларны барлаучы

90. Татарстан авыллары
Борынгы Яңа Тинчәле

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: kremnik.ru

Акыллы гамәлләр

29.04

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – «2024 елда Казанда «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турниры башланырга 300 көн кала» кирегә санау стеласын ачу тантанасында катнашучыларга аталган видеомөрәҗәгатендә:

– Без мондый ярышларның нәкъ менә Россиядә уйлап табылуы, тиз арада популярлык яулавы, мавыктыргыч функциональ-цифрлы спортның илебездә яңа мөмкинлекләр, киңлек һәм перспективалар алуы белән горурланабыз. «Киләчәк уеннарын» оештыручылар моның өчен барлык шартларны, өстәвенә иң югары дәрәҗәдәге шартларны тәэмин итәчәк, чөнки сезне Россиянең иң үзенчәлекле төбәкләреннән берсе – Татарстан башкаласы кабул итә. Зур, абруйлы халыкара форумнар үткәрүдә бай тәҗрибәгә ия матур, борынгы, кунакчыл Казан көтә.

Игелекле эшләр

28.04

Марат Хөснуллин, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XIV халыкара икътисадый форумының оештыру комитеты рәисе, – Казанда, оештыру комитеты утырышында:

– Ил Президенты Владимир Путин, Россия һәрвакыт мөселман дөньясы белән хезмәттәшлекне киңәйтәчәк һәм тирәнәйтәчәк дип, күп тапкырлар билгеләп үтте. Безнең илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда төп рольне KazanForum уйнарга тиеш, ул быелдан федераль дәрәҗәдә үткәрелә.

Мәңгелек кыйммәтләр

26.04

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – Туган тел көне һәм Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулу уңаеннан мөрәҗәгатендә:

– Тукай иҗаты – милли үзенчәлекләребез кыйммәтен тану һәм Ватаныбызда яшәгән башка халыклар белән туганлык идеяләренең, гореф-гадәтләргә тугрылык һәм заманча яңа казанышларга омтылышның тыгыз үрелү үрнәге. Тукай күтәргән мәсьәләләр күпмилләтле Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының рухи хәзинәләребезне саклау һәм үстерү, борынгы традицияләребезне тергезү, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасын тагын да баету кебек максатларына аваздаш.

Фото: tatar-inform, ТР Рәисе матбугат хезмәте, kremlin.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр /

мәңгелек кыйммәтләр /

ТӨП ТЕМА

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ислам банкингы принциплары безнең тормышка **ничек** үтеп керә

Татарстан инвесторлары җылы урынны **кайда** таба

«Туган батыр» **ни рәвешле** әкият дөньясы белән чынбарлык арасында тәрәзә ача

Ни өчен чит ил яшьләре Татарстан вузларын сайлый

Хәләл **ничек** тормыш рәвешенә әверелә

KazanForum-2023 форумында **нинди** хатын-кыз темалары күтәрелә

ИСЛАМ БАНКИНГЫ: РИБАЧЫЛЫККА – ЮК, ЯШӘСЕН ГАДЕЛ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК!

Әхмәт Шакиров

Россиядә күпме еллар бәхәсләр уятып килгән ислам банкингы принциплары һәм ислам финанс инструментларына, күрәсең, юл ачылачак. Ислам финансларын үстерүгә юнәлдерелгән закон проекты РФ Дәүләт Думасында беренче укылышны узды. Дүрт пилот төбәктә (Башкортостан, Дагыстан, Татарстан һәм Чечен Республикасы) ислам банкингын гамәлгә кертү буенча эксперимент башлана. Рибачылыкка һәм коллекторларга юл куелмаган, бары тик ике якның да гадел хезмәттәшлеге һәм үзара ышанычы гына күздә тотылган ислам банкингын гамәлгә кертү буенча... Безнең җәмгыять намуслы хезмәттәшлеккә әзерме?

Бөтен җәмгыять өчен җавап бирә алмыйм, әмма инде шактый кеше бизнеста һәм көнкүрештә мөселман кануннары нигезендә яши: тормыш закон чыгарудан алдарак атлый. Әлбәттә, ислам финанс инструментларына да ихтыяҗ бар. Ихтыяҗ булгач, тәкъдим дә туа: ислам банкингы элементлары илебездә күптәннән кулланыла башлады. Әле ул чакта Россия Федерациясендә ислам бинкингын финанс партнерлык оешмалары үстерәчәк, ә базарны Россия Банкы көйләячәк, дигән карар кабул ителмәгән иде. Россия Банкына компанияләр реестрын алып бару һәм күзәтчелек итү йөкләнә.

Татарстанда яңа юнәлеш пионерларының берсе – «Жилищные Традиции» торак кооперативы. Ул инде биш еллап республикада торак сатып алганда хәләл бүлеп түләү, ягъ-

Фото: tatar-inform.ru

ни рассрочка тәкъдим итә. Шәригать кануннары нигезендә формалаштырылган берничә финанс продуктын Ак Барс Банк та куллана. Бер ел элек «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit - 2022» икътисадый саммитында банк җәмәгатьчелеккә үзенең ислам дебет картасын тәкъдим иткән иде.

КЭШБЕКМЫ? ОНЫТЫГЫЗ

Ислам дебет картасы идеясе дә банк аналитиклары кабинетларында тумаган. Ул клиентлар, дөресрәге аларның күпсанлы сорауларына таянып пәйда булды, дип белдерде картаны тәкъдим итү вакытында Ак Барс Банк идарәсе рәисе урынбасары Алексей Акимов. Аның сүзләренә караганда, картаның әлеге базар өчен уникаль саналган берничә үзенчәлеге бар. Хәләл акчаны хәләл булмаганнары белән кушарга ярамаганлыктан, клиентларның картадагы акчалары аерым исәп-хисап счетында саклана. Картада калган акчаларга процентлар өстәлми, мондый карта белән шәригать нормаларына туры килгән товар һәм хезмәтләр өчен генә түләргә мөмкин. Дебет картасы Ислам финанс учреждениеләрендә исәп-хисап һәм аудит оешмасы стандартлары буенча эшләнгән һәм тулысынча шәригать кануннарына туры килә.

Шуңа күрә счеттагы акча диндә рөхсәт ителмәгән эшчәнлекне финанслау өчен тотылмый. Сез картаны тыелган өлкәләргә карамаган теләсә кайсы кибеттә, учреждениедә һәм интернетта сатып алу өчен куллана алырсыз. Төнге клубларда, паб һәм барларда, башка күңел ачу урыннарында, алкоголь һәм тәмәке кибетләрендә, уен йортларында, ломбард һәм микрокредит оешмаларында ислам картасы белән түләп булмый.

Банк сәүдә ноктасының МСС-кодын тикшереп тора, шушы юл белән хәрам товар һәм хезмәтләр өчен түләттерми. Әлбәттә, сатып алуның ислам принципларына туры киләме, түләргәме-юкмы икәнлеген клиент үзе дә хәл итә. Мәсәлән, гипермаркетларда, анда хәләл товарлар гына сатылмый бит. Шуңа күрә, карта дини канунңарны бозмаска ярдәм итсә дә, тулысынча мондый ялгышлардан саклый алмый.

Россиядә әлегә бердәнбер ислам картасы «Мир» түләү системасы базасында эшли. Аңа ихтыяҗ зурмы соң? Банкирлар мондый картага ихтыяҗ бар, дип белдерә, ләкин төгәл саннарны атамый.

КОЛЛЕКТОРЛАР БОРЧЫМАС

Берничә ел элек Ольга Т. фатир сатып алырга уйлый. Акчасы беренчел кертемгә генә җиткәнгә, гадәти ипотеканы күздә тотып эш итә. Ләкин шул чакта төзүче яхшы вариант тәкъдим итә: фатир бераз кыйммәтрәк торачак, әмма акчаны процентсыз, бүлеп түләргә мөмкин.

– Әлбәттә, мин бүлеп түләүне сайладым, – ди Ольга Сергеевна. – Шулай җайлырак булыр кебек тоелды, ай саен түләү күләме дә гаилә өчен уңайлырак иде. Беренче ике ел шулай булды да... Шуннан соң фатирым ай саен даярлек кыйммәтләнә башлады, димәк ки, айлык түләү дә артты. Шулай дәвам итсә, бурычка батасыбыз көн кебек ачык иде.

Ольгага ашыгыч рәвештә банктан кредит алырга туры килә. Алда аны «якты» киләчәк көтә: процентлар өстәлгән түләүләр – ике дистә ел дәвамында...

Шуңа күрә Ольга, әйтик, фатирын ислам канунңары буенча рәсмиләштерелгән акчага алган булса, аңа хәзер процентлар түләргә дә, мондый стресс кичерергә дә туры килмәс иде. Ләкин эш шунда: банклар портфелендә мондый финанс продуктлары бармы соң?

Базар тәкъдимнәрен өйрәнү нигезендә шуны әйтергә була: әйе, бар. Аерым алганда, ислам дебет картасы барлыкка килгәнче ике ел элек, базарга шәригать нормалары буенча күчемсез милек сатып алу программасы чыга. Аны шулай ук Ак Барс Банк эшләгән. Чынлыкта, программалар ике. Берсенчесе «Мегаполис – Исламская ипотека» дип атала, ул күпфатирлы йортларда фатир алырга җыенучыларга йөз тота. Икенчесе, «Комфорт - Исламская ипотека» дигәне, аерым җир кишәрлеге генә яисә кишәрлеге булган йорт сатып алырга теләүчеләр өчен.

Ислам ипотекасы традиционыннан нәрсә белән аерыла соң? Ислам ипотекасы - билгеле бер өстәмә хак белән күчемсез милекне рассрочкага алу. Ул килешү срогына, беренчел кертем күләменә һәм башка күрсәткечләргә бәйле. Игътибар: объектның бәясе бөтен срокка теркәлә һәм үзгәрә алмый,

Рамил Батыршин,
«Жилищные Традиции» ТК проекты координаторы:

– Торак сатып алуның ислам инструментларына ихтыяҗ арта бара. Иң киң таралган контрактларның берсе – «мурабаха». Ул финанс учреждениесенә клиент өчен күчемсез милек объектын сатып алырга һәм соңыннан аңа бу объектны бүлеп түләү юлы белән сатарга мөмкинлек бирә. Торакны шәригать нормалары буенча бүлеп түләү юлы белән сатып алырга мөмкинлек бирә торган тагын бер контрактка игътибар итегез. «Кими баручы мушарака» дип аталган килешү буенча клиент үз квадрат метрларын базар бәясе буенча өлешләп сатып ала. Татарстанда әлеге продукт кооператив модель базасында тормышка ашырылды. Аның уникальлеге шунда: килешү финанс арадашчысыннан башка уза, катнашучы белән элемтә үзара ярдәм кассасы принцибына нигезләнеп корыла. Тәҗрибәдән чыгып, шуны әйтә алам: чын партнерлык принцибына нигезләнгән эшчәнлек кулланучыга да, бизнес ягына да шатлык китерә. 2018 елдан башлап, бүлеп түләү программасыннан 900дән артык гаилә файдаланды, 2,3 млрд сумлык килешү төзелде. Әгәр партнерлык программасын тирәнрәк өйрәнеп, аны дөрес итеп кулланган очракта, ул РФ икътисадының иң куәтле драйверларының берсенә әверелергә мөмкин, дип әйтә алам.

бүлеп түләүләр дә тигез өлешләр белән килешү срогына туры китереп башкарыла. Моннан тыш, клиенттан комиссия, штраф һәм пенялар алынмый.

Әгәр финанс учреждениесе клиенттан бернинди процент алмый икән, аңа нинди файда кала? Күчемсез милекне сатканда салынган әлеге дә баягы өстәмә хактан. Аның күләмен булачак йорт яки фатир хуҗасы банк сайтында үзе үк исәпләп чыгара ала, ул беренчел кертемнең күләменә һәм бүлеп түләү срогына бәйле.

Ипотека продукты шартлары буенча, беренчел кертем 20 дән 80% ка кадәр булырга мөмкин, бүлеп түләү срогы – 1 елдан 30 елга кадәр. Килешүнең иң кечкенә суммасы – 500 мең сум.

Ислам ипотекасы кирәкле продукт, дилер банкта. 2019 елда старт алган ислам ипотекасы ике ел эчендә сатуларын биш мәртәбәгә үстергән. 2021 елда ислам ипотекасы бирү күләме, 2020 ел белән чагыштырганда, 6 тапкырга арткан, шул ук вакытта продуктның географиясе Татарстан белән генә чикләнгән булган. Шуңа бәйле рәвештә банк географияне киңәйтергә карар кыла: ислам ипотекасы Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта да кулланыла башлый. Ислам ипотекасын үстерү юнәлешендә Ак Барс Банкның бүгенге көндә көндәше юк диярлек: Россия финанс базарында шәригать нормаларына туры килгән продуктны әлегә бик аз уенчы гына тәкъдим итә. Шул ук вакытта Татарстанда туган продукт кулланышка кертер алдыннан җентекле эксперт тикшерүен уза. Ул Ислам финанс учреждениеләрендә исәп-хисап һәм аудит оешмасы (AAOIFI) стандартларына ярашлы рәвештә «мурабах» дип аталган ислам контракты формасында эшләнгән һәм ТР Мөселманнары диния нәзарәтенең Голәмәләр советы тарафыннан хупланган.

Шунысы кызык: бу банк продукты да халык соравы буенча пәйда булган.

– Пандемия вакытында җир кишәрлекләре һәм торак йортлар сатып алуга ихтыяҗ берничә тапкырга артты. Шул ук вакытта халык тарафыннан ислам финанславына ихтыяҗ барлыкка килде, – дип аңлатты Алексей Акимов. – Көнүзәк сорауны өйрәнеп, Ак Барс Банкы «Комфорт – Исламская ипотека» дип аталган продуктны эшләде...

Югарыда аталган финанс продуктларыннан тыш, «Ак Барс Капитал» мөселманнарга кыйммәтле кәгазьләргә хәләл инвестицияләр кертергә мөмкинлек бирә торган «Лалә» Ачык пай инвестиция фондын тәкъдим итә. Банкның матбугат хезмәтендә, ислам продуктларына гаризалар кабул итү динамикасы уңай дип белдерәләр. Өстәвенә, илнең мөселманнар яши торган төбәкләрендә, бигрәк тә Төньяк Кавказда, ихтыяҗның артуы күзәтелә. Татарстанның пилот проектында катнашуы – ислам банкингын алга таба үстерү, шәригать нормаларына туры китереп ясалган яңа продуктларны илебез базарына чыгару өчен яхшы мөмкинлек.



МУДАРАБАМЫ? РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Әгәр Ак Барс Банк конкрет хәләл финанс инструментларын эзлекле рәвештә үзләштерү һәм тормышка ашыру юлы белән барган булса, Саклык банкы башка стратегия сайлый. Узган елның декабрендә банк Татарстан башкаласында ислам банкингы кагыйдәләре

Рөстәм Шәфигуллин,
«Жилищные Традиции» торак кооперативы директоры:

– Шәригать кануннарына туры китереп, бүлеп түләү ысулы белән торак сатып алу программасы финанс продуктлары базарында тәкъдимне үстерә һәм банк хезмәтләренә көндәшлек тудыра. Хәзерге вакытта федераль көйләүче һәм закон чыгару органнары белән кредит булмаган финанс продуктларына дәүләт ярдәме чараларын (ана капиталы, өченче бала өчен акча, торак сертификатлары һ.б.) куллануга рөхсәт алу буенча эш алып барыла. Дәүләт ярдәме чараларын куллану мөмкинлеге ислам финанс продуктлары индустриясен үстерүдә мөһим фактор була ала. Төп максат – торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булганнарның барысына да йорт һәм фатир сатып алырга булышу, өстәвенә, тиз, ышанычлы һәм ипотека программаларына караганда арзанрак юл белән.

буенча эшли торган аерым офис ача – Россиядә иң беренчесен.

Партнер финанславы офисы ваклап сатуга да, корпоратив клиентларга да хезмәт күрсәтүне күздә тота, ә клиентларга тәкъдим ителгән продуктлар арасында – мудараба (активлар белән ышаныч кәгазе нигезендә идарә итү аналогы), хәләл инвестицияләү инструментлары, сәүдәне финанслау, банк гарантиясе, түләү һәм агымдагы счетлар, исәп-хисап-касса хезмәте һ.б. Әлбәттә, барысы да шәригать кануннарына төгәл туры китереп башкарыла. Бу Саклык банкы матбугат хезмәтенә: «Татарстан башкаласындагы ислам офисы – Россиядә шәригатьнең барлык нормалары буенча оештырылган һәм рәсмиләштерелгән беренче бүлекчә» дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Мондый офисның нәкъ менә Казанда ачылуы, әлбәттә, очраклылык түгел.

Татарстан ислам банкингы институтларын формалаштыруга максатчан әзерлекне берничә ел элек башлаган иде, ә процессның инициаторы һәм илһамландыручысы республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов булды.

– Татарстан Россиядә партнерлык банкингын гамәлгә кертү буенча пилот төбәк булды, – дип билгеләп үтте Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов бүлекчәне ачу тантанасында. – Безнең илдә ислам динен тотучылар санының артуы күзәтелә. Ислам динендәге халык саны традицион рәвештә югары булган аерым субъектлар бар. Бу төбәкләрдә партнер финанславы стандартларына туры килгән банк продуктлары һәм хезмәтләренә ихтыяҗ шактый зур.

ИКЕ ПРОБЛЕМА: ЗАКОННАР ҺӘМ КАДРЛАР

Шунысын искәртик: Саклык банкында инде берничә ел Партнер финанславы һәм махсус проектлар үзәге эшли. Аның активында исламча финанслауның төп ихтыяҗларын каплый торган 13 продукт бар. Идарәче директор – Үзәк башлыгы Бехнам Гурб-Заде узган ел башында гомуми санны да атады: 15 млрд сумга якын. Бу – ул вакытта Татарстан, Дагыстан һәм Чечен Республикасы компанияләреннән исламча (партнер) финанслауга алынган гаризалар күләме.

Хәер, белгеч билгеләп үткәнчә, бу әлегә тормышка ашырылмаган потенциал. Клиентлар коммерция ягыннан акланган шартларда финанслар алырга мөмкинлек бирә торган, бәя ягыннан балансланган продукт пәйда булуын көтәләр.

Бехнам Гурбан-Заде Россиядә ислам банкингы үсешен тоткарлаучы ике проблеманы билгеләп үтте. Бу профильле законнарның һәм профессиональ кадрларның булмавы.

Әгәр беренче проблеманы РФ Дәүләт Думасында беренче укылышта каралган закон хәл итәргә тиеш булса, икенчесен Саклык банкы үз көче белән чишәргә алына. Февральдә Сберуниверситетта ислам финанслары буенча белем бирү программасының көндезге модуленә старт бирелә. Ул Саклык банкының Партнер финанславы һәм махсус проектлар үзәге белән уртак эшләнгән программа. Чыгарылыш укучылары, квалификация күтәрү турында дипломнан тыш, исламча финанслау өлкәсендә Global Islamic Financial Services Халыкара белем бирү оешмасы сертификатын да алачак.

Сорау туа: пилот төбәкләрдә ислам банкингын гамәлгә кертү буенча эксперименттан без нәрсә көтәбез? РФ Финанс министрлыгының Финанс сәясәте департаменты директоры Иван Чебесков «Россия банклары – XXI гасыр» форумында билгеләп үткәнчә, әлеге сорау хәзерге вакытта аеруча актуаль, чөнки инвестицияләр җәлеп итүнең, көндәшлекне үстерүнең һәм партнер финанславы өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең төрле ысулларын эшләргә кирәк.

– Әмма көйләүне керткәнче, эксперимент үткәрергә кирәк, – дип аңлатты Иван Чебесков. – Экспериментта кредит оешмалары да, кредит оешмалары булмаганнар да катнаша ала. Бу мөһим аспект. Ләкин алар барысы да партнер финанславы үзенчәлегенә туры килергә тиеш.

Аның сүзләренә караганда, башлангыч этапта РФ Хөкүмәте каршында Совет булдыру тәкъдим ителә. Советта, Үзәк банк белән килештереп, көйләүне камилләштерү чаралары һәм, әлбәттә, нәтиҗәләр тикшереләчәк. Эксперимент кысаларында мондый Совет кире элемтә булдыруга ярдәм итәчәк. Ә инде соңрак, эксперимент нәтиҗәләре буенча партнер финанславы мәсьәләләре белән шөгыльләнергә тиешле үзкөйләүле оешма (СРО) ачарга мөмкин.

ҖЫЛЫ УРЫН. ИНВЕСТОР ҮЗЕ САЙЛЫЙ

Инвесторларга Татарстан тәкъдим итә торган преференцияләр, республика территориясендә урнашкан махсус икътисадый зоналар, алгарышлы икътисадый үсеш территорияләре, индустриаль парклар – болар барысы да бизнесны уңышлы алып бару өчен тудырылган мөмкинлекләр. Ләкин нинди генә шәп мөмкинлекләр тудырылмасын, бу нәтиҗә һәрвакыт уңай булачак дигән сүз түгел. Әлеге мөмкинлекләрдән дөрес, отышлы итеп файдалана белү исә бизнесны уңышка алып бара. Татарстанга эшләргә килгән компанияләргә күз салу да җитә – һәркайсы шуңа бер дәлил.

«Роквул-Волга», «Тракья Гласс Рус», «Август-Алабуга», «Хаят Кимья», «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри»… Идеалга якын шартларда алдынгы технология һәм тәҗрибәне үстерүдән алынган синергетик нәтиҗә бизнеста уңышка ирешергә булышкан предприятиеләрне санап чыгар өчен генә дә күпме вакыт кирәк булыр иде. Шуңа да бик күп мисаллар арасыннан без өчесен генә сайлап алдык. Димәк, инвестицияләр кертү өчен урынны дөрес сайлаган очракта, нинди уңышларга ирешеп булуы турында өч тарих.

Фотолар: president.tatarstan.ru, kastamonu.ru, kazanpalace.com, alabuga.ru

ЕВРОПАГА – АЛАБУГА АША

Алабугадагы «Кастамону» заводы – Европаның иң эре агач эшкәртү предприятиеләренең берсе. Ул елына 1,05 млн кубометр МДФ-плитә чыгара. Бүген бу хакыйкать, гәрчә әлеге завод оешып, халыкара дәрәҗәдә танылу алганга нибары берничә ел гына узган булса да. Гадәти шартларда мондый дәрәҗәгә күтәрелү өчен дистәләрчә ел таләп ителер иде. Алай гына да түгел, ачылганнан соң ике ел үтүгә, завод Россиянең идән өслекләре базарында лидерлар исәбенә керә.

«Кастамону» заводының Россиядәге генераль директоры Али Кылыч сүзләренә караганда, Россия Федерациясендә агач эшкәртү заводына инвестиция кертү идеясе 2008 елда туа. Ул вакытта компания вәкилләре Сочида узган форумда Татарстан Республикасы стенды белән таныша. Шуннан соң барысы да бик тиз хәл ителә. 2010 елның мартында «Алабуга» Махсус икътисадый зонасының Күзәтү советы үз территориясендә завод төзүгә фатиха бирә. Шул ук елның май аенда тантаналы рәвештә беренче нигез ташы салына. Тәүге продукция 2014 елның май аенда чыга.

Бүген «Кастамону» Россиянең МДФ-плитә җитештерү базарының 30 процентын алып тора, шулай ук ламинатланган идән өслекләрен экспортка чыгару буенча иң эре җитештерүчеләрдән санала.

– Без инвестицияләр өчен иң дөрес урынны сайлаганга үсәбез, – дип аңлата Али Кылыч. – Моннан тыш, республика һәм федераль җитәкчелек безгә һәрьяклап ярдәм күрсәтеп тора.

Нигә төзелеш өчен иң дөрес урын буларак Татарстанның «Алабуга» махсус икътисадый зонасы сайлап алына соң? Биредә бизнеска эшләп китәр һәм үсәр өчен уңайлы инфраструктура һәм икътисадый шартлар тудырылган, дип ачыклык кертә Али Кылыч. Беренчедән, резидентлар сыгылмалы салым системасы белән тәэмин ителгән. Икенчедән, махсус икътисадый зонаның инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы дәүләт инвестицияләре хисабына булдырылган. Өченчедән, резидентларга административ-оештыру мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтелә: кадрлардан башлап, хакимият органнары белән хезмәттәшлек итүгә кадәр. Дүртенчедән, продукциягә таможня хезмәте «бер тәрәзә» режимында күрсәтелә.

– Шулай ук безнең өчен Татарстан белән Төркия халыкларының якынлыгы, мәдәни-тарихи уртаклык та зур әһәмияткә ия, – ди Али Кылыч. – Беренче тапкыр монда килгәч, татар телен 70 процентка аңлавыма төшендем. Бу безгә яңа урынга ияләшергә, шулай ук проектыбызны тиз һәм уңышлы итеп тормышка ашырырга мөмкинлек бирде.

Бүген Алабугадагы завод елына 1,05 млн кубометр МДФ-плитә һәм 35 млн кв. метр ламинат эшләп чыгара. Эшләү дәверендә предприятие төбәккә 771,8 млн доллардан артык күләмдә инвестицияләр керткән. Предприятиенең үзендә – 950 дән артык, ә читтәш һәм хезмәт күрсәтү тармакларында 3000 кеше эш белән тәэмин ителгән. Тагын әле бу төп предприятиесе «Кастамону» булган җиһазлар җитештерү кластерын үстерү дә. Урман кисү тармагы предприятиеләре өчен сату базары да. Ахыр чиктә, импортны, ягъни Россия базарында чит ил җитештерүчеләре продукциясен алмаштыру да.

ЭЛЕККЕГЕ ЗАТЛЫЛЫК ҺӘМ ГАДИЛЕК

«Полимекс» төрек компаниясе Шамов хастаханәсе бинасын сатып алгач, күпне

күргән төзелеш бизнесы вәкилләре аптырап кала. Егерменче гасыр башында төзелеп, ярым җимерек хәлгә килгән бинаны яңартырга тәвәккәлләрлек кешеләрне Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә таба алмыйлар. Әмма бу эш алдан ук тормышка ашмастай тоела, шуңа күрә әле кыю адымга барган кешеләргә сәерсенебрәк карыйлар.

Ә эш тагын да кызыграк дәвам итә. Бинаның алгы ягы матурлана, хастаханә палаталары урынында биш йолдызлы кунакханә номерлары һәм холлары пәйда була.

European Property Awards премиясенең төбәк этабында «Яңа отельнең иң яхшы дизайн-проекты-2018» категориясендә җиңеп, кунакханә ачылганчы ук халыкара танылуга ирешә. Сүз уңаеннан, инвесторга проектны җиренә җиткереп башкарып чыгарга һәм алга таба үсәргә пандемия кебек гадәттән тыш хәл дә комачауламый.

Объектны реставрацияләргә һәм кунакханә итеп үзгәртергә биш ел таләп ителә. Архитекторлар, йөз еллык тарихи бинаның тышкы кыяфәтен үзгәртмичә, бик сак эш итә. Кайбер раритетлар, төзекләндерү эшләреннән соң, биш йолдызлы кунакханәнең заманча йөзенә бизәк кенә өсти. Кунакларны отельнең гадилеге, шул ук вакытта зиннәтле-зәвыклы булуы да сокландыра.

Кунакханә 2019 елның 1 мартында ачыла һәм шул ук елны коммерциячел күчемсез милек өлкәсендә CRE Federal Awards дигән һөнәри премиягә лаек була.

– Kazan Palace Hotel by Tasigo безгә килгән чит ил инвесторларының кунакханә инфраструктурасын үстерүдә катнашуына гына түгел, Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау стратегиясен гамәлгә ашыруда булышуына да уңышлы мисал булып тора, – диде кунакханә ачылышы тантанасында ТРның Инвестицияле үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Яңа бина кунакларны уңайлы шартлар белән тәэмин итә, ә бу исә республикага тагын да күбрәк туристларны җәлеп итү мөмкинлеге бирә. Объект төзелешенә кергән инвестицияләрнең гомуми күләме 15 миллион доллардан артыграк.

– Отельләребез концепциясе үзенчәлекле дизайн, югары хезмәт күрсәтү дәрәҗәсе белән аерылып тора, шуңа күрә кунакларны битараф калдыра алмый, – ди Kazan Palace by Tasigo һәм Neo Kazan Palace by Tasigo* кунакханәләренең генераль менеджеры Серкан Аслан. – Бер тапкыр килгәннән соң, алар тагын безгә әйләнеп кайта.

Сүз уңаеннан, Neo Kazan Palace by Tasigo – Tasigo төркеменең Татарстан башкаласындагы икенче кунакханәсе, дүрт йолдызлы. Кунакханә 2020 елның декабрендә ачыла, ә инде мартта яхшы күрсәткечләргә дә ирешә. Ул шулай ук «Кунакханә күчемсез милеге» номинациясендә, коммерциячел күчемсез милек өлкәсендә Commercial Real Estate Awards һөнәри премиясенә лаек була.

– Без Татарстанда икътисадның төрле тармакларында, шул исәптән туризм һәм кунакчыллык тармагында да үсеш күрәбез. Казанда ел саен халыкара һәм бөтенроссия күләмендәге форумнар уза, шул сәбәпле шәһәрнең барлык кунакханәләренә дә ихтыяҗ бар. Тулаем алганда, мин Татарстанда үсеш өчен мөмкинлекләр зур икәнен беләм, – ди Серкан Аслан.

* «Тасиго» – Төркия һәм Россия территорияләрендә кунакханәләр белән идарә итү компаниясе, Төркиянең «Полимекс» төзелеш холдингы составына керә.

МӨҺИМ КӘГАЗЬ БИЗНЕСЫ

Россиянең кәгазь тастымаллар базарында лидерларның берсенә әйләнер өчен Алабугадагы «Хаят Кимья» заводына өч ел кирәк була. Бәдрәф кәгазе базары әйдаманы булыр өчен юл озаграк – биш елда үтелә.

Компания «Алабуга» МИЗ резиденты буларак 2011 елда теркәлә. Югары технологияле предприятие төзелешенә берничә ел китә. Заводның беренче чираты махсус икътисадый зонада дүрт елдан соң эшли башлый. Анда популяр брендлар астында йөз процентлы целлюлозадан бәдрәф кәгазе, салфетка һәм кәгазь тастымаллар җитештерелә. Проектка кертелгән инвестиция күләме 150 миллион долларны тәшкил итә. Инвестор ирешелгәннәрдә туктап калырга җыенмый. 2017 елның сентябрендә заводның икенче чиратын төзүгә фатиха алына. Ул да файдалануга тапшырылгач, предприятиенең җитештерү куәте елына 140 мең тоннага җитә, ә хезмәткәрләр саны 900 кеше була. Җитештерүне киңәйтү өчен кертелгән 3 миллиард сумнан артык акча «Хаят Кимья» заводына «Алабуга» МИЗнда премиаль бәдрәф кәгазе җитештерү мөмкинлеге бирә.

2020 елга «Хаят Кимья» Россиядә санитар-гигиена продукциясе җитештерү буенча икенче урынга чыга. Ул вакытта Россиядә җитештерелгән бәдрәф кәгазьләренең - 25%ы, тастылмалларның 33%ы «Хаят Кимья» предприятиесендә эшләнә. 2021 елның апрелендә «Хаят» холдингының бүлендек компаниясе булган «Хаят Россия» үз бренды астында бәдрәф кәгазе, кәгазь тастымал һәм салфеткалар, шулай ук нигез кәгазьләр җитештерү буенча завод төзелешенә 9 миллиард сумлык инвестиция кертү нияте турында игълан итә. Бу юлы – Калугада.

– Без – Россиянең кәгазь-гигиена продукциясе базарында лидер дип, горурланып әйтә алам. Нибары өч ел эчендә кәгазь тастымаллар җитештерү буенча алдынгылыкка ирештек – 2020 ел ахырына базарның 37% өлеше безгә туры килә иде. 2020 елның декабрь аена 29,4% ка ирешеп, бәдрәф кәгазе базарында да лидерлыкка чыктык, моның өчен безгә биш ел вакыт кирәк булды, – диде «Хаят Россия» генераль директоры Метин Мете. – Компаниябез Россиянең 88 500 сәүдә ноктасын үз товары белән тәэмин итә, шулай ук дөньяның 14 иленә озата. Безнең уңышның нигезенә 900 дән артык хезмәткәрдән торган команданың фидакарь хезмәте һәм «Хаят» холдингы тәҗрибәсе салынган.

«Хаят» җитештерүгә карата инновацияле, экологияле сәясәте белән аерылып тора. Бүгенге җитештерү куәтләре – ресурсларны сакчыл тоткан, тулысынча автоматлаштырылган алдынгы системалар базасында эшли торган инновацияле пространство ул. «Хаят Россия» илнең урман ресурсларын сакларга актив булыша, җитештерүгә плантация урманнарында үскән агачлар гына китә. Компания Россия тәэминатчыларының сәнәгать максатларында үстерелгән һәм FSC сертификатына ия агачларыннан алынган 100 процентлы беренчел целлюлозаны гына куллана.

БӨЕК КӨЧКӘ ИЯ УК

Милли фольклор герое образын тудыру максатын куеп, «Туган Батыр» проекты авторлары, моны эшләп кенә калмыйча, хәтта әкият дөньясы белән чынбарлык арасында тәрәзә дә ачкан.

Россиянең берничә төбәгеннән килгән җәячеләр турниры масштаблы «Туган Батыр» проекты кысаларында үтә. Берничә ел элек Татарстан эшкуары, хәйрияче, «Туган Авылым» милли комплексын оештыручы Радик Абдрахманов татар халык каһарманын булдыру идеясе белән мавыга башлый, әлеге образ дөньякүләм заманча аудиториягә аңлаешлы һәм якын булырга тиеш, дип уйлый. Радик Абдрахмановның креатив идеясен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм танылган язучы Зөлфәт Хәким хуплый. Язучының татар халкының төп мәдәни, рухи, тарихи кодларын үзенә сыйдырган бәян-әкияте аңа нигез итеп алына.

– Баш герой итеп без гап-гади яшүсмерне сайладык, ул игелекле, акыллы, кыю, безгә һәм балаларыбызга охшаган. Без үзебез өчен бөтенләй ят идеяләрне алга сөргән чит ил фильм һәм комиксларындагы супергеройларны оныттырырлык образ иҗат итү турында хыялландык. Ә без традицион дөньяда, гореф-гадәтләребезне һәм бөек тарихи мирасыбызны саклап яшәргә телибез, – ди Радик Абдрахманов. – Китапта Туган Батыр төрле илләр буйлап сәяхәт иткән кебек үк, безнең проектыбыз да тормышта сәяхәт итә һәм бөтен дөньяга татар мәдәнияте, теле, ислам дине турында сөйли. Проектның популярлыгы һаман арта бару безнең традицион кыйммәтләребезнең һәм аларны саклау тәҗрибәбезнең башка төбәкләр һәм илләр өчен дә никадәр кызыклы булуын дәлилли.

Китап-эпосның беренче өлешен тәкъдим итү XIII Халыкара «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit – 2022» икътисадый саммиты кысаларында уңышлы үтә. Былтыргы май аеннан бирле проект авторлары китап үсәргә тиешле әллә никадәр юнә-

Фотолар «Туган Авылым» милли комплексының матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА. 6+

леш булдыра, шулай ук Туган Батыр һәм аның дусларының ерактагы тылсымлы илдәге маҗаралары хакында бәяннең икенче өлешен бастыруга әзерли.

ҺӘРКЕМГӘ ТАНЫШ СЫНАУЛАР

«Мәмәш исемле малай бервакыт тау итәгенә җиләк җыярга барган һәм анда бик бәләкәй кәлтә баласын тапкан. Әгәр кәлтәнең койрыгын өзсәң, берникадәр вакыттан соң аның кабат үсәчәген малай яхшы белгән. Ул кәлтәне өенә алып кайткан, талчыбыктан үрелгән чуманга салып, капкачын ябып куйган. Әледән-әле кәлтәнең койрыгын өзеп, ул яңасының ничек үсүен күзәткән...», – дип башлана китапта Туганның бөтен авылны куркытып торган аждаһа – Зур Кәлтә белән очрашкан бүлеге. Геройга бик кыен әхлакый карар кабул итәргә туры килә.

Бәяннең икенче өлешендә нәкъ менә сайлап алу һәм аның нәтиҗәләренә бик зур урын бирелә. Беренче китапта үсмер Туган тормышның якты һәм караңгы яклары, җиңү һәм җиңелүләр, дуслык һәм хыянәт, мәхәббәт һәм нәфрәт турында белә генә башлый әле. Икенче өлештә инде Туган үсә,

өлкәнәя, яңа, сихри белем һәм күнекмәләр белән коралланa. Хәер, әлеге тылсымга һәркем ия була ала.

– Туган Батырның көче – аның дөнья белән кызыксынуы, саф йөрәге, кыюлыгы һәм гаделлеккә ышанычы. Без аңа әлеге сыйфатларны тикмәгә генә бирмәдек, бәлки аның төрле хәлләрдә кабул иткән карарлары ярдәмендә традицион кыйммәтләрнең – мәдәниятебез, динебез, гаилә тормышының, ата-бабаларыбызның бөек тарихи мирасының никадәр мөһим һәм куәтле булуын күрсәтергә теләдек, – ди «Туган Батыр» проектының авторы, эшкуар, хәйрияче, «Туган Авылым» милли комплексын оештыручы Радик Абдрахманов.

МӘГЪНӘЛЕ СУРӘТЛӘР

Туган батыр кая гына бармасын – Хаклык кылычын эзләпме яки ерак Көньяк иленәме (Кырым, дип укы), аны һәркайда сынаулар көтә. Сарыкан иблис аны эзәрлекли һәм котырта, данлы киләчәккә җиңел юллар тәкъдим итә. Әмма Туган Батыр чын эчке куәтнең зур хезмәт таләп итүен аңлый һәм үзендә иблис коткысына каршы торырлык көч таба.

– Бу текст миндә иң башыннан ук безнең үз эчебездәге игелек һәм явызлык көрәше турында фикерләр уятты. Кеше явыз булып тумый, ул шундыйга әйләнә. Әкияттә минем иң яраткан фрагментларымнан берсе – Зур Кәлтә турындагысы – нәкъ менә шул хакта, – ди иллюстратор Диләрә Газиева. Эпосның икенче өлешендәге мавыктыргыч график образларны аның кылкаләме тудыра. Эпосны замана укучысына мөмкин булганча якынайту, беренче чиратта балаларга ошарлык итү өчен рәссамга сурәтләрне бик тормышчан итәргә кирәк.

– Балачагымда әбием миңа совет чорында басылган иске әкият китапларын күрсәтә иде. Алардагы иллюстрацияләр шул чорны чагылдыра, буяулар һәм кара белән кулдан ясалган рәсемнәр бик матур тоела иде, – ди Диләрә. – Ә безнең югары технологияләр заманында балаларны нәрсә белән булса да гаҗәпләндерү, аларның игътибарын җәлеп итү һәм җуймый саклау бик катлаулы. Һәм бу шәп тә! Графика заман белән бергә атларга тиеш. Мин эпосның максатына



Геройларның портретларын, дөньяның төрле почмакларыннан яшь укучылар җибәргән меңләгән фотосурәткә нигезләнеп, нейрочелтәр ясаган.

ирешүен телим: ул татар мәдәнияте турында халыкара дәрәҗәдә сөйләсен, аны популярлаштырсын һәм яшьләр өчен яңа яссылыкта яңадан тудырсын иде.

Зөлфәт Хәким, язучы, «Туган Батыр» китабы авторы:

«Безгә, галәм үлчәмнәре белән санаганда, бик кечкенә планетада яшәргә язган. Һәм әгәр фикер биеклегеннән карасак, Җирдә, анда яшәүче җан ияләре дә әкияти тоелачак. Безнең тормыш үзе әкият түгелмени? Кеше тормышы – өндәге төш яисә гомер озынлыгына сузылган әкият ул. Тормыш дигән әкият кешелек һәм аерым һәр кеше тарафыннан буыннан-буынга языла бара. Һәр буын ул әкияткә үз сюжетын өсти. Шуңа күрә әкиятнең ничек тәмамланасы, финалының нинди булачагы (фаҗигалеме яисә бәхетлеме) һәм нинди әхлакый нәтиҗәләр ясалачагы бездән һәм аерым һәр кешедән тора».

ЧЫНБАРЛЫКЛАР АРАСЫНДАГЫ ИШЕК

Аналитиклар мәгълүматлары буенча, 2025 елга баетылган (өстәлгән) чынбарлык (AR, augmentative reality) безне һәряклап чолгап алачак. «Туган Батыр» проекты авторлары да сихри көч белән идарә итү сәнгатендә эпос героеннан калышмый һәм XXI гасыр тылсымын – заманча технологияләрне файдалана: китапның тышлыгы AR ярдәмендә җанланачак.

– Баетылган чынбарлык, кешегә әдәби әсәргә хис дәрәҗәсендә кереп чумарга мөмкинлек биреп, эмоциональ элемтә урнаштырырга булыша. «Туган Батыр» китабының икенче өлеше тышлыгын җанландыру белән шөгыльләнгәндә, без әкияткә кереп чумдык, геройлар белән элемтә урнаштырдык. Укучыларның да шундый мөмкинлеге булачак, – ди AR проектларын төзү һәм гамәлгә кертү белән шөгыльләнә торган ATLANTIS компаниясен оештыручы Андрей Свежинцев.

Тышлык укучылар һәм китап геройлары өчен уртак дөньяга ишек ача. Кулланучыларның тулы кыйммәтле катнашуы өчен инде «Туган Батыр» китабы мотивлары буенча VR*-уен да эшләү планлаштырыла. Квест форматындагы, ягъни яшерелгән артефактларны эзләү һәм башваткычлар чишү формасындагы уен VR-күңел ачу паркларында тәкъдим ителәчәк.

РОССИЯ КИНОСЫ ТАРИХЫНДА КҮРЕЛМӘГӘН ХӘЛ

Китап идеяләре балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә илһамландыра. Алар анда үз проектлары өчен ресурслар таба.

– Әле күптән түгел генә безнең мультипликаторлар һәм уен киносы режиссерлары менә дигән фильмнар төшерә, алар чит ил кинематографчыларыннан да остарак иде, моны үз вакытында хәтта Уолт Дисней да таныган. Бүген исә Россия киносында яшүсмерләр өчен бернинди тәкъдим дә юк. Балаларыбыз йә Голливуд сериалларын, йә Япония һәм Корея манга, дорама, анимеларын карый, – ди «Туган Батыр» эпосы мотивлары буенча анимацион сериал төшерү проектында катнашучы креатив продюсер Юлия Сафонова. – Ә бит кызыклы, мавыктыргыч, энергияле һәм күңелле дә, шул ук

Тансал Кандәмир, төзелеш бизнесы хуҗасы (Төркия, Анталья)

«Татар милли мәдәниятен тарату өчен шундый актуаль форматта китап-эпос булдыру идеясе миңа бик зур тәэсир ясады. Мин үз тамырларың, гореф-гадәтләреңң, динеңне онытмау омтылышын хуплыйм. Минем бу проектка үз өлешемне кертәсем һәм китапка Төркиядә үз аудиториясен табарга ярдәм итәсем килде. Шунлыктан мин текстны төрекчәгә тәрҗемә итүдә булышырга булдым».

вакытта героик та фильм төшерәсе килә, ул үсеп килүче буында ватаныбыз тарихы һәм мәдәниятенә карата кызыксыну уятырга, игелек, намуслылык, вөҗданлылык тәрбияләргә, дуслык һәм мәхәббәтне данларга тиеш булачак. Безгә үз балаларыбыз охшарга теләгән нәкъ менә шундый герой кызыклы: шаян һәм батыр, игелекле һәм үзсүзле, акыллы һәм кызыксынучан, гармониягә омтылучан актив герой булсын ул.

Мультипликацион сериалны төшерү белән «Фиксики», «Смешарики» һәм Россия анимациясенең башка хитларын тудырган белгечләрне берләштергән иҗат командасы шөгыльләнә. Хәзер беренче 52 серия төшерелә. Аның тизеры XIV Халыкара «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum – 2023» икътисадый форумында күрсәтеләчәк.

– Россия киносында мондый проектның булганы юк әле. Бер фильмда дөнья кинематографының иң шәп үрнәкләре очрашачак: «Аватар – легенда об Аанге», «Бен Тен», «Гравити Фолз», «Властелин колец» һәм «Фиксики» – менә нинди зур амплитуда! Шул ук вакытта без ниндидер уйлап чыгарылган илне һәм дөньяда булмаган мифологияне өйрәнеп азапланмаячакбыз – безнең фильм Татарстан мәдәнияте һәм тарихына, легенда һәм мифларына нигезләнә, – ди Юлия Сафонова.

«БАТЫР» ИНВЕСТИЦИЯЛӘР ҖӘЛЕП ИТӘ

Бәяннең дәвамында Туган Батыр ерак илгә сәяхәткә китәчәк. Аны серле Алтайда, борынгы гүзәл Төркиядә маҗаралар көтә.

Герой белән бергә проект үзе дә халыкара дәрәҗәгә чыга. Эпосның географиясе проект авторларының Туган һәм аның сөйгәне Гөлчәчәкнең җыелма образларын нейрочелтәр ярдәмендә төзү идеясе нәтиҗәсендә киңәйгән. Челтәр дөньяның төрле почмакларыннан җибәрелгән меңләгән фотоны эшкәрткән. Проект геройларының җыелма образларын төзү буенча аудитория 5,5 миллион кешедән арткан.

Эпосның икенче өлеше татар, рус, гарәп, инглиз, төрек һәм казах телләрендә чыгачак. Ә китапның беренче өлеше илнең барлык китапханәләренә, шулай ук чит илләргә җибәрелгән, хәтта Вашингтонга, АКШ Конгрессы китапханәсенә кадәр барып җиткән.

– «Туган Батыр» проекты һаман куәтләнә бара торган тулы бер брендка әйләнде. Без инде киләчәктәге киң колачлы үсешне планлаштырабыз. Анимацион сериал төшерү инвестицияләр таләп итә, аларның бер өлешен без грантлар ярдәмендә җәлеп итәргә ниятлибез, әмма шулай ук төрле партнерлык тәкъдимнәрен дә өйрәнәбез, – ди Радик Абдрахманов. – «Туган Батыр» үзендә бөтен төрки-гарәп дөньясына аңлаешлы кыйммәтләрне берләштерә, без әлеге илләрдәге берничә укучыбыздан җылы фикер ишеттек инде. Без әлеге проектның никадәр үсешкә ирешә алачагын күрәбез. Безнең геройбыз белән шунда барырга җыенабыз. Иң кызыклысы әле алда!

«Туган Батыр» проекты катнашында уздырылачак чаралар:

МАЙ

18–19 май – XIV Халыкара «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum – 2023» икътисадый форумы **«Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәге**

ИЮНЬ

1 июнь – «Туган Батыр» балалар бәйрәме
«Туган авылым» ресторан-күңел ачу комплексы, керү бушлай

3 июнь – «Туган Батыр» проекты призларына спорт фестивале
«Ак Барс» көрәш сарае, керү бушлай

Июньдә **Татарстан милли китапханәсендә (Казан)** узачак:

- «Туган Батыр» проекты турында «Код успеха» фильмын тәкъдим итү
- «Туган Батыр» китабының икенче өлешен тәкъдим итү, **керү бушлай**

* Virtual reality - виртуаль чынбарлык.

ЧИКСЕЗ БЕЛЕМ

Елена Добровольская

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, агымдагы уку елында Татарстандагы югары уку йортларына 9000 нән артык чит ил студенты укырга кергән. Безнең университетлар чит ил яшьләре өчен кай ягы белән кызыклы? Ни өчен Казан шулкадәр популяр? Шул турыда берничә тарих.

АКЫЛЛЫ КИТАПЛАР БАСЫЛГАН ИЛГӘ

Казан энергетика университетында өч елга якын уку дәверендә Ангола егете Гарсия Себаштиау имтиханнарда бары тик бер генә дүртле алган, калганнары – гел биш. «Иң авыр фәнне бишкә бирә алмадым», – ди ул, күңелсезләнеп. Кызыл диплом турында хыялланганга борчыла. Деканатта Гарсияне тынычландыралар: бер генә дүртле хыялына киртә куя алмый. Әлбәттә, алга таба да шулай тырышып укыган очракта.

Ә Гарсия укырга ярата. Туган иле Анголада ул, математика һәм физика буенча олимпиадаларда катнашып, уңышларга ирешкән. Көллияттә механик булырга укыган һәм Россиядә инженер белеме алу турында хыялланган.

– Анголада күп кенә дәреслекләребез рус теленнән тәрҗемә ителгән иде. Укытучылар безгә гел, бу китаплар Россиядә язылган, дип әйтә иде. Һәм минем шундый акыллы китаплар басылган илгә барасым килде. Олимпиадаларда катнашу монда килү өчен стипендия алырга ярдәм итте. Ә Казан энергетика университеты турында монда укыган дустымнан белдем. Ул Казан бик тыныч шәһәр, өстәвенә, биредә тулай торак университет янында гына, юл өчен вакыт һәм акча сарыф итәргә кирәкми, дип сөйләде...

Хәзер Гарсия КДЭУның Электр энергетикасы һәм электроника институтында укый, аның белгечлеге – «электр энергетикасы системаларын релелы саклау һәм автоматлаштыру». Катлаулы техник дисциплиналар, билгеле, рус телендә укытыла.

Фотолар: tatar-inform.ru, Инна Басыйрова, геройларның шәхси архивыннан.

Португалча сөйләшүче героебыз рус телен Казанга килгәнче бөтенләй белмәгән. Шөкер, энергетика университетының әзерлек бүлегендә чит ил студентларына (сүз уңаеннан, алар биредә 350 ләп кеше) бер ел дәвамында рус телен өйрәтәләр.

Гарсиянең вуз алды әзерлеге бүлегендә рус телен укыткан укытучысы Лариса Тәлгать кызы Демидовага рәхмәте зур. Нәкъ менә укытучысы ярдәмендә ул ярты ел эчендә шундый катлаулы телне өйрәнә. Һәм, әлбәттә, тулай торак кухнясы да ярдәм итә, чөнки анда рус телле студентлар белән күп аралашырга туры килә. Әмма кайбер рус сүзләре аның өчен әлегә кадәр табышмак булып кала. Мәсәлән, португал телендә, дип аңлата миңа Гарсия, хәрәкәтне белдерүче бер генә фигыль бар. Мин хәрәкәтләнәм – бетте, аның ни рәвешле башкарылуы мөһим түгел. Ә рус телендә «лечу» «еду» «иду» – бөтенләй башка сүзләр... Яисә дуслары аңа: «Ну ладно, мы пошли», – диләр. Ә бит «пошли» – үткән заман фигыле, ә алар әле барырга гына җыена. Гомумән, мондый нечкәлекләр шактый. Ләкин Гарсия тырыша. Әзерлек курсларында укыганда хәтта чит ил студентлары арасында рус теле буенча бөтенроссия олимпиадасында беренче урынны да ала.

Беренче курс башында барыбер авыррак, әлбәттә, чөнки техник дисциплиналар буенча кайчак рус телендә сөйләшүче дә аңлап бетерми торган терминнар шактый. Ләкин миңа укытучыларым һәм курсташларым нык ярдәм итте, дип искә ала Гарсия. Бигрәк тә Чистай егете – иң якын дусты Зөфәт.

– Ул Россиядә мин белгән иң акыллы кеше! – ди Гарсия.

Сүз уңаеннан, Гарсия Чистайда кунакта булган инде. Хәер, хәзер аның Россиядә дуслары күп, шуңа күрә ул инде Самарада да, Кировта да булган. Әлбәттә, Мәскәүне дә күргән. Әмма Гарсия тормыш һәм уку өчен Казанны сайлавына бер дә үкенми. Шәһәр аңа ошый. Гарсия йөрергә ярата (бигрәк тә җылы вакытта, кышкы салкыннарда тулай торактан чыкмаска тырыша). Шәһәр матур, кешеләр монда мәрхәмәтле. Дөрес, безнең герой фикеренчә, Ангола белән чагыштырганда, кешеләр әзрәк елмая. Ләкин ул биредә үзе өчен шуны аңлаган: әгәр дә кеше сиңа елмая икән, бу әдәпле булып күренү өчен генә түгел, ә ихлас күңелдән эшләнә.

Россиядә белем алу, ди Гарсия, Анголадагы кебек теориядә генә түгел. Практикумнар, лаборатор эшләр күп. Бу һөнәр үзләштерүдә нык ярдәм итә. Туган иле Анголада энергетик Себаштиауны эшкә алырга әзер предприятиеләр бар инде. Сүз уңаеннан, чит илдән килеп, КДЭУда белем алган күп кенә белгечләр дөнья буенча таралган энергетика компанияләрендә яхшы карьера ясыйлар. Гарсия Казанда алган белемнәре туган илендә яхшы эшләрдә эшләргә мөмкинлек бирер, дип ышана. Ләкин аңа әле күп нәрсәләрне өйрәнергә кирәк. Һәм ул моны шактый уңышлы башкара. Фәнни мәкаләләр яза. Чит ил студентлары арасында теоретик механика буенча бөтенроссия олимпиадасында икенче урынны алган. Гарсия магистратурага да керергә планлаштыра.

Казан энергетика университетында өч елга якын уку дәверендә Ангола егете Гарсия Себаштиау имтиханнарда бары тик бер генә дүртле алган, калганнары – гел биш.

ТАТАРСТАН ВУЗЛАРЫНДА 21 МЕҢГӘ ЯКЫН ЧИТ ИЛ СТУДЕНТЫ УКЫЙ. АЛАР 14 – ЯКЫН ҺӘМ 114 ЕРАК ЧИТ ИЛДӘН КИЛГӘН.

ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ ҺӨНӘРИ

Мисырлы Омар Гонейм Казан медицина университетына укырга керә. Укудан тыш, аны җәмәгать эшләре дә кызыксындыра. Омар студентлар матбугат үзәгендә эшләргә тели, әмма анда барысы да рус телендә генә сөйләшә. Әлбәттә, Омар укырга кергәнче бер ел дәвамында рус телен өйрәнә, ләкин үзен телне бик яхшы беләм дип санамый. Һәм чит ил студентлары өчен (алар университетта 2000 гә якын, шул исәптән ордина-

Мисырлы Омар Гонейм Казан медицина университетына укырга керә. Укудан тыш, аны җәмәгать эшләре дә кызыксындыра.

торлар, аспирантлар һәм әзерлек факультеты) инглиз телендә матбугат үзәге булдыру яхшы булыр иде, дип уйлый.

Вуз җитәкчелеге бу омтылышны хуплый, әмма эш кысаларын киңәйтергә тәкъдим итә – нигә әле бер юнәлеш белән генә чикләнергә? Шулай итеп, Омар Казанның Чит ил студентлары ассоциациясе ярдәме белән үз югары уку йортында шундый ук берләшмә оештыра. Һәм бүген Мисыр, Һиндстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Алжирдан Казанга килеп укучы медицина вузы студентларына сәнгатьтә, спортта, медиасферада яки фәндә үз сәләтләрен үстерү урыны бар.

– Без чит илдән килгәннәргә яңа шартларга яхшырак җайлашырга ярдәм итәбез, – ди Елдана Шеризатова.

Елдана – Казахстаннан. Омар кебек үк, ул да чит ил студентлары факультетының өченче курсында дәвалау бүлегендә укый. Бүген нәкъ менә Елдана КДМУның Чит ил студентлары ассоциациясен җитәкли. Татарстан студентлары лигасы белән бергә, алар хәзер чит ил студентларының торак проблемаларын хәл итәргә тырышалар. Елдана аңлатканча, эш бик җитди. Чөнки тулай торакта урыннар бөтен кешегә дә җитми, ә фатирларын арендага бирүчеләр һәрвакытта да анда вакытлыча яшәүчене теркәргә әзер түгел. Чит ил гражданы өчен теркәлү мәсьәләсе бик мөһим...

Омар да элеккечә үк Чит ил студентлары ассоциациясе тормышында актив катнаша. Моннан тыш, ул Халыклар дуслыгы йорты каршында оештырылган Татарстанның гарәп студентлары берлеге советына да керә. Алар концертлар оештыра, волонтерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә, рамазан аенда даими рәвештә студентлар өчен ифтарлар үткәрә...

Әлбәттә, Казанның мөселман традицияләре, мәчетләрнең күп булуы булачак уку урынын сайлаганда үз ролен уйнады, дип аңлата Омар. Елдана өчен дә югары уку йортын сайлаганда мөселман факторы мөһим була. Өстәвенә, Казан аңа туган шәһәре Алматыны хәтерләтә.

Казанга укырга килү өчен тагын бер җитди сәбәп – алар икесе дә, Казан медицина вузы дипломы Россиядән читтә дә популяр, ди. Чөнки җәмәгать эшләре, әлбәттә, яхшы, шулай да алар өчен иң мөһиме – медицина өлкәсендә һөнәри карьера. Омар, мәсәлән, USMLE имтиханын тапшыруга җитди әзерләнә башлаган, аны кайбер чит илләрдә табиб булып эшләү өчен тапшырырга кирәк. Ул АКШта яисә Күвәйттә ординатура үтү турында уйлый. КДМУның табиб дипломы белән бу хыялын тормышка ашырып булачагына ышана. Өстәвенә, чит ил студентлары факультетында уку тулысынча инглиз телендә бара, бу чит илләрдәге эш бирүчеләрдә Казан дипломына ышанычны тагын да ныгыта. Хәер, алай да...

– Россиядә дә ординатура программалары бик яхшы, – дип елмая ул. – Миңа шулай ук РКХндә практика узу ошады, бик яхшы хастаханә!

Кыскасы, киләчәккә планнарын ул ахырына кадәр уйлап бетермәгән әле.

Елдана да Россиядә табиб булып эшләргә каршы түгел. Шунысы кызык: алар икесе дә хирургия белгечлеге турында хыяллана. Һәм икесе дә аңлый: бүген табиб гел белемен арттырып торырга тиеш, дипломлы

Казахстан кызы Елдана Россиядә табиб булып эшләргә каршы түгел.

белгеч булгач та. Һәм икесе дә шуңа ышана: киләчәктә һөнәри яктан камилләшү өчен алар Казанда ук ышанычлы белем алачак.

УНИКАЛЬ КАЗАН

Казан федераль университетында йөз илдән ун мең ярымнан артык чит ил студенты укый. Күпчелеге – Кытай, Төрекмәнстан һәм Үзбәкстаннан. Чит ил студентлары арасында өч иң популяр университет бүлекчәсе арасында Халыкара мөнәсәбәтләр институты (ИМО) да бар.

– Уку урынын сайлаганда, без Халыкара мөнәсәбәтләр институтына тукталдык. Чөнки танышларыбыздан халыкара мөнәсәбәтләргә нәкъ менә Казанда яхшы өйрәтәләр, дип ишеттек, – ди Кытай кызы Чжэн Зыинг. Ул ИМОның беренче курсында халыкара ягулык-энергетика куркынычсызлыгы белгечлегенә укый.

Гомумән, Казан аның тормышында быел гына пәйда булмаган. Эш шунда ки, берничә ел элек бирегә аның әти-әнисе эшкә килгән. Шуңа күрә Зыинг хәтта мәктәпне дә Татарстан башкаласында тәмамлый, Россия укучылары кебек үк БДИ тапшыра.

Әлбәттә, мәктәптән соң туган иле Кытайда да укырга мөмкин була. Ләкин Казан аңа ошый, чөнки монда... бик тыныч.

– Кытайда тормыш агышы куәтле, артык киеренке, – ди Зыинг. – Мәктәп укучылары анда сигездән дүрткә кадәр укый, ә аннары төн уртасына кадәр өй эшләрен әзерли. Һәм барысы да Россиядәге БДИның аналогы булган чыгарылыш имтиханы өчен бик борчыла, чөнки бездә конкуренция бик югары!

Мәскәүдә уку да уңайсыз булыр иде, анда да ыгы-зыгы көчле, дип саный Зыинг.

– Ә Казан – уникаль шәһәр! – ди героебыз.

Ул Казан Кремле буйлап йөрергә һәм Бауман урамында музыкантларны тыңларга ярата. Аңа шулай ук өчпочмак белән кыстыбый ошый. Бу гаҗәп түгел – бу ризыкларны кем генә яратмый икән!

Казанның уникальлеге шәһәрнең мультимәдәнилегендә күренә, дип саный студент кыз. Әтисе кытайлы, ә әнисе Кытайда үскән кореялы булган кызга милләтләр, телләр һәм диннәрнең үзара үрелеп яшәве бик аңлаешлы. Сүз уңаеннан, мультимәдәниятлелек ул укыган университет төркеме турында да: кытайлар, таҗиклар, колумбиялеләр, вьетнамлылар, төрекләр бергә укый. Кайвакыт бер-беребезне аңлау өчен онлайн-тәрҗемәчегә яисә ишарәләр теленә мөрәҗәгать итәргә туры килә, дип көлә Зыинг. Шуңа күрә алар булачак халыкара мөнәсәбәтләр белгечләре дә, алар башка телдә сөйләшүче кешеләрне аңларга өйрәнергә тиеш!

– Гомумән, безнең институтның Чит ил студентлары ассоциациясенә 51 ил вәкиле керә, – дип сөйли Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры урынбасары Альбина Имаметдинова. – Кытайдан бездә ике йөздән артык студент укый. Кытайның Казандагы Генераль консуллыгы белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез (сүз уңаеннан, аның барлык рус телле хезмәткәрләре – бездә укыган белгечләр). Шәһәрдә Кытай мәдәнияте көннәрен үткәрәбез, Ай яңа елын һәм Көз уртасын бәйрәмен (Көнчыгыш Һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия халыкларының традицион бәйрәме – ред. иск.) билгеләп үтәбез.

Зыинг, беренче ел гына укыса да, мондый чараларны студент тормышындагы бик мөһим нәрсәләр кебек кабул итә. Бәйрәмдә курсташлары каршында кытайча җырлавы, Кытай Яңа елында якташлары белән бергә дусларын махсус ай прәннекләре белән сыйлавы турында сөйли. Хәер, башка халыкларның бәйрәмнәре дә аның хәтерендә калган. Мәсәлән, Нәүрүз. Яисә төрле илләрдә Гашыйклар көнен бәйрәм итүгә багышланган кичә – бу бәйрәм һәркайда үзенчәлекле үтә икән. Кытайда, мәсәлән, мондый көнне өч тапкыр билгеләп үтәләр: 14 февральдән тыш, 7 июльдә (Ай календаре буенча) һәм 20 майда (чөнки бу датаның әйтелеше «Мин сине яратам» фразасы яңгырашына охшаш).

– Халыкара мөнәсәбәтләргә нәкъ менә Казанда яхшы өйрәтәләр, дип ишеттек, – ди Халыкара мөнәсәбәтләр институтының 1 нче курс студенты, Кытай кызы Чжэн Зыинг.

Беренче курс студенты буларак, Зыинг әлегә университеттан соң кайда эшләячәген күз алдына китерә алмый. Россия дипломы белән туган илендә эш табу авыр булмаячагына ышана, чөнки аның КФУны тәмамлаган танышлары бар, алар хәзер Кытайда яхшы эшләрдә эшли.

– Бәлки, ул безнең институтта кытай телен укытыр, – дип, өметләре белән уртаклаша Альбина Имаметдинова. – Кытай белеме – институтыбызның иң популяр юнәлеше, кытай телен бездә 1700 кеше өйрәтә.

Чжэн Зыинг әлегә бу сүзләргә җавап итеп елмая гына. Ләкин кем белә...

Казан халыкара мәктәбе

МЕЖДУНАРОДНАЯ ШКОЛА КАЗАНИ

Идел буенда бердәнбер халыкара мәктәп

- БДИга да, халыкара имтиханнарга да әзерлибез
- Бөтен фәннәр инглиз телендә укытыла
- 10 илдән 40 тан артык укытучы

Кабул итү сораулары буенча тел.: +7 (843) 204-12-81

3 яшьтән 18 яшькә кадәр

Федосеевская урамындагы кампус

Федосеевская ур., 52

Мәүлетов урамындагы кампус

Мәүлетов ур., 5

Казанда чит илдәгечә белем ал

Халыкара аккредитация:

ib Diploma Programme

ib Middle Years Programme

ib Primary Years Programme

www.iskazan.com

Лицензия на осуществление образовательнгой деятельности №8386, серия 16Л01 №0004400 от 23.06.2016. РЕКЛАМА

Ата-анага баласы укыйсы мәктәпне сайлау җиңел түгел. Балаларына киләчәктә үзебездә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы мөмкинлекләр бирерлек югары уку йортын, эшчәнлек юнәлешен, эш урынын һ.б.ларны алдан ук сайлап куярга теләүчеләр өчен бигрәк тә. Бөтен кеше дә балигъ булмаган баласын чит илдәге пансион-мәктәпкә озатырга әзер түгел. Әмма бу халыкара дәрәҗәдәге урта белем турында онытырга кирәк дигәнне аңлатмый. Вариантларның берсе – Россиядә ачылган халыкара мәктәп.

«БАЛАЛАРЫБЫЗ ЭШЛИ БЕЛӘ, УҢЫШНЫҢ КАДЕРЕН АҢЛЫЙ ҺӘМ ТОРМЫШКА ӘЗЕР»

Казандагы Халыкара мәктәп директоры Нияз Гафиятуллинга 5 сорау

– Халыкара мәктәп нәрсә ул һәм анда нинди белем бирү системасы гамәлдә, шул хакта сөйләсәгез иде?

– Мәктәп халыкара оешма аккредитациясенә ия, анда белем чит телдә бирелә, шул чит телдә сөйләшүчеләр эшли һәм чит ил балалары укый ала.

Без дөньяда иң динамик үсештә булган, универсаль, заманча IB-программага нигезләнеп эшлибез.

Ул өч өлешкә бүленә: башлангыч мәктәптә (3–11 яшьләрдә) төп игътибар балаларда дөньяның гомуми картинасы турында күзаллау тудыруга бирелә; урта мәктәптә (12–16 яшьләрдә) төрле предмет юнәлешләренә басым ясала; өлкән сыйныфларда (17–18 яшь) тирәнтен махсуслашу һәм балага аеруча кызыклы предметларны өйрәтү алып барыла.

Мәктәпне тәмамлаганда, чыгарылыш сыйныф укучысының үзе сайлап алган өлкәдә уңышка ирешү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләре генә түгел, дөньяның теләсә кайсы вузына укырга керү мөмкинлеге дә булачак.

– Укытучыларыгыз кайсы илләрдән?

– Хәзер штатта дөньяның 10 нан артык иленнән 30 га якын чит ил укытучысы эшли.

Киләсе елда без командабызны АКШ, Бөекбритания, Канада, Яңа Зеландия, Көньяк Африка, Португалия, Мисыр, Сербия һәм Канададан 10–12 белгечкә баетырга ниятлибез.

– Сезнең мәктәпкә хас төп үзенчәлекләр нидән гыйбарәт?

– Үзенчәлекләр арасында түбәндәгеләрне аерып күрсәтәсем килә:

• бәяләү системасы – балаларда билге өчен түгел, ә кызык булганга уку теләге булдырырга тырышабыз;

• программа тулысынча инглиз телендә;

• укытучыларга үзләре яхшырак дип санаган укыту режимын сайларга мөмкинлек бирә торган мәктәп инфраструктурасы.

Шулай ук елның башында һәм ахырында без уку-укытудагы ниндидер проблемаларны башлангыч стадиядә ачыклау яки үсеш динамикасын күзәтү максатында укучыларга академик сынау-тикшерүләр үткәрәбез.

Безнең максат белем бирү генә түгел, ә балаларны тормышта мөһим булган нәрсәләргә өйрәтү: командада эшләү, үзеңне һәм үз проектыңны тәкъдим итә белү, заманча интерактив җайланмалардан файдалана, үз фикереңне белдерә белү һ.б.

– Укучылар нинди өстәмә дәресләргә йөри ала?

– Балалар 5 яшьтән башлап түгәрәкләргә йөри. Бу очракта сүз уйлап, җентекләп әзерләнгән дәресләр турында бара: башлангыч мәктәптә бала үз яшенә күрә төрле яктан үсәргә, ачылырга тиеш. 3 сыйныфтан 12 сыйныфка кадәр алар үзләренә кызык юнәлешне сайлый.

Барлык дәресләр өч юнәлешкә бүленгән: академик (IT-юнәлеш, робот техникасы, икенче тел, өстәмә инглиз теле дәресләре, әдәби клуб, шахмат), спорт (баскетбол, футбол, гольф, өстәл теннисы һәм зур теннис, кыяга менү, бию), сәнгать (рәсем сәнгате, керамика, кул эшләре, музыка мәктәбе, вокал).

– Мәктәпкә ничек укырга кереп була?

– Математикадан (инглиз телендә), рус һәм инглиз телләреннән тест, психолог диагностикасын үтәргә кирәк.

Әгәр бала тестны уңышлы узмаган икән, без кайда нәрсәне ныгытырга, тирәнәйтергә кирәклеге турында һәрвакыт киңәшләр бирәбез һәм күпмедер вакыттан соң яңадан чакырабыз.

Монда сүз балаларны сайлап алу һәм селекция турында бармый, безгә «уңышсызлык» ситуациясен күрми калмау һәм баланың мондый программага әзерме-юкмы икәнлеген аңлау мөһим.

204 12 81
iskazan.com
Мәүлетов, 5; Федосеевская, 52

Фото Казандагы Халыкара мәктәптән алынды. РЕКЛАМА

HALAL LIFESTYLE* – КӨНДӘШЛЕКЛЕ ӨСТЕНЛЕК УЛ

Әхмәт Шакиров

Татарстанның хәләл индустрия базары – 100 дән артык җитештерү ул, шулардан ике дистәсе экспортка тәгаенләнә. Былтыр республикадан хәләл продукцияне экспортка чыгару күләме 6,5 миллион доллардан артып киткән. 2022 елда Татарстаннан чит илләргә җибәрелгән агросәнәгать комплексы продукциясе фонында хәләл экспорт өлеше әлегә ике проценттан да кимрәк. Хәер, бөтен нәрсә чагыштырып караганда ачык күренә.

Әйе, Татарстан хәләл товарларының чит илләргә җитди экспансиясе хакында сөйләргә иртәрәк әле, әмма шулай да статистика тотрыклы үсеш күрсәтә. Былтыр хәләл продукцияне экспортка чыгару күләме аннан алдагы елдан 1,5 миллион долларга артып киткән, 2020 елда әлеге күрсәткеч – 2,5 миллион долларга, 2019 елда исә нибары 0,3 миллион долларга гына тәңгәл булган. Дөньядагы хәләл продукция базарының еллык 15 процентлы үсеше белән чагыштырганда, Татарстан экспорты арту динамикасы шаккаткыч. Уйланылган стратегиядән башка мондый ыргылыш мөмкин булмас иде, моны ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында да раслыйлар.

– Без хәләл юнәлешен соңгы ике-өч елда гына актив үстерәбез әле, – ди Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров. – Быелгы бурыч – 8 миллион долларлык хәләл продукцияне экспортка чыгару. Кая таба барырга, нинди тармакларга аеруча игътибар бирергә кирәклеген аңлап, сату өчен перспективалы базарларны ачыкларга тырышабыз. Беренче чиратта, БДБ илләре, гарәп илләре белән хезмәттәшлекне үстерүне планлаштырабыз – анда хәләл туклану продуктла-

*Halal Lifestyle - хәләл яшәү рәвеше (инглиз теленнән тәрҗемә)

Фотолар: tatar-inform.ru, islamicbanks.ru

рына ихтыяҗ һәрвакыт югары һәм тотрыклы үсеш динамикасына ия.

Дөрес сайланган юнәлешләр нәтиҗә бирә, әмма бу тынычлану өчен сәбәп була алмый әле. Базарның потенциалы моннан күпкә баерак. Россия–Гарәп эшлекле киңәшмәсенең 12 нче сессиясе кысаларында игълан ителгәнчә, глобаль азык-төлек базарында хәләл туклану продуктларының өлеше 15 процент тәшкил итә. Ә Татарстаннан чит илләргә җибәрелгән агросәнәгать комплексы продукциясенең тулаем күләмендә, хәтерләсәгез, хәләл экспорт өлеше әлегә ике проценттан да кимрәк. Шуңа нәтиҗәләрне үзегез ясагыз.

Биредә сүз Татарстан турында гына бармый. Киләсе елга дөньядагы хәләл продукция базары күләме 3,5 триллион долларга җитәргә мөмкин. Белгечләр әйтүенчә, әлеге үсешнең төп сәбәбе – мөселман илләрендә халык саны арту. 20 миллионнан артыграк мөселман яшәгән Россияне әлеге базарда статист роле генә канәгатьләндермәстер, мөгаен.

МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫ

Дөньяның хәләл-индустрия базары мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен аңлау өчен иң мөһиме нәрсә соң? Хәләл – катгый мөселман кануннары буенча әзерләнгән туклану продуктлары гына түгел ул. «Без хәләл яшәү рәвеше турында сөйлибез, – дигән иде моннан дүрт ел элек ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясендә республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов, конкрет бурыч куеп. – Бу өстенлекле юнәлеш, чөнки без ислам дине тотыла торган республика бит. Без әлеге көндәшлекле өстенлектән файдалана алыр идек».

Хәләл, чыннан да, яшәү рәвеше ул, бөтен ислам икътисады аның нигезендә төзелә. Хәләл туклану продуктларын җитештерү – бер юнәлеш кенә. Барысын да яхшылап өйрәнмичә һәм максатка баруның конкрет юлларын билгеләмичә, көндәшлекле өстенлектән файдалып калырга тырышу – өметсез шөгыль. Хәләл индустрия ныгысын һәм базарларны фаразларда гына түгел, чыннан да үзләштерсен өчен, Татарстанда хәләл яшәү рәвешен үстерү буенча Halal Lifestyle юл картасы эшләнгән, аны ТР Хөкүмәте раслаган.

Halal Lifestyle – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларның тулы бер комплексы ул. Хәтерегезгә төшерәбез, әлеге төркемне РФ Президенты Владимир Путин күрсәтмәсе буенча 2014 елдан бирле Татарстан Республикасы башлыгы

– Бүген хәләл – ул яшәү рәвеше һәм тулы бер индустрия, – дип белдерде ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин Russia Halal Expo күргәзмәсе турында: «Хәләл – яшәү рәвеше ул».

Рөстәм Миңнеханов җитәкли. Юл картасы йогынтысы даирәсенә хәләл туристлык, хәләл җитештерүләр, мода, финанслар, IT һәм медиа керә. Максатлары – мөселман туристлары килүен арттыру, Татарстан һәм бөтен ил халкын хәләл яшәү рәвешенә күнектерү, хәләл стандартлары буенча продукциянең товар әйләнешен арттыру, Татарстандагы хәләл брендларын Россиядә һәм чит илләрдә популярлаштыру, шулай ук Татарстанда шәригать кануннары буенча база финанс IT-инфраструктурасын төзү.

Юл картасы пунктлары үтәлә барган саен, ирешелергә тиешле ориентирлар да билгеләнә бара. Аерым алганда, Татарстанга килүче мөселман туристлары саны өч тапкыр ишәячәк һәм 150 мең кешегә җитәчәк; модалы брендларны Россиядә дә, чит илләрдә дә сатудан кергән акча артачак; ә Казан, әлеге документтан күренгәнчә, ислам дөньясының IT-башкаласы статусына ирешәчәк – бу төбәктә шәригать нормалары буенча база финанс IT-инфраструктурасы төзелү нәтиҗәсендә мөмкин булачак.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: KazanSummit икътисадый саммитында традиционга әйләнгән һәм KazanForum кысаларына бик җайлы кереп урнашкан Russia Halal Expo күргәзмәсе (биредә хәләл индустриянең иң перспективалы һәм иң яхшы үрнәкләре тәкъдим ителә) – Halal Lifestyle яшәү рәвешен алга этәрүнең мөһим инструментларыннан берсе. Тулаем алганда исә, юл картасы хәләл яшәү рәвешен үстерү буенча төрле тармакларда эшнең 60лап төп юнәлешен билгели.

– Татарстан мисалында без ислам бизнесы белән үзара хезмәттәшлек итүнең гамәли механизмнарын җайларга омтылабыз, – дип аңлата Татарстан Рәисе Рөстәм Миңне-

– 2022 елда Казанда Саклык банкының ислам банкингы офисы ачылды. Әлеге пилот проект кайсы хезмәтләргә ихтыяҗның аеруча зур булуын ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

ханов. – Ислам икътисадын үстерү өлкәсендә зур перспективалар ачыла. Аерым алганда, хәләл туклану, хәләл туристлык, хәләл медицина индустрияләре үсә.

Бүген инде кибет һәм супермаркет киштәләрендәге хәләл ит һәм казылык, сөт, сөт ризыклары, сырлар, кондитер эшләнмәләре, хәтта йөзем согы белән генә беркемне дә гаҗәпләндереп булмый... Татарстанда җитештерелгән һәм хәләл туклану продуктларының дөнья базарында көндәшлеккә сәләтле продуктлар ассортименты бик тиз арта. Аның кадәр үк тиз булмаса да, шулай ук әзлекле рәвештә медицина, туристлык, банк, финанс өлкәләрендә дә хәләл хезмәтләр һәм товарлар саны ишәя бара.

– Республикабызда инде 16 оешма 16 юнәлештә шәригать буенча финанс хезмәте күрсәтә, – ди ТР Инвестицияле үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Гамәлдәге законнар кысаларында шәригать кануннары буенча хезмәт күрсәтә торган компанияләр һәм банклар саны арта. 2022 елда Казанда Саклык банкының ислам банкингы офисы ачылды. Әлеге пилот проект кайсы хезмәтләргә ихтыяҗның аеруча зур булуын ачыкларга мөмкинлек бирәчәк. Киләчәктә алар мондый офисларны бөтен ил буенча ачарга ниятли. Ак Барс Банк актив эшли. Инде хәзер үк республикада товар, фатир, транспорт чарасын шәригать кануннарын бозмыйча сатып алырга мөмкин; шулай ук җиһаз сатып алу өчен финанслар, инвестицияләр, акча һәм кыйммәтле кәгазьләр белән инвестицияләү рөхсәт ителә; банк картасы, ипотека алырга, рөхсәт ителгән акцияләрне сатып алырга була. Тагын акцияләрне скринингла у, килешүне шәригать кануннары һәм Россия законнарына ярашлы рәвештә төзү һәм тикшерү буенча консультацияләр, пенсия продуктларына шәригать аудиты һәм башка хезмәтләр тәкъдим ителә. Һәм халыкка күрсәтелә торган барлык бу хезмәтләр саны арта бара. Ихтыяҗ тәкъдимне тудыра – әгәр дә әлеге хезмәтләргә ихтыяҗ булмаса, бернәрсә дә барып чыкмас иде.

ХӘЛӘЛ – КАНУННАР ТАЛӘБЕ УЛ

Товардагы «хәләл» тамгасы һәрвакытта да аның ислам нормаларына туры китереп әзерләнүен аңлатамы? Тиешле сертификат сыйфат һәм дөреслеккә дәлил булып тора. Ул сатып алучының чыннан да хәләл продукт сайлавынраслый. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлары комитеты – атап кителгән тармакта иң абруйлы һәм принципиаль сертификат бирүче органнардан берсе.

Сертификат бирүче органнар эшенең күләме шаккатыргыч: Россиядә хәләл продукция индустриясе әйләнеше елына 100 миллиард сумга якын тәшкил итә. «Хәләл» стандартлары комитеты реестрында гына да сертификат алган 196 предприятие, оешма һәм эшкуар теркәлгән (мәгълүматлар 2022 ел азагыныкы – ред.иск.). Шул ук вакытта бизнес-структураның әлеге сертификатны алу теләге генә нәтиҗәнең уңай булачагын аңлатмый әле. Былтыр тиешле контрольне үтәргә теләп комитетка гариза юллаган 200 предприятиенең 41 енә генә сертификат бирелгән: ислам

индустриясенең катгый нормаларына ярашу бик җиңел түгел шул.

Әмма ихтыяҗ һәм хәләл базары потенциалы төрле тармактагы компанияләрне үз предприятиеләрен һәм технологияләрен махсус таләпләргә яраклаштырырга мәҗбүр итә, гәрчә бу очракта өстәмә чыгымнар таләп ителсә дә. Соңгы айларда сертификатлар алучылар арасында азык-төлек, көнкүреш химиясе, косметика җитештерүчеләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре, кунакханә һәм шифаханәләр, туристлык һәм медицина хезмәте күрсәтә торган оешмалар бар. Ә эшли башлаганнан бирле исә Комитет бөтен Россия буенча 1190 предприятиегә сертификат биргән.

Комитетның эш принциплары үзгәрешсез. Аерым алганда, контроль аудит үткәргәнче, аның белгечләре оешмаларга ислам кануннары буенча җитештерү тәртибе турында тәфсилле консультация бирә. Аннары – тикшерү. Биредә бөтен нәрсә исәпкә алына: җитештерү куәтләре, технологияләр, азык өстәмәләре, ингредиентлар, чимал сатучылар... Тикшергәндә Комитет белгечләре һәр продуктның азык-төлек куркынычсызлыгы нормаларына һәм җитештерүдә санитария-эпидемиология кагыйдәләренә туры килүен өйрәнә. Комитет ризыктагы хәрам компонентларны гына түгел, бәлки продуктның тәңгәллек декларациясе булу-булмавын да тикшерә. Җитештерү чылбыры продуктның хәләл статусын предприятиегә кергән чималдан алып әзер ризык кулланучыга җибәрелгәнче сакларга сәләтле булырга тиеш.

Предприятие тиешле таныклыкны алгач та, эш тукталмый әле. Киләчәктә дә продуктның сыйфаты, аның хәләл статусы җитештерүченең намусыннан гына тормый. Комитет вәкилләре сертификат алган оешмаларда даими аудит үткәрә. Бу, мәсәлән, кеше факторы аркасында килеп чыккан җитешсезлекләрне тиз арада ачыклау һәм төзәтү мөмкинлеген бирә. Хәзерге вакытта Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлары комитетында биш шәригать белгече даими эшли, шулай ук җитештерүләрдә 15 контролер тикшерә. Аларның эшендә иң мөһиме – продукциянең хәләллеген өйрәнү мәсьәләләрендә гаделлек, дип саныйлар Комитетта. Ни дисәң дә, хәләл – кануннар таләбе бит ул.

ТАТАРСТАН ХӘЛӘЛ-ХАБКА ӘЙЛӘНЕРМЕ?

Дөньядагы хәләл продукция базары бик тиз үсә. Экспертлар ышандыруынча, тагын ике елдан ул барлык җитештерелгән товарларның кимендә 20 процентын тәшкил итәчәк. Фаразлар буенча, мөселманнар саны 2050 елга планетада яшәүчеләрнең 30 процентын тәшкил итәчәк. Димәк, киләчәктә бу базар тагын да тизрәк үсәчәк әле. Россия бизнесының үз алдында ачылган мөмкинлекләрдән файдаланмый калырга хакы юк, гәрчә бу өлкәдә теләк һәм тәкъдим ителә торган товарларның сыйфаты гына әле җитәрлек шарт булмаса да.

Илебез продукциясен чит ил хәләл базарларына чыгару өчен төп һәм мәҗбүри шартлардан берсе – сертификатлаштыру. Алай гына да түгел, сертификат кына җитми, ул конкрет илләрнең халыкара сертификат бирүче органнары тарафыннан танылырга да тиеш.

– Әгәр продукцияне ислам илләренә экспортка чыгару бурычы куела икән, Россия Мөфтиләр шурасы каршындагы «Хәләл» Халыкара стандартлаштыру һәм сертификатлаштыру

үзәге (ХССҮ) сертификатыннан башка бернәрсә дә эшләп булмаячак, – ди ХССҮ директоры Айдар Газизов. Аның әйтүенчә, әлеге структура, продукцияне ислам илләренә экспортка чыгарырга булышып, иң эре федераль җитештерүчеләргә хезмәт күрсәтә. Әгәр инде Татарстан предприятиесенең экспорт куәте юк икән, ХССҮ үз комитетларына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә – бу якынрак та, контрольдә тотуы да җиңелрәк.

Чынлыкта исә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте «Хәләл» стандартлары комитетының экспорт потенциалы башкаладагы коллегаларыныкыннан бер дә ким түгел. Күптән түгел макарон эшләнмәләр һәм камыр ризыклары җитештерүче Россиянең танылган бренды үз продукциясен Согыд Гарәбстанында сата башлаган – Якын Көнчыгыш базарына чыгарга Татарстан комитеты сертификаты булышкан. Предприятие ТР Диния нәзарәте «Хәләл» стандартлары комитеты биргән сертификатлы 13 нче экспортчыга әйләнгән. Бу аның халыкара даирәләрдә танылуына иң шәп дәлил булып тора.

Хәер, сертификат бирә торган органнар арасында нindидер көндәшлек тә бар икән. Ул бик дипломатларча алып барыла: бернинди маркетинг сугышлары һәм бер-берсенең клиентларын җәлеп итү күренешләре күзәтелми. Ике як арасында имзаланган «илдәге хәләл индустрияне үстерү максатларында» үзара аңлашу турында меморандум да моңа дәлил булып тора.

KazanSummit-2021 саммитында ук Ислам илләренең стандартлаштыру һәм метрология институты (SMIIC) генераль секретаре Ихсан Овют билгеләп үткәнчә, хәләл продукция сәүдәсендә төп проблема – теге яки бу стандартларны танудагы милли үзенчәлекләр ул.

– Мин, без бергә, бердәм булырга тиешбез, дип саныйм. Һәм, Аллаһ теләсә, SMIIC эшендә яңа документ кабул ителер, – дип вәгъдә биргән иде Ихсан Овют. – Бу үзара танылган аккредитация һәм сертификацияләрдән билгеле бер пирамида булыр. Без шәхси мәнфәгатьләр белән чикләнергә тиеш түгел, безнең уртак мәнфәгатьләребез булырга тиеш.

Үзара тану пирамидасы төзелгән вакытта исә Россиядәге хәләл индустриясен үстерергә теләүчеләр дә вакытларын бушка уздырмый. «Хәләл» стандартлары комитеты халыкара сертификатлаштыру органнары белән сертификатларны үзара тануга багышланган эшлекле очрашуларны даими үткәреп тора. Петербург халыкара икътисад форумында ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Аккредитацияләү федераль хезмәте җитәкчесе Назарий Скрыпник белән хезмәттәшлек турында килешү имзалаган: төбәк «Хәләл» индустриясен көйләүгә, мәгълүмат һәм экспертлар фикерен алмашуга булышачак. Бөтендөнья хәләл көне рәисе Мөхәммәд Җиннәнең Татарстанны мөселман һәм мөселман булмаган илләр арасында хәләл-хаб ясау идеясе дә өйрәнелә.

UNWHD оешмасы җитәкчесе Мөхәммәд Җиннә Рөстәм Миңнехановка Бөтендөнья хәләл көне ачкычын тапшыра.

MLK GROUP: ИЛНЕ АШАТЫРБЫЗ, БЕРКЕМ ДӘ АЧ КАЛМАС!

MLK Group – Россиядә сөт эшкәртүче иң зур компанияләрнең берсе. Компания традицион сөт продукциясе белән бергә, әчетелгән сөт эшләнмәләре җитештерү, шулай ук йомшак һәм эретелгән сырлар, спредлар һәм коры сөт чыгару буенча да махсуслаша.

MLK Group компанияләр төркеме «Милково», «Бәрәкәтле» һәм «Молочная фамилия» кебек сөт брендларына ия.

MLK Group – бүген Россиядә сөт продукциясе җитештерү һәм сату буенча әйдәп баручы компанияләрнең берсе. Компанияләр төркеме 2021 ел йомгаклары буенча Россиянең иң эре сөт һәм сыр җитештерүче лидерлар унлыгына* керә. Бүгенге көндә MLK Groupның өч җитештерү мәйданчыгы: Удмуртиядәге иң өлкән флагман «Ува-молоко» заводы һәм Татарстандагы «Касымовский» һәм «Апастовский» сөт комбинатлары тәүлегенә 900 тоннага якын сөт эшкәртә.

Апас сөт комбинаты – Казаннан якынча 100 км ераклыктагы предприятие. 2019 елда стеналары гына диярлек калган ташландык мәйданчыкны 44 млн сумга сатып алалар. Предприятиегә инвестиция планы якынча 700 млн сум тәшкил итә.

Ремонт эшләре 2020 елның гыйнварында башлана, 2021 елдан яңа Европа җиһазлары урнаштырыла: Lekkerkerker Dairy & Food компаниясенең сыр линиясе һәм «Вздухоторг» компаниясенең VRA-4 заманча киптерү җайланмасы монтажлана.

Заводның Татарстан Республикасының иң яхшы 3 сөт мәйданчыгына әйләнү перспективасы бар, эшкәртү куәте тәүлегенә 450 тонна чимал сөткә җитәчәк. Сыр өчен Татарстанның югары технологияле фермаларыннан сайлап алынган чимал кулланылачак, чөнки сөт комбинаты чи сөт сыйфаты буенча лидер районнарның берсендә урнашкан.

* *Milknews һәм Dairynews тарафыннан 2021 ел азагына алынган мәгълүмат*

Фотолар MLK Group компаниясенең матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

Светлана Кузьмичёва,
MLK Group компаниясенең үсеш буенча директоры:
– Безнең компанияләр төркемендә бизнесны оештырырга ярдәм итәрлек, җаваплы, бай тәҗрибәгә ия бик яхшы команда тупланды. «Ува-молоко»да тупланган заманча көчле матди-техник базага таянып, без бик озак эшли алабыз әле. «Апастовский» дип аталган яңа сөт комбинаты техниканың соңгы сүзе буенча җиһазландырылган – бу безгә озак вакытка җитәрлек зур үсеш резервы. Стратегия, коллектив, техник тәэмин ителеш һәм, әлбәттә, сөт – без боларга таянып эшли беләбез. Һичшиксез, илне ашатырбыз, беркем дә ач калмас!

Заводны сынау рәвешендә эшләтеп җибәрү агымдагы елның апрелендә узды.

Җайланма-җиһазлар – көйләү-эшләтеп җибәрү этабында. Линияләрнең куәте тәүлегенә 40 тонна ярымкаты «Голланд» сыры һәм 20 тонна коры сүл (эремчек суы) җитештерү мөмкинлеге бирәчәк.

Моннан тыш, заводта Татарстанда танылган «Бәрәкәтле» бренды продукциясенең башка ассортиментын җитештерү планлаштырыла.

«Бәрәкәтле» – «файдалы», «кадерле» дигәнне аңлата. Брендның төп идеясе дә – табигыйлек, сафлык. MLK Group милли традицияләрне саклау мөһим дип саный.

Бренд ассортиментында классик сөт продукциясе (сөт, май, эремчек, каймак һ.б.лар), шулай ук татар милли продуктлары: корт, тан, әйрән һәм башкалар бар. Брендның кырыктан артык төрдәге ризыгы бар.

Продукция тулысынча хәләл ризык таләпләренә туры килә. Бу «чиста, файдалы ризык»ның сыйфат билгесе: тәмне көчәйтүче һәм зарарлы буяу матдәләре юк, бары тик табигый ингредиентлар гына. Җитештерүнең барлык этапларында сыйфатка һәм гигиена нормаларына аерым игътибар бирелә.

Предприятиедә 81 яңа эш урыны ачылачак.

Заводны рәсми рәвештә эшләтеп җибәрү июньнең беренче декадасына планлаштырылган.



** хисапка алынган берәмлек

СӘЛАМӘТЛЕК ЭЛИКСИРЫ, ЯКИ IN «ЭМИЗ» VERITAS

Биш ел эчендә «ЭМИЗ» (русча «яшьлек һәм сәламәтлек эликсиры» дигән сүзләрдән кыскартып ясалган) уникаль бренды Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә популярлык казанды. Һәм компания продукция линейкасын шикәр һәм буягычларсыз эшләнә торган табигый составлы яңа эчемлекләр белән тулыландыруын дәвам итә. «ЭМИЗ» компанияләр төркеме хуҗасы Раил Фазылҗанов, тиз булмаса да, эзлекле үсешне күздә тоткан мондый юлның үзен киләчәктә тотрыклы итеп күрергә теләгән һәр компания өчен мөһим, дип саный. Бүгенге әңгәмәбез – «ЭМИЗ»нең уникальлеге, табигый, чиста продуктлар җитештерү һәм аларның файдасы турында.

Караңгы пыяла шешәдән үтә күренмәле бокалга, тирә-якка тәмле хуш ис таратып, куе кызыл төстәге эчемлек ага. Аның әчкелтем-баллы тәме төсмерләргә бай – виноград тәме дә бар, шул ук вакытта гранат кебек авызны камаштырып та җибәрә.

Каберне Совиньон, Мерло, Саперави... Составында полифеноллар микъдары ягыннан абсолют чемпионнарның берсе булган эликсир нигезен әлеге кара виноград сортлары тәшкил итә. Эчемлектәге гранат тәме нәкъ менә шулар белән бәйле.

– «Яшьлек һәм сәламәтлек эликсиры»ның тиңсезлеге нидән гыйбарәт соң?

– Виноград белән бәйле иң төп өстенлек – бу күп күләмдә полифеноллар булу. Кара виноград сортларында, аларның төшләрендә һәм тышчаларында иң мөһим полифенолларның берсе – ресвератрол бар.

Полифеноллар ирекле радикалларның зарарлы йогынтысын туктатырга һәм күзәнәкләрне зарарланудан сакларга ярдәм итә. «ЭМИЗ» эчемлеген мегаполисларда яшәүче һәр кешегә эчәргә киңәш итәргә мөмкин.

Менә шул рәвешле, эликсирыбызның кыйммәте аның шифалы һәм табигый составында, ачык һәм бай тәмендә булып чыга.

– Бу сезнең үз рецептыгызмы?

– Борынгы рецепт бар иде, ләкин без аңа үзебездән бер үзенчәлек өстәдек. Шуның нәтиҗәсендә безнең продукция күп яктан караганда уникальгә әйләнде. Безнең әлеге өстәмәбезгә һәм эликсирыбызга Россиядә дә, дөньяда да тиңдәш юк, дип уйлыйбыз. Әйе, рецептуралары нигезендә виноград төше булган эчемлекләр бар. Әмма безнең технология бераз башкарак. Бик нечкәлекләренә кереп тормыйча гына тасвирлап үтик: без виноградны туңдырабыз да бик шәпләп ваклыйбыз, аның төшләреннән, тышчасыннан, җимеш йомшагыннан һәм тәлгәшеннән барлык файдалы матдәләрне виноград согына тартып чыгарабыз. Ә бу сок, билгеле булганча, кеше организмы тарафыннан бик яхшы, 100% диярлек үзләштерелә.

– «ЭМИЗ» әзерләү өчен нинди дер үзенчәлекле виноград кулланамы?

– Әйе, без кара виноград сортларын гына кулланабыз, аларның да калын тышчалы һәм эре төшле иң кыйммәтлесен сайлыйбыз.

«ЭМИЗ» сәүдә йорты фотолары. РЕКЛАМА

«ЭМИЗ» – тулысынча алкогольсез эчемлек, чөнки җитештерүнең бер этабында да ул әчи алмый. Эликсирның «хәләл» статусын раслый торган сертификаты бар.

ДАРУЛАР ТӨП РИЗЫККА ӘЙЛӘНГӘНЧЕ, РИЗЫГЫГЫЗ ДАРУ БУЛСЫН.

Гиппократ

Без виноград сайлауга һәм аның сыйфатына, витамин һәм минералларны мөмкин кадәр күбрәк саклап калуга бик зур игътибар бирәбез. «ЭМИЗ»нең организм өчен файдасы бәхәссез, әмма шул ук вакытта теләсә нинди продуктны чама белән куллану тиешлеген истә тотарга кирәк. Безнең һәр эликсирыбыз сатуга тәфсилле аңлатма белән чыга.

– Былтыр сез яңа продукт – BAZR лимонадлары линейкасын җитештерүне җайга салдыгыз. Сатып алучылар аларны инде яратып та өлгерде. Һәркем бу эчемлекләрнең гадәти булмаган, көчле тәмен телгә ала...

– Бренд атамасының барлыкка килү тарихы да үзенчәлекле. 2021 елда республикабызга Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең азык-төлек һәм су иминлеге буенча дәүләт министры Мәрьям бинте Мөхәммәд әл-Мхәйри килгән иде. Һәм без Татарстан Хөкүмәте тарафыннан аның белән очрашуга чакырылган дүрт компаниянең берсе булдык. Мәрьям ханым «ЭМИЗ» продукциясенә игътибар итте һәм Дубайга күргәзмәгә чакырды, ләкин шешә формасын үзгәртергә киңәш бирде. Без шулай эшләдек тә. Ә лимонад өчен исем эзли башлагач, «базр» сүзенә тукталдык, бу сүз гарәпчә «виноград төше» дигәнне белдерә.

BAZR лимонадлары – заманча технологияләр һәм борынгы традицияләрнең кушылмасы ул. Составларында – табигый компонентлар, аларда буягыч матдәләр, хуш исләндергечләр юк, өстәп шикәр кушылмый.

2022 елда Чистай шәһәрендә лимонадлар җитештерә торган үз цехыбызны эшләтеп җибәрдек. Лимонадлар табигый продуктлар белән сәламәт туклануга йөз тоткан юнәлешебезне дәвам итә.

Виноград, җиләк, груша һәм киви кебек ачык тоемлана торган дүрт тәм шунда ук кәефне күтәреп, көч-дәрт өстәп җибәрә ала. BAZR лимонадлары сусауны бик яхшы баса һәм үзеннән соң үзенчәлекле татлы тәм калдыра. Тиздән тагын кайбер яңа тәмнәр белән сөендерербез.

Сатып алучыларыбызның географиясе киңәя. Хәзер безнең фирма продукциясен татарстанлылар гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә яшәүчеләр дә татып карый ала. Без инде Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан белән эшлибез.

Шунысын да әйтергә кирәк: без тагын да алга киттек. Хәзер эчемлекләргә бездә заказ биреп, аннары аларны үз брендларында сата торган партнёрларыбыз бар. Рецептура тулысынча безнеке, продукт та шул ук, кәгазе генә үзгәрә. Әмма партнёрлардан ниндидер аерым бер тәмле эчемлек эшләргә мөрәҗәгать килсә, без аны да эшләячәкбез! Бер генә нәрсә үзгәрешсез калачак, ул да булса – табигый ингредиентлар.

– Хәзерге вазгыятьтә «ЭМИЗ» брендын үстерүне ничек күзаллыйсыз, җитештерү планнарына төзәтмә кертергә туры киләме?

– Әлбәттә. Кулланучы һәрвакыт ниндидер яңа нәрсә көтә, ә хәзерге вазгыятьтә әле брендыбызны мөмкин кадәр арзанайту юнәлешендә дә үзгәрергә әзәрә. Без яңа ысуллар, тәкъдимнәр эзләүдән туктамыйбыз. Алар арасында импортны алыштыру проектлары да бар.

2022 елда «ЭМИЗ» эчемлеге «ПродЭкспо» халыкара күргәзмәсендә 2022 елның иң яхшы продукты дип танылa һәм алтын медаль белән бүләкләнә.

«ЭМИЗ» сәүдә йорты «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты була, «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасында җиңеп, аның «Сыйфат тәме» дип аталган югары бүләген яулый.

ЛАУРЕАТ 100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ 2022

2022 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

2018 елда нигезләнгән **«ЭМИЗ» КОМПАНИЯЛӘР ТӨРКЕМЕ** виноградтан эликсирлар һәм витаминлы катнашмалар җитештерә. 2019 елда Кырымда җитештерү эшен башлап җибәрә. 2020 елда ширкәт җитештерүнең һәм сатуның колачлы циклына күчә, Казанда экспорт өчен икенче җитештерү мәйданчыгы ача. 2022 елда Чистайда лимонадлар җитештерү эше җайга салына.

Элемтә өчен: **8 (800) 444-09-37, 8 (937) 778-09-37**
Сайт: **emiz.ru**. Эл. почта: **sales@emiz.ru**

KAZANFORUM–2023: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ

Җәмәгать киңлекләре өчен шәһәр җиһазлары һәм җайланмалары җитештерү буенча SIGN URBAN компаниясе хуҗасы Ләйлә Сафина «KazanForum-2023» икътисадый форумында хатын-кызларга кагылышлы нинди темалар күтәреләчәге, мөселман киемнәренең ни өчен эшлекле ханымнарга туры килүе турында фикер йөртә.

ИСЛАМ ФОРУМЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ТЕМАСЫ

– «KazanForum-2023» программасын өйрәнгәндә, анда хатын-кызлар тематикасына караган чараларның шактый күп булуын күрдем. Хатын-кызлар бизнесына, хәләл индустриягә караган бизнеска, шәригать стандартлары буенча сәламәтлек һәм матурлык өлкәләрендә бизнес оештыруга, ана һәм бала сәламәтлеген саклауга аерым игътибар бирелгән, сәламәтлек саклау технологияләре һәм яңалыкларына хатын-кызлар керткән өлешкә вакыт һәм игътибар күрсәтелгән...

Бу күркәм күренеш, безнең хатын-кызлар бизнесына әлеге белемнәр файдалы булыр, дип уйлыйм. Алар безгә, Татарстанның эшлекле ханымнарына, тагын да кирәгрәк булырга, үзебезне ачарга, бизнеска үзенчәлекле төсмер өстәп, аңа хатын-кыз рухын кертеп җибәрергә мөмкинлек бирәчәк.

НИ ӨЧЕН МӨСЕЛМАН КИЕМЕ ЭШЛЕКЛЕ ОБРАЗЛАРГА ЯХШЫРАК ТУРЫ КИЛӘ

– Ислам форумы ислам модасы трендларын игътибарсыз калдырмый. Һичшиксез Modest Fashion Day әдәпле мода фестиваленә барачакмын. Хатын-кыз мөселман костюмы – ул барыннан да элек гүзәл затларның чын матурлыгын ачу мөмкинлеге, ә бизәнү әйберләре аны нәзакәтлелек һәм затлырак итәргә булыша.

Эшлекле хатын-кызларга мөселман костюмы якынрак та, аңлаешлырак та – ул бер үк вакытта тыйнак та, затлы да. Нәфис һәм стильле мөселман киемен тулысынча яки өлешчә кулланып, төрле эшлекле образлар тудырып була. Зәвык булганда, мөселман бизәнү әйберләре һәм аксессуарлары ярдәмендә образларны дөрес яраштырырга мөмкин.

ТУГАНДАШ ХАЛЫКНЫҢ РУХЫН НИЧЕК СЕҢДЕРЕРГӘ

– Мөселман бизәнү әйберләре ярдәмендә генә түгел. Без күпмилләтле республикада яшибез, Татарстанда 173 милләт вәкиле яши, төрле халык бәйрәмнәре уздырыла... Татарстан халыклары дуслыгы – ул зур бүләк һәм республиканың казанышы.

Барлык этник, мәдәни, милли, үзенчәлекле әйберләрне яратам. Башка халыкларның бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карыйм. Гомумән милли киемнәр миндә соклану уята. Хәзер дизайнерларның милли киемнәрдәге, бизәнү әйберләрендәге стильләргә игътибар итүләренә, халык бизәкләрен һәм принтларын үз коллекцияләрендә куллануларына шатланам. Татар милли киемен рәхәтләнеп киям. Якут, үзбәк, казах, мордва, чуваш дизайнерларының этник һәм милли бизәкләр кертеп тегелгән заманча киемнәре бик ошый. Һәр деталь, орнамент, силуэт үзенчә яхшы. Ту-

Анастасия Алашеева фотолары. РЕКЛАМА

гандаш халыкларның рухы синең җаныңа үтеп керә кебек тоела.

НИ ӨЧЕН ӨЙДӘГЕ ҖЫЛЫЛЫК РЕЛИГИЯГӘ КАРАМЫЙ

– Милләтем буенча мин татар. Мөселман хатын-кызларының менталитетында татарларның милли традицияләре белән уртаклык зур, дип уйлыйм. Бүгенге заман хатын-кызы, социаль тормыштан тыш, гаиләгә, балалар тәрбияләүгә, өйдә җылылык тудыруга өстенлек бирә. Ничек кенә булмасын, болар барысы да һәр диндә бар. Мин замана белән бергә атлаучы хатын-кыз, Аллаһыга ышанам, әмма безнең гаиләдә диниләренә караганда, мәдәни гореф-гадәтләр күбрәк тотыла. Гаиләбездә традицион тәртип: гаилә башлыгы – ирем, аннары мин, соңрак – балалар. Балаларда мөстәкыйльлек тәрбияләргә тырышам. Хәләл ризыкка хөрмәт белән карыйм, гаиләдә дуңгыз ите кулланмыйбыз, бу бездәге кагыйдәләрнең берсе.

ТЫРЫШЫРГА ҺӘМ ТЫРЫШЫРГА

– Сәяхәт итәргә яратам, гаиләбез белән күп илләрдә булдык, төрле мәдәниятләрне күрдек. Еш кына андагы тормыш белән үзебезнекен чагыштырам. Әмма Казанымны дөньяның башка берәр шәһәренә алыштыру уе башыма кереп тә караганы юк. Әйе, кайчак башка менталитет һәм тормыш рәвеше булган урында яшәп карыйсым килә, әмма андагы мәдәниятне, гореф-гадәтләрне эчтән аңлау өчен генә. Бөтенләйгә күченү – юк! Без Казанны чын күңелдән ярата-

быз. Шәһәр үсә, матуррак, яшәү өчен уңайлырак була бара, тормыш итү өчен мөмкинлекләр күп. Монда безнең әти-әниләребез яши, монда гаиләм, ирем һәм яраткан эшем. Теләк булганда, биредә халыкара компанияне ачарга, аны үстерергә мөмкин. Һәм тырышып республикабыз һәм илебез иминлеге хакына эшләргә!

Без булмый, кем Казанны, илебезне, бу гүзәллекне үстерергә тиеш соң? Кем безнең Татарстанны тагын да яхшырак итәр? Бу буш сүзләр түгел, бу вазгыятьне эчтән аңлап, ихластан әйтелгән сүзләр. Беркем дә читтән килеп туган ягыбызны яхшыртмаячак. Моны бары тик без үзебез генә эшли алабыз. Хәзер дөньяның төрле почмакларыннан Казанга туристлар агыла – карарга, сокланырга, фотога төшәргә, тәмле итеп сыйланырга. Яңадан рәхәтләнеп әйләнеп килү теләге белән, күргәннәрдән бик канәгать калып китәләр. Ә кайчандыр берәү дә Казанга килергә атлыгып тормый иде – мин ул заманнарны да хәтерлим. Гәрчә бүген Казан һәрвакыт шундый матур, төзек, заманча һәм кунакчыл булгандыр кебек тоелса да.

Шуңа күрә бүген нәрсә генә эшләнмәсен, барысы да кешеләрнең тырышлыгы бәрабәренә ирешелүен бик яхшы аңлыйм. Шыңшырга һәм зарланырга яратучыларга карамастан.

ТОРМЫШ ПРОГРАММАСЫН НИЧЕК ЯҢАРТЫРГА

– Миннән еш кына тирә-юньдә нәрсә барганын белмәгәндә, сине беркем дә аңламаганда, ничек инде зарланмаска, күңелсезләнмәскә була, дип сорыйлар. Тормыш программасын яңадан ничек эшләтеп җибәрергә?

Барысы да бик гади: тормышны яратырга, кешеләрне – үз якыннарыңны гына булса да – яратырга, аларга көчеңне, күңел җылыңны кызганмаска кирәк! Барысы да йөзе белән үзеңә әйләнеп кайтачак. Һәм тагын тырышырга да тырышырга, әлеге хезмәт нәтиҗәсендә нәрсәнеңдер яхшыракка үзгәрә баруын тоеп яшәргә. Ярдәм кулы сузарга! Узып китмәскә!

Гаиләгез, дусларыгыз һәм эшегезне яратыгыз – бәхет шул булыр. Бәхет – максат та түгел, юл да түгел, ул сайлау бит! Әгәр кеше бәхетле булам дип яши икән, ул бәхеткә ирешәчәк! Мин үз теләгемә ирештем – һәм мин бәхетле.

Фотога төшү урыны: Казан Кремленең Кабул итү урыннары
Оештыручы: Wonderpeoplegroup
Фотограф: Анастасия Алашеева
Стиль: Нәргизә Солтан
Мейк: Елена Жукова

«АМИРА» ХАТЫН-КЫЗГА НИ КИРӘГЕН БЕЛӘ

Хәзер Җиһаншиннарның гаилә бизнесы әйләнешендә ай саен 10 миллион сумга якын акча йөри, ә ул вакытта, 2013 елда, барысы да хобби һәм яшь гаилә өчен өстәмә керем чыганагы буларак башланып китә.

«Амира» предприятиесенең исеме гарәпчәдән «шаһзадә» дигәнне аңлата. Шаһзадә белән охшашлык та күзаллана: хатын-кыз башында яулык таҗ кебек балкып тора.

ЮГАРЫ МАКСАТЛАРГА КИТЕРГӘН ХОББИ

Ун ел элек, декрет ялында утырганда, инглиз теле укытучысы Лилия Җиһаншина буш вакытын яңа һөнәр үзләштерүгә багышларга ниятли. Ире Эльдар белән Лилия – мөселманнар, шуңа күрә аның мөслимәләр өчен матур баш киемнәре тегәргә теләве бик табигый. Эшне башлыйлар: яңа идеяне тормышка ашыру өчен 15 мең сумлык тукыма сатып алына.

Лилия:

– Озак та үтми, клиентлар безгә: «Ә бәлки сез хатын-кызлар өчен киемнәр дә тәкъдим итәрсез?» – дип мөрәҗәгать итә башлады. Без кибет ачтык, һәм шуннан эш кузгалды. Беренче тегү цехын оештырып җибәрдек, әмма ул гына заказларны өлгертеп җиткерә алмады. Икенче, өченче цехларны ачарга туры килде... Бүген безнең 300 квадрат метрлы үз мәйданыбыз бар, шуңа өстәп, килешү төзелгән җитештерү цехлары бары тик безнең заказлар буенча гына эшли. «Амира» киемнәрен тегүдә барлыгы 120 кеше хезмәт куя. Мин җитештерү белән җитәкчелек итәм, ә Эльдар «Амира» компаниясенең генераль директоры. Вазыйфалар бүленешен шартлы дияргә була, чөнки гаилә бизнесында бер-беребезне алмаштыра алабыз: җитештерүдә, чимал сатып алуда, товарны урнаштыруда, маркетинг, логистикада. Бер генә нәрсә: миңа киемнең үзе белән күбрәк шөгыльләнергә туры килә, чөнки, хатын-кыз буларак, клиентлар белән турыдан-туры үзем аралашам, аларның ихтыяҗлары турында күбрәк беләм.

БАРЛЫК ХАТЫН-КЫЗЛАР ӨЧЕН КИЕМНӘР

Кечкенәдән башланган эш җитди бизнеска әйләнә башлагач, Лилия киемнәр тегү өлкәсендә махсус белемнәре җитмәгәнен аңлап ала. Ул КХТИда укып, «киемнәр дизайнеры-конструкторы» белгечлеген ала һәм мода технологияләре буенча Италия мәктәбенең эш принципларына нигезләнгән белемнәрен шунда ук эшкә дә җигә.

«Амира»ның клиентлар базасы зур, ул көннән-көн арта бара. Шәригать кануннарында язылганча, тыйнак кием-салым яратучы хатын-кызлар «Амира» маркасын сыйфатлы тукымалары, уңайлы өлгеләре, модада заманча тенденцияләргә туры килүе өчен үз итә.

Лилия:

– Без башта ук мөселман клиентларга йөз тоттык. Әмма заказларны бөтен Россия буенча җибәрә башлагач, сатып алучыларыбыз арасында башка милләт, башка дин кешеләре дә барлыгы ачыкланды. Чыннан да безнең киемнәр гади – шул ук блузалар, күлмәкләр, итәкләр. Алар бары тик кулларны, күкрәкләрне каплый, озынлыгы – аяк йөзеннән.

Эльдар:

– Пандемия безнең сатып алучыларның географиясенә үз төзәтмәләрен кертте. Мин дә Лилия кебек үк укытучы, ләкин гарәп теле укытучысы. Шуңа да товарларны сатуның яңа каналларын – маркетплейсларны үзләштерү өчен укырга кирәк булды. Монда Татарстан Хөкүмәте зур ярдәм күрсәтте. Республикада «Маркетплейс. Җиңел» Электрон сәүдә итү үзәге бар. Ул Татарстан Рәисе ярдәме белән булдырылып, ТР Икътисад министрлыгы, Эшкуарлыкка булышлык итү фонды белән берлектә эшли. Үзәк – электрон сәүдә итү базарындагы барлык эре мәйданчыкларның технологик партнеры.

Маркетплейсларга чыгу кыен булмады, чөнки сатуда булган кием-салымны үзебез җитештерәбез. Әгәр дә сез, әйтик, Wildberries*та «Амира мөселман киемнәре» дип җыясыз икән, анда безнең бөтен ассортимент чыга. Казанда Париж Коммунасы урамы, 25/39 һәм Җиңү проспекты, 206 адреслары буенча ике кибетебезнең уңышлы эшләвенә карамастан, хәзерге вакытта сатылган товарның күпчелек өлеше маркетплейсларга туры килә. Беренчедән, анда сатып алучылар аудиториясе күпкә зуррак, икенчедән, маркетплейслар

Вайлдберриз ҖЧҖ. ОГРН 1067746062449. Юр. адрес: 142181 Мәскәү өлкәсе, Подольск ш. о., Коледино авылы, Индустриаль парк, 6; 1 корылма

Фотолар «Амира» предприятиесеннән алынды. РЕКЛАМА

аша сатып алу уңайлырак. Без андагы кагыйдәләре буенча уйнарга – ташламалар ясарга һәм шуның аша тагын да күбрәк клиентлар җәлеп итәргә мәҗбүр.

СИҢА БИРЕЛГӘН ИКӘН – БҮЛЕШ

Җиһаншиннарның эшкуарлык юлында һәрвакытта да аларга ярдәм итүче кешеләр очрап торган. Матди ярдәм белән генә түгел, мәгълүмати яктан ярдәм күрсәтүчеләр дә күп булган. Кемдер яхшы тукымаларны кайдан алырга кирәклеге турында киңәш биргән, кемдер ышанычлы фурнитура сатучыларга чыгу юлын күрсәткән. Ә инде мөселманнар арасындагы танышлары «Амира» компаниясендә тегелгән киемнәрнең үтемле товар булуына инангач, артык акчаларын биреп торырга да тәкъдим иткән.

Эльдар:

– Бер генә бизнеста да өстәмә акчалар җәлеп итмичә эшләп булмый. Без дә искәрмә түгел. Хәзерге вакытта ислам финанслары турында күп сөйлиләр. Шуңа да биредә сүз исламда тыелган рибачылыкны күздә тоткан банк кредитлары турында бармый. Без аерым кешеләрне хезмәттәшлеккә сәүдә килешүе шартларында җәлеп итәбез, ул «мурабах» дип атала. Шул рәвешле без сәүдә әйләнешен дә арттырабыз, үз акчаларын безнең бизнеска биреп торган кешеләргә акча эшләү мөмкинлеге дә бирәбез.

Барлык хезмәткәрләребез дә лаеклы хезмәт хакы ала (40-60 мең сум). Эшкә урнашып эшләүчеләр өчен социаль түләүләр, иминиятләштерүләр, авырган вакытта түләүләр бар, декрет һәм отпуск еллары да түләнә.

«Амира» – социаль юнәлешле компания. Нигезендә безнең дини ышануларыбыз ята: барысы да безгә Аллаһы Тәгаләрәхмәте белән бирелә. Студент вакытта азык-төлек алырга да акча җитмәгән вакытлар була иде. Һәм без ул чакларны онытмыйбыз. Бүген дә Аллаһы Тәгалә безгә башкаларга ярдәм итү мөмкинлеге биргән икән, моны шатланып эшлибез. Кулдан килгән кадәр киемнәрне бушка да өләшәбез. Мисал өчен, күптән түгел «Ярдәм» мәчетенә тернәкләнүгә килгән сукыр хатын-кызларны киендердек. Практикага студентларны җәлеп итәбез, мәктәп укучыларына акча эшләп алу мөмкинлеге бирәбез, мәдрәсәләр төзелеше, мәктәпләрне төзекләндерү, авыл имамнарына, балалар белән эшли торган мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләү белән бәйле, башка төр проектларда катнашабыз. Безнең өчен иң мөһиме: сиңа бирелгән икән – рәхмәтле бул, бүлеш. Чөнки безнең эшнең социаль ягы – Аллаһ ризалыгы өчен эшләнгән эш, аның әҗере дә зурдан була.

КӨНДӘШ ТҮГЕЛ, ПАРТНЕРЛАР

Татарстанда мөселманча кием тегүчеләр күп кенә түгел, бик күп. Яңа тегү цехлары ачыла тора, яңа компанияләр барлыкка килә. Әмма бик азлар гына базарда ныклы адымнар белән атлап китә ала.

Эльдар:

– Кием тегү белән бәйле бизнес читтән караганда гына җиңел тоела. Бу – ялгыш фикер. Хатын-кызлар өчен кием-салым белән сәүдә итү өлкәсендә көндәшлек бик зур. Әмма без бу этапны үттек инде һәм, дөресен генә әйткәндә, бергә аралашып эшләгән, яшәгән кием җитештерүчеләрне көндәш дип санамыйбыз. Безнең өчен алар партнерлар. Күпмедер дәрәҗәдә алар безгә булыша, үз чиратыбызда, без дә ярдәмгә киләбез. Әлеге бизнеста калу өчен кием тегү генә җитми, даими рәвештә базардагы үзгәрешләргә һәм базар кануннарына ярашлы итеп эшләргә әзер булырга кирәк.

Лилия:

– Отышлы ягыбыз да шунда: без клиентны тоеп кына калмыйбыз, аны яхшы беләбез. Бу турыдан-туры аралашу да, онлайн-язышулар да, сораштырулар да һәм хәтта «Менә мондый кирәк!» дип килгән фотоларны өйрәнү дә.

Без төп ихтыяҗны канәгатьләндереп барабыз. Укырга, офиска, ял итәргә, спорт белән шөгыльләнергә, намазга кия торган киемнәр... Авыл кешеләре өчен – кыр һәм бакча эшләрендә кияргә уңайлы киемнәр. Бездә тиз арада, җиңел генә итеп бөтен тәнне каплый торган модельләр дә бик күп. Мин үзем – алты бала анасы, һәр минутның кадерле икәнен беләм, эшләгәндә, вакытның кадере бигрәк тә арта.

Бүген тегелә торган киемнәрнең ассортименты бик киң: төрле стильдәге күлмәкләр (көндәлек кия торганнардан алып, бәйрәм күлмәкләренә кадәр, мәсәлән, никах өчен), спорт костюмнары, шулай ук офис, өйдә, хастаханәгә кергәндә кияр өчен халатлар, буркини (мөселманнар өчен йөзү костюмы, биелдан алып кызыну өчен дә), итәкләр, чалбарлар һәм башкалар.

Безнең марка ассортиментның барлык үлчәмнәрдә дә булуы белән аерылып тора – 40 тан 60 нчы үлчәмгә кадәр, заказга теләсә кайсы үлчәмгә тегә алабыз. Безнең киемнәрнең бәяләре – 1500–3000 сум. Хәтта 500 сумлык күлмәкләр дә бар. Һәм без тулысы белән товарыбызның сыйфаты өчен җавап бирәбез. Тукыма тулысынча киҗе-мамыктан булмыйча, катнаш булса да, ул барыбер җиңел һәм «сулый», чөнки чималны сатып алганда, без барысын да, хәтта җепләрнең ничек үрелүенә кадәр тикшерәбез. Клиентлар да «Амира»дан алган күлмәкне рәхәтләнеп, берничә ел киячәкләрен белә.

Киемнәребезгә этник элементлар кертмибез, чөнки төп гардеробның максаты – универсальлек һәм кулланылышта уңайлылык. Без Россиядә, Татарстанда үз модабыз булуын телибез. Кызларыбыз гарәп яисә Азия стилендә түгел, ә үзебездә тегелгән заманча киемнәр кисен, дип тырышабыз.

Эльдар:

– Без иң башта куйган – хәләл-стайл кысаларында уңайлы һәм һәркем сатып ала алырлык кием тегү максатына ирештек. Казанда безнең киемнәрне киеп йөрүчеләрне күрәбез. «Амира» маркасы турында киң аудитория белә. Чикләрне киңәйтсәк, тагын да яхшырак булыр иде – илебезнең башка төбәкләрен дә безнең компаниядә тегелгән киемнәр белән таныштырасы килә. Амбицияләрне канәгатьләндерү өчен түгел, Россия базарына сыйфатлы, уңайлы һәм арзанлы кием чыгару максатыннан. Алга таба без бу мәсьәләдә республика Хөкүмәтенең ярдәменә өметләнәбез. «Амира» бренды Казан һәм Татарстан белән бәйле ассоциацияләр тудырсын, мөселман модасы башкаласы биредә – безнең шәһәрдә булсын, дип телибез.

1. **ENSAR кибете**
Париж Коммунасы ур., 25/39
10:00-19:00 ял көннәрсез
тел.: 89178926621
2 **AMIRA кибете**
Җиңү проспекты, 206
8:00-18:00 ял көннәрсез
тел.: 89178926623
https://t.me/odejda_amira13

ТАУЛАР КҮЧЕРЕРГӘ СӘЛӘТЛЕ ХАНЫМНАР

«Без хатын-кызларның барысы өчен дә ачык, арабызда төрле гүзәл затлар бар. Уңыш дәрәҗәсе буенча да чикләүләр юк, безнең белән һәркем үз юнәлешен таба», – дип аңлата «НУР» хатын-кызлар социаль инициативалары ассоциациясенең кыйммәтләрен Айгөл Хәйруллина. Ул әлеге берләшмәгә нигез салучы һәм аның президенты. Хезмәттәшлекнең беренче елында һәр катнашучы алга таба кайсы юнәлештә барырга кирәклеген аңларга өйрәнә: кемдер үз бизнесын башларга карар кыла, яңа офыклар ача, кемдер ире белән мөнәсәбәтләрен җайга сала яки, гомерлек тормыш юлдашын табып, бәби алып кайта. Бу ничек эшли соң?

ҮЗ ЮНӘЛЕШЕҢНЕ ЯКТЫРТУ

«НУР» – уртак кызыксынулар нигезендә оешкан клуб кына түгел, ә рәсми рәвештә теркәлгән хатын-кызлар берләшмәсе. Ике елдан артык ул хатын-кызларга илһам канатлары куя. Оешмада 200 дән артык катнашучы исәпләнә, һәм аларның саны даими үсә. Һәрберсенең нинди дә бер этапта Ассоциация белән бәйле үз тарихы бар, алар бирегә таяныч эзләп килә.

Барысы да иҗади очрашулардан башлана. Аларда хатын-кыз үзенең мөмкинлекләрен, хезмәтләрен, продукцияләрен тәкъдим итә, фикердәшләр үз идеяләрен тормышка ашыру өчен мәйданчык таба. Алга таба ачылып китү өчен, төрле чаралар, нетворкинглар, бизнес мәктәбендә дәресләр, бизнес-остазлык, иҗат белән бәйле вакыйгалар ярдәмгә килә. Болар психология, эвәләп ясау, рәсем ясау буенча осталык дәресләре, трансформация уеннары булырга мөмкин. Башка күп кенә иҗтимагый оешмалардан аермалы буларак, Ассоциациянең үз коворкинг мәйданы бар. Өстәвенә, ярты елга бер тапкыр һәр катнашучы үз проектын тәкъдим итә һәм «НУР»дан 250 мең сумга кадәр грант ала ала. Әмма акчалата ярдәмнән башка да барлык теләкниятләр гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта монда корыч холыклы ханым булырга өйрәтәләр дип уйлау дөрес түгел. Биредә әйтүләренчә, хатын-кызның төп урыны ир-ат янында, ул гаиләне саклап, үзен шәхес буларак ачарга тиеш. Ә матди байлыклар күңелле бер өстәмә дип карала.

ИҖАТ ТЕРАПИЯСЕ

– Хатын-кызның бирегә сүнгән күзләр белән килеп, яңа мохиттә ничек үзгәрүен, уңышка ныклы өметнең аңа нинди көчле йогынты ясавын күп күрдек, – ди **Ассоциация директоры Лилия Сәлахова.** – Илһамланган хатын-кыз таулар күчерергә сәләтле. Бездәге ханымнар ачкан бизнеслар арасында күчемсез милек агентлыгы, дөрес туклану өлкәсендә җитештерү предприятиесе, матурлык салоны, сыр җитештерү цехы бар.

Ассоциациянең президенты һәм аңа нигез салучы Айгөл Хәйруллина уңыш сере тәртип белән төзелгән системада дип белдерә. Һәм ул бу системаны нульдән төзегән. 18 ел ирләр бизнесында эшләгәннән соң, ул хатын-кызлар юнәлешенә күчә. Кайсыдыр бер чорда Айгөл ханым сизелерлек нәтиҗәләргә ирешә һәм белемнәрен уртаклашырга теләге барлыгын аңлый. Ассоциация әнә шулай оештырыла. Барысы да кечкенә очрашулардан башлана, аларга төрле сораулары булган хатын-кызлар килә. Баштагы мәлдәрәк бөтен нәрсә бизнес күзлеге аша алып барыла. Әкренләп исә хатын-кызга эш кенә түгел, ә иҗат итү кирәклеге дә ачыклана.

– Бер иҗади сәләт җебен тартып кую да җитә, – дип аңлата Айгөл, – бөтен эчке дөнья ачыла. Мин еш кына бизнес-остазлык дәресләре алып барам. Әлеге сессияләрдә еш кына эшнең нәтиҗәсе күренмәгәндә хатын-кызның күңел төшенкелегенә бирелүе ачыклана. Аннары исә аның үз юлы белән бармавы аңлашыла.

Ассоциациядә рәсми булмаган, дустанә аралашу мохите урнашуы да мөһим: килүчеләр үзләре кебек үк инициативалы һәм иҗади рухка ия фикердәшләре белән танышалар, дуслашалар, гаиләләр белән йөрешәләр, авыр мизгелләрдә бер-берсенә ярдәм итәләр.

«НУР» АССОЦИАЦИЯСЕ САННАРДА

802 көн

12+ бала туган

5 колачлы форум

34+ никах саклап калына

200+ даими әгъза

102+ хатын-кыз нульдән башлап үз эшен ачып җибәрә

1000+ бүләк уйнатылган

1 млн сумнан артык суммага 4 грант

Фотолар «Нур» ассоциациясеннән алынды. РЕКЛАМА

ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘДӘГЕЛӘР ЯРДӘМЕ

Татарстанда «Диңгез мәчеләре» дип аталган беренче инклюзив йөзү үзәгенә нигез салучы һәм аның җитәкчесе Анна Кузнецованы язмыш «НУР»га бизнес-партнер белән аңлашылмаучанлык килеп чыккан вакытта китерә. Ул чакта дөньяның асты өскә килгән кебек тоела аңа. Ассоциация форумына Анна очраклы рәвештә генә эләгә. Үзе кебек үк эшмәкәрләр белән таныша һәм киңәш-табыш ягыннан бик зур булышлык таба.

Үз бизнесын Анна, ире һәм башка бизнес-партнер белән бергә, 2019 елдан үстерә башлый. «Диңгез мәчеләре» үзәге булдыру идеясе бер танышының: «Балаларың булгач, йөзү белән шөгыльләнегез, сәламәтлек өчен шәп», – дигән сүзләреннән соң башына килә. Гаиләдә беренче бала тугач, ир белән хатын аңа бассейн эзли башлый. Ләкин кулай вариант таба алмыйлар. Алар моңа кадәр беркем дә батырчылык итмәгәнне эшләргә: һәркемгә уңайлы бассейн ачарга ниятли. Шулай итеп, үз бассейннарын ачу эшенә керешәләр.

– Хәзер «Диңгез мәчеләре» үзәгендә 3 айдан 10 яшькә кадәрге сау балалар һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар бер үк вакытта шөгыльләнә. Без балаларны аермыйбыз, төп үзенчәлек шунда, – ди Анна. – Проектыбызның миссиясе – балалар сәламәтлеген, спортны, йөзү спортын һәм сәламәт яшәү рәвешен үстерү. Безнең хезмәтләргә ихтыяҗ арта гына бара, инде кысанлык та сиздерә, урыннар җитми. 2022 елның 26 маенда проектыбызны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка тәкъдим иттек. Проект аңа ошады, һәм ул министрларга шәһәрнең һәр районында шундый бассейн булдыру турында күрсәтмә бирде. Проектны алга таба үстерү өчен, безгә чыннан да ярдәм кирәк.



ИДЕЯЛӘРНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУ

Алия Сәгыйрова – Казанда «Максат» күчемсез милек агентлыгына нигез салучы һәм аның җитәкчесе. Бер ел элек ул, белеме буенча икътисадчы-аналитик, вазифасы буенча сату бүлеге җитәкчесе, ирешкән уңышлары һәм тормышындагы тотрыклылыкка (өе, гаиләсе, балалары, эше) карамастан, үзенә нәрсәдер җитмәвен аңлый. Эзләнү барышында Алия «НУР»га нигез салучы Айгөл Хәйруллинага киңәш сорап мөрәҗәгать итә. Һәм шунда нигә әле үзеңне идарәче ролендә сынап карамаска дигән фикер килә. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә Алия үзенең күчемсез милек агентлыгын ача. Бер ел эчендә аның 2 хезмәткәрдән гыйбарәт штаты 15 кешегә кадәр үсә, клиентлар базасы формалаша.

– Мин кешеләрне бик яратам һәм аларга булышырга әзер, – ди Алия. – Баштан ук, кешеләр безне башкаларга тәкъдим итәрлек булсын, дигән максат куйдым, Шулай килеп чыкты да. Безнең үзенчәлек шунда: без эшне ахырына кадәр җиткерәбез, озак вакытлы хезмәттәшлеккә йөз тотып, ачык күңел белән, киләчәкне уйлап эшлибез. Клиентлар арасында төрле дәрәҗәдәге кешеләр бар. 2022 елда күп кенә агентлыклар ябылды, ә минем, киресенчә, эшем артты. Без яңа төзелгән һәм икенчел торакны, шәһәр читендәге һәм чит илләрдәге күчемсез милекне сату-алу белән шөгыльләнәбез.

Хәзер Алия дәүләт муниципаль идарәсе юнәлешендә өстәмә белем ала, ә 2023 елны шәхси брендын үстерүгә багышларга карар кылган. Аның сүзләренчә, шушы дәвердә аны «НУР» ассоциациясе илһамландырып торган. Ул һәр хатын-кызның шундый илһам чыганагы булырга тиеш, дип саный.

ДАВЫТ ХӘЙРУЛЛИН, 3Д-КОЙМАЛАР ЗАВОДЫ:

«БИЗНЕСНЫ РОССИЯДӘ КОРАСЫ КИЛӘ»

Купшырак яңгыраса да, үз эшенең үсешен «ДАИС» компаниясе җитештерүне арттыруда гына түгел, ә Россия эшкуарлыгы, рус сәүдәгәрлеге традицияләрен ныгытуда да күрә. Хәзер акчаларны һәм көчне Россиядәге бизнеска, туган төбәгебез Татарстанга бирә торган чак, бу юнәлештә дәүләт ярдәме чараларын формалаштырыр өчен иң кулай вакыт, дигән фикергә килә компаниянең директоры һәм аңа нигез салучы Давыт Хәйруллин, чит илдә бизнес алып баруның үзенчәлекләрен үз җилкәсендә татыганнан соң. Шул исәптән шәригать тарафыннан билгеләнгән нечкәлекләрне, кредит алу-бирүгә бәйле чикләүләрне һәм җирле җитештерүчегә мәҗбүри рәвештә ярдәм күрсәтүне дә күздә тотып...

– Хәзер күпләр үзләре яшәргә күнеккән зур койма һәм диварлардан баш тарта, иркенлеккә омтыла, коймалар санын киметергә, матур манзараны капламаска тырыша, – ди Давыт Исхак улы һәм, панель коймалар заводы продукциясе белән таныштырып, аларның өстенлекләрен аңлата. – Бу яктан караганда, заводыбызда җитештергән 3D-коймалар үзләренең экологиялелеге белән аерылып тора. Алар каплый, бу койма аша сикереп чыгу мөмкин түгел, әмма шул ук вакытта изоляция, бикләнү хисе барлыкка килми, иркенлек тойгысы кала.

Беренчедән, җитәкче сүзләренчә, завод үзебезнеке һәм ул Чистайның сәнәгать паркында урнашкан. Димәк, электр, аренда өчен түләүләрдә, салымнарда ташламалар ясала дигән сүз. Шуңа күрә клиентларга көндәшлеккә сәләтле, отышлы бәя тәкъдим итә ала. Икенчедән, компания белгечләре эшне тиз йөртә, юнәлешне дә тиз арада үзгәртеп корырга, сыйфатны югалтмыйча, продукцияне эшләп тапшырырга сәләтле. Өченчедән, социаль юнәлеш тә мөһим – компания эш урыннары булдыра. Хәтта кышкы чор, җитештерелгән продукция күләме кимегән вакытта да, эшчеләр хезмәт хакы белән тәэмин ителгән.

Фирма киңәю турында уйлана. Күптән түгел продукция төрләрен арттыру өчен өстәмә яңа станок кайтартылган, күләмлерәк материалларны буяу өчен, якын арада тагын бер мич сатып алу планлаштырыла. Ә киләчәктә җитештерүнең яңа төрләрен үзләштерү нияте дә бар, шөкер, моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Шул ук вакытта компания төзелеш оешмалары, АЗС челтәрләре, «Газпром» корпорациясе белән хезмәттәшлеккә әзер – җитештерү күләме зур заказларны башкару мөмкинлеге бирә.

Бу эштә дәүләт ярдәме бик вакытлы булыр иде. Бүген җитештерү куәтләрен арттыру өчен лизинг-грантлар, дәүләт программалары һ.б. рәвешендәге финанс ярдәме кирәк. Әмма, ни кызганыч, базардагы вазгыятьне анализлау әлеге юнәлеш өчен яраклы программаларның булмавын күрсәтә. Компаниянең җиһазларны лизингка сатып алу омтылышы да барып чыкмый: шартлар оешманың базар стажы өч елдан артык булуын таләп итә.

Ә Давыт Исхак улының компаниясе яшь әле. Заводны ул былтыр гына сатып алган. Бизнеста инде күп еллар булса да, эшмәкәр өчен бу – җитештерү тармагындагы беренче тәҗрибә. 48 яшенә ул 50 илдә булырга өлгерә, аларның кайберләрендә бизнес алып бара. Холкы белән ул үзен идарәче, өстәвенә, катлаулы процессларны өйрәнүдән тәм табучы кеше, дип саный. Койма бизнесы исә нәкъ энә шундый.

– Гомумән алганда, дөньяның төрле почмакларын күреп, төрле илләрнең менталитетын өйрәнеп, мин бизнес һәм тормыш өчен иң яхшы ил – Россия, ә Җирнең иң уңайлы шәһәре – Казан икәнен аңладым, – ди эшмәкәр. – Бу буш сүзләр түгел, мин нәрсә әйткәнемне беләм. Без дөрес юлда, бары тик җирле җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме, ислам банкингы үрнәгендә процентсыз кредит бирү системасы гына җитми.

Хәзер «ДАИС» төзелеш оешмалары белән хезмәттәшлек кора, ваклап сату юнәлешендә клиентларының санын арттыра. Компаниянең потенциаль клиентлары – мәктәпләр, хастаханәләр, балалар бакчалары, газ тармагы. Һәр заказчы үз заказына кулай бәя ала. Базарда үз юлын күптән түгел башлаган компания буларак, «ДАИС» клиентларының ихтыяҗларын исәпкә алып үсәргә ниятли.

Фото «ДАИС» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

Могҗиза
Сезнең өчен!
зәркән эшләнмәләр салоны
ЭКСКЛЮЗИВ
50% – КЫЙММӘТЛЕ ТАШЛЫ БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕНӘ барысына да ташлама 2023 елның 30 июненә кадәр
50% – ТУЙ БАЛДАКЛАРЫНА ташлама 2023 елның август ахырына кадәр
Салоннарның адреслары:
Р. Зорге ур., 67, тел./факс (843) 268-25-24
Восстание ур., 62, тел./факс (843) 564-77-67
Бутлеров ур., 29, тел./факс (843) 238-42-50
Чистай ур., 16/15, тел. (843) 223-00-08, 223-00-09
www.exclusive-jewelry.ru, e-mail: exclusive-kazan@yandex.ru
Ташламалар башка барлык ювелир салоннары дисконт карталары буенча да ясала.
Бездә ҮЗЕГЕЗ ТЕЛӘГӘН СУММАГА БҮЛӘК СЕРТИФИКАТЛАРЫ сатып алырга мөмкин.
РЕКЛАМА

СӘЛАМӘТ БУЛУ – МОДАДА

Бу шифаханәне белмәгән кеше юктыр: биредә дәвалану буыннан-буынга күчә бара. «Васильевский», шифаханә-курорт дәвасы өлкән яшьтәгеләр өчен генә, дигән стереотипны җимерү үрнәге дә булып тора әле.

«ВАСИЛЬЕВСКИЙ» ШИФАХАНӘСЕ – СӘЛАМӘТ ЯЛ ИТҮ УЛ

Шифаханә-курортларда даими дәвалануның гомерне 10–15 елга озайтуын сез беләидегезме әле?

Режим, дөрес туклану һәм уңай яшәү шартлары организмның гомум сәламәтләнүенә китерә. «Васильевский» мисалында шифаханәнең нәрсә бирүе турында сөйләшеп алыйк әле. Әгәр сезнең нинди дә булса авыруыгыз инде бар икән, дөрес сайланган савыктыру процедуралары ремиссия вакытын озайту мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәне югалтмас өчен, әлеге процедураларны даими һәм системалы – елына 1–2 тапкыр кабатларга кирәк. Гомумән, шифаханә-курорт дәвасы киләчәктә сәламәт яшәү рәвешенә күчү өчен уңай шарт булып тора.

Шифаханә-курорт юлламасы, дәваланудан тыш, кимендә тагын өч өлешкә бүленә: яшәү, туклану, ял итү.

ДӘВАЛАНУ ҺӘМ ТЕРНӘКЛӘНҮ

Әллә ни күп булмаган акчага сез «Васильевский» шифаханәсендә көн саен бассейнда йөзә, дәвалау физкультурасы белән шөгыльләнә, минераль су, фиточәй эчә аласыз. Табиб сезгә профильле сихәтләндерү программалары билгеләячәк. Шифаханә-курорт дәвасы – ял итүнең бик файдалы төре, ул көннән-көн популярлаша бара. Кеше, өендәге гадәти мохиттән аерылып, шифаханәгә эләккәч, аның нерв системасы уңай үзгәреш кичергәндәй була. Бу яңа тәэсирләр һәм танышулар. Гаиләле кешеләргә болай ял итү ошый, чөнки табиб һәркайсы өчен шәхси сәламәтләндерү программасын билгели. Һәрвакыт саф һавада йөрү, ә иң мөһиме – тынычландыра, киеренкелекне бетерә, иммунитетны ныгыта һәм организм системалары эшен нормага сала торган файдалы һәм рәхәт сәламәтләндерү процедуралары үтү мөмкинлеге бар.

УҢАЙЛЫ ЯШӘҮ ШАРТЛАРЫ

«Васильевский» актив сәламәт яшәү рәвеше алып баручыларда шифаханә-курорт ялының файдасы хакында беренчеләрдән булып күзаллау тудыра башлаган шифаханәләрдән санала. Аның барлык биш кунакханәсендә дә бик уңай яшәү шартлары тудырылган, ә бәяләрнең төрле булуы кунакларга бүлмәне үз бюджетларына карап сайлап алу мөмкинлеген бирә.

СӘЛАМӘТ ТУКЛАНУ

Шифаханәдә туклану ике типта оештырыла: швед өстәле һәм меню-заказ.

Менюны санаторийның югары квалификацияле диетологлары сәламәт туклану принципларына ярашлы рәвештә төзи, ул дөрес сайланган витаминнар, минераллар, аксымнар, майлар һәм углеводлар комплексыннан гыйбарәт. Чөнки нәкъ менә дөрес туклану сихәтләнергә булыша һәм хроник чирләрдән котылырга ярдәм итә бит.

Швед өстәленең исә өстенлеге шунда ки, кеше үзенә кирәкле ризыкларны үзе сайлап ала. Шул рәвешле, ул организмын рацион үзгәрүгә бәйле стресстан саклый. Килешәсездер, өй ризыклары шифаханә диеталары белән бер түгел инде.

Меню-заказ системасы ял итүчеләргә киләсе көнгә менюны мөстәкыйль төзү мөмкинлеген бирә. Кунаклар бирелгән исемлектән үзләренә диетологлар тәкъдим иткән ризыкларны сайлап ала. Меню исә өлкәннәрнең дә, балаларның да күңеленә хуш килерлек. Табында һәрвакыт – яхшы сыйфатлы ит һәм балык, яшелчә-җиләк-җимеш, фермерлар җитештергән табигый сөт продуктлары гына.

«Васильевский» шифаханәсендә, хәләл меню тәкъдим итеп, мөселман традицияләрен дә саклыйлар. Шулай ук вегетарианнар өчен махсус меню да бар. Яңа кафеда исә гаилә белән сыйланып утырырга яки яңа танышлар белән тәмләп чәй эчәргә мөмкин.

ФАЙДАЛЫ ЯЛ

Дәва процедураларыннан тыш, биредә киногa яки китапханәгә барырга, бильярд яки теннис уйнарга, иҗат остаханәсендә күңеленә якын шөгыль табарга да мөмкин. Нәниләр өчен йомшак тау, мата, коры бассейн урнаштырылган уен бүлмәсе бар. Велосипед, самокат, роликлы тимераяк, туп, сикергеч, кыршау, чаңгы, тимераяк кебек спорт инвентарен прокатка алырга мөмкин. Эшлекле очрашулар өчен мультимедиа җиһазлы һәм флипчартлы конференц-заллар эшли. Гомумән, биредә рәхәтләнеп ял итеп була. Т

Фотолар «Васильевский» шифаханәсеннән алынды. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

«БӘКЕР»НЕҢ КӨЧЕ – ТАБИГАТЕНДӘ!

Моннан 90 ел элек Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы Мәхәббәт тавы итәгендә, Шушма елгасы тугае һәм Озын Күл үзәнендә республиканың иң яхшы савыктыру үзәкләреннән берсе – «Бәкер» курорты эшли башлый.

Гап-гади земство табибы Максим Игнатьев беренче булып биредәге ләмнең һәм күкертле водород чишмәләренең гаҗәеп дәвалау үзлекләренә игътибар итә. Аның үҗәтлеге һәм тырышлыгы нәтиҗәсендә 1933 елның җәендә сазлык урынында ләм-бальнеология курорты төзелә башлый. Сихәтле ләм запасы 100 мең тонна тәшкил итә, ә күкертле водород чишмәләре тәүлегенә 350 мең литр су бирә! 60 елдан соң исә табигать «Бәкер»гә тагын бер бүләк ясый: 1991 елда биредә дәвалау үзлекләре буенча тиңдәше булмаган минераль сульфат-натрий-магний-кальцийлы су табыла.

ИДЕЛДӘН ЕНИСЕЙГА КАДӘР

Бүген Калининградтан – Камчаткага, Мурманскидан – Сочига, Иделдән алып Енисейга кадәр – Россиянең бөтен почмакларыннан кеше дәвалану өчен «Бәкер»гә агыла... Шифаханәдә ел саен 16 меңнән артыграк кеше дәвалана, ял итә. Биредә бер тапкыр шифа тапкан кунаклар яңадан әйләнеп кайта. Сезгә бик гаҗәп тоелыр: әмма күпләр «Бәкер»гә инде 20 нче - 30 нчы тапкыр килә!

БАРЫСЫ ДА ҮЗЛӘРЕНЕКЕ

«Бәкер» шифаханәсе кай ягы белән уникаль соң? Әлбәттә инде, беренче чиратта, дәвалауның югары нәтиҗәле булуы белән. Бирегә бернәрсә дә читтән кайтартылмый. Моннан 90 ел электәге кебек үк, «Бәкер»нең көче – аның үз биләмәләрендә үк урнашкан минераль сулы чишмәләрендә, сапропель ләмендә һәм, әлбәттә, дөньяның иң шәп курортларындагыдан калышмый торган тиңдәшсез климатында. Гаҗәеп табигый ландшафт, аллея һәм газоннарның пөхтәлеге, Мәхәббәт тавына менү сукмагы – барысы бергә кушылып, искиткеч манзара тудыра, тау башыннан исә бөтен шифаханә уч төбендәгедәй күренеп тора.

ИҢ ШӘП ДӘВА, ИҢ ШӘП ТАБИБЛАР

Физиотерапиянең 250 дән артык төре сайлау һәм конкрет авырулар буенча кирәкле процедураларны комплекслы итеп алу мөмкинлеген бирә. Курортның төп юнәлешләре – терәк-хәрәкәт аппаратын, нерв системасын, тире авыруларын дәвалау, урология һәм гинекология. Шифаханә 50 елдан артык хатын-кызларны да, ирләрне дә балага уза алмаудан – кысырлыктан дәвалауның нәтиҗәле методикасын куллана. Шушы еллар эчендә йөзләгән кеше ата-ана булу бәхетенә ирешә.

«Бәкер»гә ашказаны-эчәк тракты чирләре белән дә, ковид белән авырганнан соң тернәкләнү өчен дә, башка авырулардан шифа табу өчен дә киләләр. Чөнки «Бәкер» шифаханәсендә бөтен кирәкле заманча җиһазлар һәм, табигый ки, үз эшенең остасы булган югары класслы белгечләр бар. Кунаклар шифаханә табибларына рәхмәтле булып китәләр. Алар арасында Татарстан Республикасының ике атказанган табибы – табиб-гинеколог Эльза Мөнәвир кызы Шәймәрданова һәм табиб-физиотерапевт Җәмил Вахит улы Шәмсетдинов, шулай ук биредә инде 40 елдан артыграк эшләүче Татарстанның атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре, шифаханәнең баш шәфкать туташы Нәкыйбә Миннәхмәт кызы Сәлахова бар.

ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Шифаханәдә дәвалауның яңа ысулларын кертү, тагын да камилрәк дәва программалары булдыру юнәлешендә даими эшлиләр. Кунаклар арасында популяр булган озон терапиясе, карбокситерапия, гидровакуумлы массаж, криосауна, һава-озон ваннасыннан тыш, югары технологияле медицина аппаратлары пәйда булган, алар табигый дәва ресурслары белән беррәттән уңышлы нәтиҗәгә ирешергә булыша. Бу – күптөрле авыруларны дәвалау һәм алдан кисәтүдә кулланыла торган авантрон, магнитотурботрон аппаратлары.

БӘКЕР «КОШ»ЛАРЫ

Кунаклар «Бәкер»не бик уңайлы шартлары өчен дә, җентекләп уйланылган мәдәни-ял итү программалары өчен дә үз итә. Шифаханәнең дүрт корпусы, «Тургай», «Аккош», «Сандугач», «Карлыгач» дип, татарча кош исемнәре белән аталган. Алар берьюлы 600 гә якын кешене кабул итәргә сәләтле. «Аккош»та хәзер яңарту эшләре төгәлләнеп килә, һәм аның интерьерлары Европадагы зиннәтле кунакханәләрдән калышмаячак.

Рәхәтләнеп ял итү өчен бушлай спорт инвентаре – чаңгы, тимераяк, велосипедлар, скандинав йөреше таяклары бар. Спортның төрле төрләре буенча ярышлар үткәрелә. Кич исә кунакларны йә шоу-программа, йә концерт, йә спектакль көтә. Мини-зоопаркны исә шифаханәнең визит карточкасы дип әйтергә була. Анда тәвә кошлары да, боланнар да, кыр кәҗәләре дә, куяннар да бар. Ә саф сулы буада яшәүче пар аккош исә шифаханә кунакларын каршы ала һәм озатып кала, үзләренең гүзәллеге һәм нәфислеге белән сокландыра.

«БАРЫСЫ ДА БИК ШӘП»

Ничәмә-ничә еллар дәвамында «Бәкер»дә эшләүче һәркемнең курорттагы тиңдәшсез табигый ресурсларны кадерләве, сәламәтлек чыганагының беркайчан да саекмавы өчен аларны саклавы белән шифаханә коллективы чын-чынлап горурлана. Кунакларга килгәндә исә, аларның берсе социаль челтәрдә: «Бу шифаханәдәге барлык дәва – супер, бик шәп. Сәламәтләнергә теләгән һәркем бары тик бирегә – «Бәкер» гә генә килергә тиеш!» – дип язып куйган.

Фото «Бәкер» шифаханәсеннән алынды. РЕКЛАМА

ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫ БУЕНЧА ЮРИДИК ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

«Хәләл» билгесе күптән инде дини чикләрне узып, туклану өлкәсендә генә түгел, яшәү рәвеше, сервис һәм хезмәт күрсәтүләрдә дә сәламәт, саф, аңлы сайлау критериена әйләнде.

KAZAN LEGAL GROUP компаниясе җитәкчеләре Кристина һәм Руслан Курбаниязовлар интеллектуаль милекне саклау, шәригать каннуннары буенча юридик хезмәтләр күрсәтү һәм киләчәккә планнары турында сөйләделәр.

ЮРИСТ ӨЧЕН ИҢ ПРОГРЕССИВ ӨЛКӘЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Безнең компания интеллектуаль милекне саклау, мәгълүмати технологияләр өлкәсендә киңәшләр бирү һәм судта интеллектуаль хокуклар буенча вәкил булуда махсуслаша.

Товар билгеләре, кушымталар, музыка, китаплар, сурәтләр, дизайн, шәхси эшкәртмәләр, җитештерү серләре, техник яңалыклар – болар барысы да интеллектуаль милеккә керә.

Без клиентларыбызга аларны теркәүдә генә түгел, башкаларның күчереп алуыннан һәм намуссыз көндәшләрдән саклануда да ярдәм итәбез.

Бу өлкәнең катлаулылыгы шунда ки, ул даими үзгәреп, үсеп тора. Бу безгә ошый, без дә үз квалификациябезне даими күтәрергә, соңгы яңалыклардан хәбәрдар булырга, яңа белемнәрне эшебездә кулланырга тырышабыз.

ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫ БУЕНЧА ЮРИДИК ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ДӨНЬЯВИ ЭШЛӘРДӘН АЕРЫЛА

Беренче һәм иң мөһим аерма – без хәләл булмаган бизнес белән эшләмибез. Мәсәлән, без алкоголь яки тәмәке продукциясенең товар билгесен теркәмибез.

Моннан тыш, шәригать каннуннары клиент белән мөнәсәбәтләргә дә тәэсир итә. Безгә тулы чын мәгълүмат бирү һәм бөтен булган хәвефләр турында кисәтү мөһим.

Тагын бер аерма – гендерлык буенча бүленү. Ир-ат – ирләр белән, хатын-кыз ханымнар һәм туташлар белән эшли. Әмма икебез дә бертигез дәрәҗәдәге һөнәри тәҗрибәгә ия, шунлыктан ике очракта да хезмәт күрсәтү бердәй югары дәрәҗәдә башкарыла.

Шәригать каннуннарын һәм ислам стандартларын саклау аеруча мөһим булган кешеләргә булыша алуыбызга без бик шат.

Шунлыктан безгә «Мөселман эшкуарлары ассоциациясе» кебек мөселманнар ассоциацияләре клиентлары да, «Нур» ассоциациясе», «ТР-ның эшлекле хатын-кызлары» кебек дөньяви оешмалар да еш мөрәҗәгать итә.

ИСЛАМ ЮРИСТЫ ҮЗ ДИНЕНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛЕРГӘ ТИЕШ

Әмма шул ук вакытта ул үз эшенең остасы булырга, әхлакка зыян китермичә сыйфатлы хезмәт күрсәтергә, бу дөньяда гына түгел, ахирәт тормышында да хәерле киләчәккә өметләнеп эш итәргә тиеш.

Ирләр арасында мөселман юристлары җитәрлек, ә менә яулык япкан хатын-кыз юристны очратуы сирәк, бигрәк тә башка шәһәрләрдә. Анда аеруча кызыксыну сизелә.

«ХОКУК-300» – ҮЗГӘ БЕР ГОРУРЛЫК

«Хокук-300» – безнең илдәге төп бәйсез рейтинг, ул иң яхшы юридик компанияләрне ачыклый.

Безнең хезмәтебезне шундый югары дәрәҗәдә бәяләүгә без бик сөендек. Уңыш формуласы исә бик гади – бары үз эшеңне яратырга, катлаулы эшләргә алынудан курыкмаска, максатлар куярга һәм көн саен яңа изге ниятләргә таба атларга гына кирәк.

БЕЗГӘ БЕР УРЫНДА ТАПТАНМАУ МӨҺИМ

Быел без, күбрәк күләмдә хезмәт күрсәтү өчен, командабызны зурайтырга, үз квалификациябезне күтәрүне дәвам итәргә, коллегаларыбыз һәм белгечләр белән аралашырга, белемебез белән уртаклашырга һәм үзебез дә яңа белемгә омтылырга телибез.

Компаниябез эшчәнлеге клиентларга файда китерсен, иртәгәге көн исә кичәгесеннән яхшырак булсын, дип хыялланабыз. Т

+7 (987) 409-10-54 (Руслан),
+7 (960) 040-86-65 (Кристина)

kazan-legal-group.ru

Казан, Спартак ур., 88Б

kazanlegalgroup@gmail.com

Фото KAZAN LEGAL GROUP компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Дөньядагы иң шәп урын **кайда**

Сәнәгать предприятиесе **ничек** район күркенә әверелгән

Иң матур музейга **ничек** эләгергә

Кукмарада елына **ничә** итек басалар

Кәрзинне **нәрсәдән** үрәләр

ДӨНЬЯДА ИҢ ШӘП УРЫН

ИХ, КУКМАРА, КУКМАРА, ЕРАГАЙМАСЫН АРА...

Кукмара, мөгаен, Татарстанда иң матур районнарның берседер. Монда барысы да: мәһабәт таулар да, офыкка җәелгән үзәннәр дә, куе урманнар да, Норма елгасы да, саф сулы чишмәләр дә бар... Табигатьнең шушы гүзәллекләрен аерым-аерым күргәндә дә, тулаем караганда да асфальт «елга»лар, бордюр «яр»лар арасында үскән гади шәһәр кешесе хәйран кала.

Фото: Александр Ефремов

1
Сергей Димитриевич безне үзенең туган ягы – Кукмараның бай тарихына турыдан-туры бәйле истәлекле сәнәгать урыннары буйлап экскурсиягә чакыра.

2
Туристлар яратып йөргән «Бакыр тау» тау чаңгысы комплексының исеме дә Кукмара төбәге тарихына бәйләнгән.

– Ләкин гаҗәеп табигать манзаралары – безнең бердәнбер байлыгыбыз түгел, – ди Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев. – Кукмара – киң танылган һәм популяр күп кенә товарларның бренды буларак күптән билгеле. Сәнәгать туризмы белән кызыксынучы туристлар шуңа күрә республиканың һәм Россиянең барлык почмакларыннан безгә килә. Алар бик канәгать кала һәм бер дә буш кул белән китми.

Сергей Димитриевич безне үзенең туган ягы – Кукмараның бай тарихына турыдан-туры бәйле истәлекле сәнәгать урыннары буйлап экскурсиягә чакырды.

БАКЫР ТАУ ХУҖАЛАРЫ

– 1930 елда оешкан районыбыз тарихи күзлектән караганда яшь булса да, кешеләр бу якларга 16 нчы гасырда ук килеп урнашкан, – дип сөйли Сергей Димитриевич. – Ә Кукмараның сәнәгать тарихы бакыр рудасын чыгару һәм эшкәртүдән башлана. 1741–1743 елларда Казан сәүдәгәре Иноземцев Туеш дип аталган татар авылы җирләрендә бакыр кою заводы төзи. Заводның биш кою миче һәм 130 руднигы була. Биредә ел саен 1553 пот саф бакыр коела! Эшчеләр завод тирәсенә урнаша башлый, шулай итеп «Кукмара заводы», яки «Туеш заводы» дип йөртелгән бистә барлыкка килә.

Туристлар яратып йөргән «Бакыр тау» тау чаңгысы комплексының исеме нәкъ менә шушы тарихи фактка бәйләнгән дә инде.

КИЕЗ ИТЕКЛӘР ҺӘМ ТАБАЛАР КАЙЧАН ЧЫГА БАШЛАГАН

XIX гасырның икенче яртысында Кукмара һөнәрчелек үзәгенә әверелә. Киез сугу кәсебе аеруча актив үсә. 1870 елда бертуган Комаровлар киез һәм бурка аяк киеме фабрикасына нигез сала. Ул тиздән Казан губернасының иң эре киез итек предприятиеләренең берсенә әйләнә! Предприятиедә сигез ат көчле бер пар машинасы, бер пар казаны була. Фабрика елына 285 көн эшли, сменалар 12 шәр сәгать дәвам итә. Куәте ягыннан ул губернаның өченче эре сәнәгать предприятиесе санала.

Бертуган Родигиннарның киез-йон фабрикасы бу тармакның икенче эре предприятиесе була. «Бертуган Родигиннар иптәшлеге» Казан һәм Вятка губерналарында аяк киеме фабрикалары ачып җибәрә.

Әлеге предприятие инде кырык ат көчле пар двигателе белән җиһазландырыла. Ширкәтнең Мәскәүдә һәм Казанда вәкиллекләре эшли.

Әлеге фабрикалар туристлар һәм шәһәр кунаклары киез итекләр сатып алырга ярата торган хәзерге Кукмара киез итек-киез комбинатының чишмә башы булып тора.

Шәһәрдә тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләре – бертуган Комаровлар фабрикасының җитештерү бинасы, контора бинасы һәм складлары сакланган. Бертуган Родигиннарның киез сугу фабрикасы бинасы да шундыйлар арасында.

1924 елдан соң Кукмарада промысел артельләре оеша башлый, соңыннан алар базасында предприятиеләр барлыкка килә. Оешмаларның исемнәре үзгәреп тора, алар әле ябыла, әле яңартылып ачыла, ләкин асыллары кала. Бүген болар – Кукмара сәнәгатенең төп брендлары: «Хыял» тегү фабрикасы, Kukmara металл савыт-саба заводы һәм «Мастер и камень» заводы.

ЯШЬЛӘР КИРӘК

– Димәк, Кукмара – мөстәкыйль яшәп, үзүзен тәэмин итә ала торган, эш урыннары җитәрлек булган шәһәр һәм беркемгә дә, читкә китеп, мегаполисларда эш һәм яхшы-

3
– Сәнәгать тармагында дисеңме, авыл хуҗалыгындамы – биредә һәр яшь кеше, һәр яшь гаилә өчен эш җитәрлек.

рак тормыш эзләп йөрисе юк. Мегаполиска күченгән кеше анда югала, дип уйлыйм. Кечкенә шәһәрләрдә ул үз урынын тизрәк табып, максатына ирешә алачак. Әгәр дә ул үзен яхшы белгеч итеп күрсәтсә, монда ул күбрәккә ирешәчәк, аны тизрәк күреп алачаклар. Казандагы хезмәт хаклары Кукмараныкыннан аерылмый. Ә зур шәһәрдәге фатир өчен ипотека түләп, һәм 20–30 елга тозакка эләгү бер дә дөрес түгел. Сәнәгать тармагында дисеңме, авыл хуҗалыгындамы – биредә һәр яшь кеше, һәр яшь гаилә өчен эш җитәрлек. Безгә белгечләр кирәк. Киләчәктә тагын да үсәргә уйлыйбыз: 98 гектарга исәпләнгән яңа сәнәгать мәйданчыгы ачабыз. Бу исә яңа предприятиеләр, яңа эш урыннары дигән сүз. Шуңа күрә без һәрвакыт яшьләрне районда калырга өндибез, алар белән очрашулар уздырабыз, таләп-үтенечләренә колак салабыз, үтибез. Парклар, скверлар, кинотеатрлар төзелде. Кафе сорадылар – анысын да ачтык. Казандагы очрашу урыны кебек берәр сәүдә үзәге сорадылар – бу үтенечне дә тормышка ашырабыз. Әлегә китүчеләр белән биредә калучылар нисбәте – 50 гә 50. Ләкин яшьләрнең акрынлап кайту тенденциясе күзәтелә: шәһәрдә белем алганнан соң, күпләр районга кире кайта.

Бездә яхшы һәм перспективалы эш өчен дә һәрнәрсә бар – предприятиеләрдә кайчак гаиләнең берничә буыны хезмәт куя. Рәхәтләнеп ял итү өчен дә шартлар җитәрлек – мәдәният йортлары, китапханәләр, спорт комплекслары эшли.

КУКМАРАЛЫ ПОРТРЕТЫ

– Кукмара кешесе нинди ул? Биредә калганнары да, әйләнеп кайтканнары да?

– Кукмаралылар – иҗади, һөнәрле һәм акыллы халык. Җитеш-мул тормыш булдыру өчен, алар юкны бар итә, курыкмыйча теләсә кайсы эшкә тотына. Бик таләпчән халык та алар, беренче чиратта, үз-үзләренә карата. Аларда, ягъни бездә бөтен нәрсә иң яхшысы булырга тиеш.

ХУҖА КЕШЕНЕҢ ҮТКЕН КҮЗЕ

Җанына якын Кукмараның истәлекле урыннарына соклана-соклана, кунаклар белән бергә шәһәр буйлап сәяхәт иткәндә, экскурсоводыбызның, юк-юк дигәндә дә, туктап, кемгәдер шалтыратуын, кырыс тавыш белән берәр җитешсезлекне төзәтергә, эшне хәл итәргә кушуын күрәбез. Нинди кимчелек турында сүз барадыр – анысы шул хуҗа кеше күзенә генә күренә.

– Кайвакыт йөреп кайтырга дип эштән чыгам да кайда нәрсә җитешмәгәнен күрәм, – дип аңлата Сергей Димитриевич. – Телефонга фотога төшерәм дә, мәсьәләне хәл итәр өчен, бу участок өчен җаваплы кешеләргә җибәрәм. Паркларда да, скверларда да бернинди максатсыз, болай гына йөри алмыйм. Безнең сәнәгать яки авыл хуҗалыгы предприятиеләре территорияләрендә генә чын күңелдән ял итәм, дип әйтә алам – эшнең кайнап торуын күзәтергә яратам. Анда һәрвакыт тәртип булуы сөендерә. Нигездә, районыбызда һәрвакыт чиста. Кыш көне кар булмаска тиеш урында – карын, көз көне пычрагын, ә җәй көне тузанын таба алмассыз. Халык чисталыкта һәм тәртиптә яшәргә өйрәнә. Тирә-юньдә чисталык урнашканда, чүпләмәскә дигән шартлы рефлекс барлыкка килә. Җыештырылган урында түгел, ә чүпләнмәгән урында чиста була. Бу сүзләр Кукмарага бик туры килә.



ТАРИХИ ХАТАНЫ ТӨЗӘТҮ

– Сездә барысы да чиста-пөхтә, ничек дөрес, шулай кебек тоела. Хаталар бөтенләй булмыймыни?

– Бар бездә бер тарихи хата, – ди башлык. – Хәзер аны төзәтәбез. Кукмара сәнәгатенә нигез салучылар – бертуган Комаровларга һәм бертуган Родигиннарга һәйкәл куярга ничектер вәгъдә җитми торды. Мактаулы хезмәт җимеше – киез итеккә һәйкәл бар бездә. Ә аларның үзләренә юк.

Тиздән Комаровлар утарында бертуганнарның һәйкәле пәйда булачак. Ә музей янындагы мәйданга Родигиннар һәйкәле куелачак.

– Ә сезнең атаклы «Кукмара» табасына һәйкәл?

– Анысы да быел булачак, – дип вәгъдә бирә Сергей Димитриевич.

4 – Бездә киез итеккә һәйкәл бар, ә киез басу эшенә нигез салучыларга – юк.

5 – Гырон быдтон – ул һәрвакыт искиткеч тәэсирләр, кызыклы бәйгеләр, җыр һәм биюләр дигән сүз. Һәм, әлбәттә, бу – халыкның үзенчәлеген, аның телен һәм традицияләрен саклау да, төрле милләт кешеләре арасында дуслыкка һәм үзара аңлашып яшәүгә нигез дә.

6 Кунакчыл Кукмара сезне көтә! Рәхим итегез!

БАРЫГЫЗНЫ ДА ГЫРОН БЫДТОНГА ЧАКЫРАБЫЗ!

Кукмара районында унлап милләт халкы – татарлар, руслар, удмуртлар, марилар һ.б.лар дус-тату гомер кичерә. Мәсәлән, Татарстан удмуртларының күпчелеге нәкъ менә биредә яши. Балалар туган телләре – удмурт телен мәктәптә өйрәнә.

– Кукмарада район мәдәният йорты базасындагы 14 коллектив халык ансамбле исемен йөртә. Аларның күбесе – удмуртларныкы, – дип дәвам итә экскурсоводыбыз. – Мәсәлән, Лельвиж авылы мәдәният йортындагы «Купанча» фольклор ансамбле, Урта Кукмара авылы мәдәният йортындагы «Зангари» фольклор ансамбле, Нырья мәдәният йортының – «Сактон», Биер авылы клубының «Инвожо» ансамбльләре...

Мин хәзер ни өчен удмуртлар турында шулай җентекләбрәк сөйлимме? – ди Сергей Димитриевич. Һәм үзе үк җавап та бирә: – Эш шунда: тиздән Кукмарада удмурт милли бәйрәме – Гырон быдтон узачак. Ул язгы кыр эшләренең тәмамлануын белдерә һәм «сабан бетү» дип тәрҗемә ителә. Бу бәйрәм ел саен төрле районнарда уза. Һәм менә 17 июньдә республикакүләм Гырон быдтон бәйрәме безгә – Кукмара районының Нырья авылына кунакка киләчәк. Без инде аңа әзерләнәбез. Программа эчтәлекле, кызыклы һәм күңелле булачак. Беркемгә дә кәефсезләнергә ирек бирмәбез. Беркем дә сыйланмыйча китмәячәк. Былтыр без Шәһәр көнендә иң зур бәлеш пешереп, Россиянең Рекордлар китабына кердек. Быел төрле ярмалардан ботка пешерергә уйлыйбыз.

Гырон быдтон – ул һәрвакыт искиткеч тәэсирләр, кызыклы бәйгеләр, җыр һәм биюләр дигән сүз. Һәм, әлбәттә, бу – халыкның үзенчәлеген, аның телен һәм традицияләрен саклау да, төрле милләт кешеләре арасында дуслыкка һәм үзара аңлашып яшәүгә нигез дә.

Без кунакларга бик шат – килми калмагыз!

ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР МИРАСЫ

Әлбәттә, Кукмара районы Гырон быдтон белән генә дан тотмый. Һәр авылда диярлек районның матди булмаган мәдәни мирасы объектына әверелгән ниндидер үзенчәлекле җирле бәйрәмнәр бар. Мәсәлән, Зур Сәрдек авылында **Самавыр бәйрәме** үткәрелә. Табын янында чәйләп алырга, төрле рецептлар белән бүлешергә, туган телдә җырлап, әйлән-бәйлән биеп, күңел ачарга яраткан һәркем өчен шәп бәйрәм. Самавыр белән чәй эчү гадәтен яңарту дияргә мөмкин.

Татар халкының **календарь йоласы – «Карга боткасы»** элек-электән Кенәбаш авылында билгеләп үтелә. Ул май бәйрәмнәренә туры килә, бу исә анда авыл халкына гына түгел, ә шунда туып-үсеп, инде күптән башка шәһәрләрдә яшәүчеләргә дә катнашырга мөмкинлек бирә.

«Юон сям» дип исемләнгән кунак җыры Яңа Каенсар авылы удмуртлары тормышында аерым урын алып тора. Мондый җырлар ярдәмендә халык яшьләрне күркәм рәвештә шатланырга, бәйрәм итәргә, кайгы-хәсрәткә сабырлык белән түзәргә өйрәткән.

«Сигезле мари биюе» – катнашучылар чылбыры бер чакрымнан артыгракка сузылган иң зур бию. Мултан авылы марилары башкара торган «сигезле» биюенең үз үзенчәлеге бар. Анда кызлар бию вакытында такмак әйтә. Ир-атлар исә, бертуктаусыз «сигезле» хәрәкәте ясый-ясый, тыпырдатып бии. Өзлексез биюне күзең талганчы карарга була.

«Сөрән» бәйрәме Күкшел авылында сакланып калган. Ул авыл Сабантуена бер көн кала үткәрелә. Егетләр – югары сыйныф укучылары һәм узган елгы чыгарылыш укучылары – бу йолага бер ай алдан әзерләнә. Алар алма бакчасында гармунга кушылып яңа җырлар һәм биюләр өйрәнә. Бәйрәм Сабантуйга яулык һәм башка бүләкләр җыюны күздә тота. Җәй булуына карамастан, кара чалбар, ак күлмәк һәм түбәтәй кигән егетләр авыл буйлап киез итектә йөри. Төнлә алар һәр ишегалдына кереп, татарча җырлый, гармунга бии. Ә авыл халкы исә ишегалдында чәй табыны оештыра, Сабантуйга тапшырыр өчен, төнге кунакларга бүләкләр бирә.

КУКМАРАГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Гомумән, тормыш кызыклы, туристлык маршрутлары эшләнгән: «XX гасыр башы мари йорты» кебек этнографик сәяхәт дисеңме; «Ишман бабай тыюлыгы» кебек таныштыру юнәлешендәгесеме; фирма кибетенә керүне дә күздә тоткан «Кукмара металл савыт-саба заводы» АҖ кебек сәнәгать маршрутымы; «Кукмара манзаралары» кебек экологик сәяхәтме... Аларга киез итек фестивале, милли бәйрәмнәр: Сабантуй, Питрау, Чакара, Пеледыш пайрам, Семык, Гырон быдтон өстәлә – җаның ни тели...

Кунакчыл Кукмара сезне көтә! Рәхим итегез!

6

Гырон быдтон

УДМУРТ МӘДӘНИЯТЕ РЕСПУБЛИКА БӘЙРӘМЕ ПРОГРАММАСЫ

Кукмара районы Нырья авылы | **2023 елның 17 июне**

09:00-10:00	**Катнашучы коллективларны каршы алу һәм теркәү** Мәйданчык: Нырья авылы мәдәният йорты
10:00-17:00	**Бәйрәмдәге интерактив мәйданчыклар эше** Мәйданчык: «Куно корка»
10:00-17:00	**Декоратив-гамәли сәнгать әйберләре күргәзмә-ярминкәсе** Мәйданчык: «Вузкарон»
11:00-12:00	**Бәйрәмне ачу** Мәйданчык: «Шулдыръясьскон» (Үзәк алан)
12:00-13:00	**«Айкай» Дәүләт фольклор җыр һәм бию театрының концерт программасы** Мәйданчык: «Шулдыръясьскон» (Үзәк алан)
13:00-17:00	**Татарстан районнары фольклор коллективларының концерт программасы** Мәйданчык: «Шулдыръясьскон» (Үзәк алан)
16:00-17:00	**Ирекле микрофон**
13:00	**Россия Рекордлар китабы белгечләре катнашында изге удмурт боткасын пешерү**
12:00-14:00	**«Чеберина но Батыр» республика матурлык һәм талантлар конкурсы** Мәйданчык: Кече сәхнә
10:30-17:00	**Удмурт гаиләләре республика конкурсы** Мәйданчык: Кече сәхнә
12:00-17:00	**Уен мәйданчыгы, милли уеннар** Мәйданчык: «Гырон быдтон шудонъёс»
17:00-23:00	**Кичке бәйрәм концерты** Мәйданчык: Нырья авылы мәдәният йорты

13-17 июнь – Кукмара районының М.П.Прокопьев ис. Нырья урта гомуми белем бирү мәктәбендә «Бигерд» удмурт яшьләре төбәкара форумы

ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ 100

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ МАТУР.

КУКМАРАНЫҢ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ

– Дөньядагы иң матур музейга рәхим итегез! – дип каршы алды кунакларны Кукмараның туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре. Һәм чыннан да бусагадан атлауга, бу сүзләрнең дөреслегенә ышанасың. Чөнки…

…Чөнки, беренчедән, ул 1870 елгы бик матур тарихи бинада урнашкан, анда элек бертуган Родигиннар ширкәтенең киез аяк киеме фабрикасы булган. Бина архитектура һәйкәлләре реестрына кертелгән һәм «Мирас – Наследие» программасы ярдәмендә 2010 елда тулысынча реставрацияләнгән.

Икенчедән, музейның эчендәге тарих тышындагыдан ким түгел. Экспозиция төбәкнең иң борынгы чорлары белән таныштыра. Кукмара тирәсендә табылган мамонтның балтыр һәм оча-бот сөякләре зурлыклары белән шаккатыра. Алар белән бергә тешләр, яңак сөякләре, кабырга һәм гаҗәеп зурлыктагы казык сөякләрен дә күрдек. Бу стендта мамонт янәшәсенә йонлач мөгезборын да урын алган. 10-12 мең еллар элек Кукмара җирендә яшәгән бу хайванның балтыр сөяген берәү үз бакчасында казып алган һәм музейга китереп биргән.

Ә Кукмара бистәсе, Мәчкәрә авылы һәм Олы Кукмара каберлегендә барган археологик казынулар вакытында табылган фин-угор хатын-кызларының көмеш бизәнү әйберләре чал тарихка, бүген Кукмара районында яшәгән халыкларның борынгы бабаларына ишарәли.

ПРЕДМЕТЛАР ТУРЫНДА…

Музей экспозицияләргә бүленгән, аларның һәрберсе ниндидер тарихка бәйле, бу турыда андагы предметлар сөйли.

Менә бакыр эретү заводы турындагы тарих. Ә бу Володиннарның XIX гасырдагы бакыр савыт-саба – поднос, самавыр, кулъюгыч, комган фабрикасы турында… Экспонатларга хәтта «Въ Кукморъ. Александр Володин» дигән тамга да сугылган.

Менә кәгазь акчалар тарихы: һәр акча, чыгарылу елына карап, зурлыгы буенча кеченәрә барган…

Кукмараның һөнәрчелек кәсепләре турындагы тарих: итек турында калып, өлге, бәләк кебек әйберләр сөйли. Йон язу-тарау өчен кулланылган махсус тараклар мамык шәл бәйләүгә карый. Ә менә «качедык» дип аталган кызыклы экспонат – ул чабата үргәндә кирәк булган.

Александр Ефремов фотолары

ФЕТНӘЧЕ ТУРЫНДА...

Тарихның һәр чорында сугышлар булган. Музей экспозициясендә шуларның икесе чагылыш тапкан. Беренчесе – Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы.

– Анда безнең якташыбыз – Кукмара районы Пычак авылы кешесе Мәсәгут Гомәров катнашкан, – ди экскурсовод. – Ул Пугачев манифестын төрле телләргә тәрҗемә итә. Авылларда, өйдән-өйгә йөреп, аның текстын укый, халыкны фетнәчеләр сафына өнди. Башта Мәсәгут йөз кешелек гаскәр җыя, аннары 1,5 мең кеше җыела. Гаскәрдәге кешеләр саны 3000 гә җиткәч, алар Казан ягына юл тота. Ләкин анда фетнәче кулга алына. Мәсәгутне каты җәзага тарталар. Яңагына кайнар өч хәреф бастыралар: З – злодей, Б – бунтарь һәм И – изменник. Күзләрен чокып алалар, һәм шул хәлдә сөргенгә җибәрәләр...

ГОСПИТАЛЬ ТУРЫНДА...

Сугышка кагылышлы икенче тарих безгә 2786 нчы эвакогоспиталь турында сөйли. Бөек Ватан сугышы вакытында, 1941 елда, Кукмараның беренче һәм икенче мәктәпләре территориясендә госпиталь ачыла.

Мәсәлән, шул вакытта хастаханәгә куелган караватта яраланган солдатның халаты ята. Фотолардагы дәваланучы солдатлар да шундый халаттан. Менә фронтка җыелган посылка, анда – махорка, такта чәй, җылы оекбаш һәм бияләйләр. Бияләйләре үзенчәлекле: чакмага басарга уңайлырак булсын өчен, тылдагы хатын-кызлар аның имән бармак турысын аерып бәйләгәннәр.

Кукмарадан фронтка 18 000 кеше киткән. Бары тик 7 000е генә туган якларына кире әйләнеп кайткан.

КӘРӘЗЛЕ ТЕЛЕФОННЫҢ АТА-БАБАСЫ ТУРЫНДА...

Бүгенге кәрәзле телефонның килеп чыгышы коммутатор тарихына барып тоташа. Бу могҗизага тиң тарихны балалар бик яратып тыңлый. Алар кесә телефоныннан башка кешеләрнең ничек яшәвен һәм гомумән ул вакытта җир йөзендә яшәү булганмы-юкмы икәнен күз алдына

да китерә алмый! Экскурсовод, елмаеп, монда телеграф хезмәткәре утырганын, кешеләрне бер-берсе белән төймә һәм чыбыклар ярдәмендә тоташтырганын аңлата...

ТИМЕР ЮЛ ТУРЫНДА...

Кукмарада тимер юл фабрикант Николай Васильевич Комаров тырышлыгы белән салына. Проектта бу якларга кереп тору каралмаган була. Ләкин Комаровка үз товарын Россиянең башка төбәкләренә озатырга, чимал буларак йон ташырга кирәк була. Ул юл төзүчеләрне расланган проектны үзгәртергә үгетли. Хәтта юлчыларны сатып алган, юл Кукмара аша үткәндә, аларга зур суммада акча вәгъдә иткән, дип сөйли легенда. Юл төзелә, ләкин фабрикант үз вәгъдәсен үтәми. Нәрсә эшләргә? Юл салынган, аны киредән сүтеп булмый. Әмма төзүчеләр вокзалны Кукмараның иң биек калкулыгына салып, сүзендә тормаган фабрикантка үчләрен кайтаралар, чөнки товарны калку урынга ташу бик җиңел булмый. Шуңа да карамастан, Кукмарада тимер юл бар, аның аша елына 100 мең кеше уза. Хәзер тимер юл вокзалына кадәр җәмәгать транспорты йөри.

КӨНДӘШЛЕК ТУРЫНДА...

XIX гасырга караган кием шкафын, буфет, язу өстәле һәм кәнәфине музейга киез итек-киез комбинатының элеккеге директоры Шамил Михәйдәрович Әхмәтшин бүләк итә. Җиһазлар Николай Комаров гаиләсенеке. Шуңа күрә музей аның көндәше фабрикант Родигин фабрикасы бинасында урнашкан булса да, әлеге экспозицияне «Николай Васильевич Комаров кабинеты» дип йөртәләр. Шул рәвешле музей XXI гасырда XIX гасыр көндәшләрен берләштерә.

Пыяла астына куелган металл тамгалар элек һәр пар киез итеккә беркетелгән була. Аларны бүген дә Россиянең төрле төбәкләрендә табалар, чөнки бөтен ил Кукмарадагы бертуган Комаровлар һәм бертуган Родигиннар баскан итекне кигән.

Шунда ук исәп-хисап дәфтәрләре – хәзерге хезмәт кенәгәләренең прообразлары, анда кем ничә сәгать эшләгән, күпме ял иткән – барысы да язылган…

ИТЕКЛӘР ТУРЫНДА...

Һәм иң төп экспонат – киез итек үзе. Аларны безнең көннәргә кадәр саклау аеруча авыр, чөнки көя күбәләге тик тормый: элек тә, хәзер дә йон әйберләрне яратып ашый. Ләкин музейда итекләр яхшы саклана, чөнки махсус матдәләр белән эшкәртелә, көя килә алмый.

Кулдан төрле бизәкләр чигеп ясалган киез итекләр аеруча кыйммәтле. Бүген мондый бизәкләрне заманча технологияләр кулланып чигәләр.

ИШМАН ШӘҖӘРӘСЕ ТУРЫНДА...

Музейның бер диварын зур нәсел агачы – шәҗәрә бизи.

– Әлеге нәсел агачын Мәчкәрә (элек Ишман) авылында таптык. Анда 500 дән артык исем теркәлгән, ул 1600 елдан башлана. Күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов та әлеге нәселдән чыккан. Аның бабасы Хәмзә бай 1 нче гильдия сәүдәгәр булган һәм Мәчкәрә авылында яшәгән. Үзенең нәсел тамыры турында Чыңгыз Айтматов 2006 елда, шагыйрь Муса Җәлилнең 100 еллыгын бәйрәм итәргә килгәч, музейның элеккеге директоры Ләбүдә Әхмәтфида кызы Дәүләтшинадан ишетә. Очрашудан соң ул музейга хат җибәрә. Анда мондый юллар бар: «Әнием ягыннан бабаларым – Әхмәтвәлиевләр шәҗәрәсен төзү турындагы мәгълүмат өчен ихлас рәхмәтемне юллыйм. Сез безнең Кукмара җирендәге шәҗәрәбезне торгызгансыз. Хәзер бу урын, бу авыл минем өчен изге булачак».

Мәчкәрә авылында тагын бер кызыклы объект – сәүдәгәр Үтәмешевлар йорты бар. Әлеге нәсел варислары да Кукмара музее геройлары. Мәсәлән, Рөстәм Исмәгыйль улы Үтәмешев Белка белән Стрелканы галәмгә очуга әзерләгән.

Һәм тагын бу авылда «Зөләйха күзләрен ача» фильмының кайбер күренешләрен төшергәннәр.

«КАЗАН СӨЛГЕСЕ» ТУРЫНДА...

Кукмара музеенда экскурсия бөтенләй көтелмәгәнчә тәмамлана. Иң матур экспонатларның берсе – борынгы чигеш үрнәкләре белән бизәлгән «Казан сөлгесе» музейның хәзерге хезмәткәрләре тарафыннан кулдан чигелгән булып чыкты.

– Музей хезмәткәрләре турында, алар бернәрсә дә эшләми, музей тузанын сулап, тик кенә утыралар, дип уйлыйлар гына, – дип көлә экскурсовод Сиренә Сабирова.

Бүген музейдан кеше өзелми. Балалар һәм өлкәннәр өчен төрле мастер-класслар, лекцияләр, музей территориясендә кызыклы шәхесләр белән очрашулар, туристлар һәм кунаклар белән көндәлек эш... Ә сөлге исә эштән бушаган мизгелләрдә башкарылган иҗат җимеше...

Музей директоры Рамилә Мәхмүт кызы Хәсәнова безгә истәлеккә мастер-классларның берсендә кулдан басылган сувенир итекләр бүләк итте һәм, без китүгә, тагын бер төркем кунакларны каршы алды. Бүгенге туристның туган як тарихы белән кызыксынуы музейны 24/7 режимында эшләргә мәҗбүр итә.

ШӘҺӘРЧӘ КИЛЕШЛЕ УҢАЙЛЫ АЯК КИЕМЕ

Россиядә киез аяк киемнәре җитештерә торган иң эре предприятие – Кукмара киез итек-киез комбинаты продукциясенең ассортименты теләсә нинди ихтыяҗны канәгатьләндерә ала.

Бүген комбинат ассортиментында йөзләгән заманча модель исәпләнә. Сайлау мөмкинлеге, чыннан да, бик зур. Балыкка бару яки болай гына йөреп кайту өчен киез итекләр, көндәлектә кияр өчен ботинка һәм итекләр, складларда, җылытылмый торган биналарда эшләү өчен пималар һәм кыска итекләр, йорт өчен чүәкләр, проблемалы һәм киң аяклар өчен йомшак башмаклар, офис өчен модалы лоферлар, яшьләр өчен челси һәм берца модельләр... Биредә елына 562 мең пар аяк киеме чыгарыла. Шундый эш күләме белән брендлы продукциянең сыйфатын ничек саклап була?

– Комбинат өч юнәлештә үсә – киез итек басу, киез җитештерү һәм киездән тегелгән аяк киеме җитештерү, – ди «Кукмара киез итек-киез комбинаты» АҖ генераль директоры Ләлә Шәрипова. – Сатып алучы өчен «Кукмара киез итекләре» бренды һәрвакыт, шул исәптән бүген дә, яхшы сыйфат дигәнне белдерә... Март башында чимал базары шактый тетрәнеп алуга, бәяләре ким дигәндә 45% ка күтәрелүгә, чимал белән тәэмин итүдә тоткарлыклар башлануга карамастан, комбинат коллективы авырлыкларны җиңеп чыга алды. Бездә план бар. Җитештерү процессы туктап торырга тиеш түгел. Кайдадыр тәэминатчыны үзгәрттек, кайдадыр, сыйфатка зыян китермичә генә, комплектлау өчен кирәкле материалларны алыш-

Фотолар «Кукмара киез итек-киез комбинаты» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

тырдык. Үз запасларыбыз да булышты. Сатып алу эшендә дә таләпчәнлек, үҗәтлек күрсәтергә туры килде. Югалтуларсыз гына булдыра алдык, ахыр продуктка бәяләрне минималь дәрәҗәдә генә күтәрдек. Иң мөһиме – без югары сыйфатлы һәм арзанлы бәяләрне саклап кала алдык.

Комбинатның төп чималы – 100% сарык йоны. Сатып алынган йонның һәр партиясе беренчел контрольне уза. Чимал белән тәэмин итүчеләребез ышанычлы һәм даими.

Киемнәрдән тыш, аяк киеме җитештерү өчен кирәкле фурнитура да зур күләмдә сатып алына: җилем, олтан, спилок-велюр, йон полотносы, молнияләр, шнурлар... – алар санап бетергесез.

Комбинат лабораториясе, йонны кабул итеп алганда, беренчел контрольне уздыра.

Безнең аяк киемнәре сыйфатлы булсын һәм барлык таләпләргә һәм стандартларга туры килсен өчен, итек басу һәм киез җитештерү цехларында ярымфабрикатларның һәм әзер продукциянең авырлыгы, гомуми үлчәмнәре тикшерелә.

Бүген гадәти киез итекләр дә, бу аяк киеменең заманча модельләре дә трендта. Моданың әйләнеп-әйләнеп кайтуы – факт. Бу киез итекләргә дә кагыла, алар төрле фасонда, төрле төстә, чигүле, бизәкле... Киез итекләр, әлбәттә, искиткеч уңайлы һәм җылы аяк киеме, ләкин бу әле алар стильле һәм модалы булырга тиеш түгел дигәнне белдерми. Шуңа күрә Кукмара киез итек-киез комбинаты дизайнер-

САННАР СӨЙЛИ

2022 елда Кукмара киез итек комбинатында:

- **216 мең пар** киез итек
- **186 мең пар** киез аяк киеме
- **291 тонна** киез җитештергәннәр

Кукмара продукциясенең бәя диапазоны да шактый киң. Һәр сатып алучы үзенә аяк киемен үз зәвыгына гына түгел, акча янчыгының калынлыгына карап та сайлый ала.

лары һәм белгечләре дөнья аяк киеме базарындагы барлык яңалыкларны күзәтеп-карап тора. Аларның киез итекләре бүген, дизайн ягыннан бер дә калышмыйча, башка аяк киемнәренә сизелерлек көндәшлек тудыра.

ЧИРАТ?! ТҮБӘТӘЙГӘ КЕМ СОҢГЫ?

Сатып алучылар һәрвакыттагыча милли колоритлы – чигүле, бизәкле аяк киемен үз итә. Андыйлар республикадан читтә яшәүче милләттәшләребездә аеруча популяр. Бөтенроссия сабантуйларында кукмаралыларның сәүдә нокталары янында җыен куначлары, киез түбәтәйләр, «читек» стилендәге итекләр, намаз уку өчен җыелмалар, чүәкләр сатып алыр өчен, чиратка тезелә.

Гомумән, милли аяк киеме белән кызыксыну аларның уникаль җылылык көйләү сыйфатына гына бәйле түгел, әйе, киез аяк киемендә кышын җылы, ә җәен эссе түгел. Мода белгечләре фаразынча, этностиль подиумнарда да, шәһәр урамнарында да озакка тоткарланачак әле.

МАТУРЛЫК КОРБАН СОРАМЫЙ

Кукмара фабрикасының табаннарына предприятие логотибы сугылган, басып ясалган киез итекләренең (самокаткаларның) сыйфатына тел-теш тидергесез. Чөнки аларны басканда, үсемлек калдыкларыннан арындырылган һәм юылган сарык йоны гына кулланыла.

Тагын бер өстенлек – алар кислотасыз эшкәртелә, бу исә йонның файдалы үзлекләрен тулысынча саклап калырга мөмкинлек бирә.

Аяк киеменең җайланган шәкеле фәнни-тикшеренү институтлары тарафыннан эшләгән һәм аякның анатомик рәвешенә ия калыплар бәрабәренә гарантияләнә.
Матур, тыгыз

һәм шул ук вакытта чама белән йомшак киез итекләр, кигән чакта утырмыйча, сезгә озак еллар хезмәт итәчәк.

Кукмара киез итек-киез комбинаты ассортиментында яңа төр аяк киемнәре генә түгел, инде күп еллар чыгарыла торган модельләр дә сатыла. Экологик, сыйфатлы, уңайлы аяк киемнә-

рен өлкән буын кешеләре һичшиксез хөрмәт итә. Хәзерге заман кешесенең тормыш рәвеше тиз үзгәрүчән. Һәм аяк киемен ул үз ритмына яраклаштырып сайлый. Күп кенә яшьләр дә натураль составлы, уңайлы һәм практик аяк киемнә көннән-көн күбрәк өстенлек бирә. Бу киез итекләргә дә кагыла.

ЖЫЛЫ ДА, МОДАЛЫ ДА

Кукмара аяк киеме – ул җылылык һәм уңайлык яратучы бик күпләр тарафыннан югары бәяләнгән оригиналь продукт. Заманча киез итекләр – аяк киемнәре дөньясындагы чып-чын сәнгать әсәре ул. Шулай булгач, хәзер «җылы» һәм «модалы» дигәннәр арасында сайлап торасы юк.

Идеаль аяк киеме ул уңайлылык, югары сыйфат, табигый материаллар, матурлык һәм арзан бәянең берләшүеннән барлыкка килә. «Кукмара киез итекләре» бренды продукциясен сатып алганда, сез тиңе юк товарга ия буласыз, дип раслый Кукмара халкы. Аларның киез итекләре күп кенә проблемаларны хәл итәргә булыша:

• Кыш көне урамда туңудан, өшеп авыру әләктерүдән курыкмый йөри аласыз – аякларыгыз һәрвакыт җылыда булачак.

• Акчагызны янга калдырасыз. «Кукмара киез итекләре» – кулай бәяле, дөрес киеп йөргәндә һәм тиешенчә карап-тәрбияләп торганда, сезгә күп еллар хезмәт итәчәк табигый аяк киемнәре ул.

• Аякларга көн дәвамында уңайлы шартлар тәэмин итәчәк. Киез аяк киеме аяк рәвешен ала. Ул сезгә җайлаша, сез уңайсызлык, аякларда авырлык хисе тоймаячаксыз.

• Әгәр аякларыгыздан начар ис килү проблемасы бар икән, сез аны 100% онытырсыз. Йон җылылык көйләү үзлекләренә ия, ул тән дымын сеңдереп, аны парга әйләндерә. Аяклар һәрвакыт коры булачак. Тир исен чыгара торган бактерияләр барлыкка килү өчен мохит бөтенләй юк!

• Күңелгә хуш тагын бер ягы – йонның сәламәтлегезгә уңай йогынтысы булачак – ул кан әйләнешен яхшырта, артрит, артроз вакытында профилактика чарасы санала, буыннар сызлавын, аякларның арыганлыгын киметә, массаж эффекты ясый.

Киез аяк киеме һава торышы шартлары үзгәрүгә җайлаштырылган, шәһәр мохитендә көндәлек киеп йөрү өчен яраклы.

Кукмара киез итекләре белән элек-электән дан тота. Кукмарада киез итек-киез җитештерүнең 155 еллык тарихы бар. Кукмара киез итек-киез комбинаты «Бертуган Комаровлар сәүдә йорты»ның шәхси биләмәсе базасында төзелгән.
Кукмараны бөтен Россиягә таныткан атаклы киез итекләр инде шул вакытта ук чит илләрдә дә билгеле була. Алар Париж, Лейпциг, Брюссель сәүдә күргәзмәләрендә алтын һәм көмеш медальләр ала.

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

Күпләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоннар: (84364) 2-08-31,
8-800-250-11-32

Фирма кибете:
Адрес: Кукмара шәһәре,
Вахитов ур., 1
Телефон: (84364) 2-08-78

АЛТЫН КУЛЛЫ ОСТАЛАР ТӨБӘГЕ

Кукмара районы – инеш-елгаларга һәм тешне сындырырлык салкын сулы чишмәләргә (алар биредә 400 гә якын!) бай гүзәл табигатьле искиткеч төбәк ул. Әмма аның казанышлары табигый байлыклар белән генә чикләнми.

Казан ханлыгы чорыннан ук бу җирлектәге халык терлекчелек һәм игенчелек белән беррәттән төрле һөнәрләр белән дә бик мавыга. Күн иләү, киез итек басу, мех эшләнмәләр тегү, шәл бәйләү осталарын Кукмараның бүгенге икътисадына нигез салучылар дип санарга була. Район оешкан 1930 нчы елларда биредә «Ил» һәм «Ярыш» артельләре кебек җиңел сәнәгать предприятиеләре эшли башлый.

РАЙОН БРЕНДЛАРЫ

Һәм бүгенге көнгә кадәр киез итек басу-киез комбинаты, металл савыт-саба заводы һәм Кукмара тегү фабрикасы районадагы иң зур предприятиеләр булып кала. Әлеге брендлар бүген Татарстаннан читтә дә дан казанган – Кукмара районының сәнәгать секторы (ул җирле тулай продуктның 40 процентын тәшкил итә) республикабыз икътисадының нигезен формалаштыра бит.

СЫНАУЛАР СЫНДЫРМАГАН

Кукмара тегү фабрикасы – чал тарихлы предприятие. Ул 1956 елдан – бер төркем тегүченең үз җитештерү эшчәнлеген башлаган вакыттан бирле сафта. Әкренләп җитештерү биналары зурайтылган, цехларга тагын да камилләштерелгән җиһазлар куелган, хезмәт шартлары яхшырган. Димәк, продукция җитештерү күләме арткан һәм эшләнмәләрнең ассортименты төрлеләнгән.

Бүген предприятиедә 110 кеше эшли – кечкенә генә шәһәр өчен шактый зур коллектив бу. Хезмәткәрләр биредә дистәләрчә ел буе эшли, осталарның (төгәлрәге, остабикәләрнең – кием-салымны нигездә хатын-кыз тегә бит) тулы бер династияләре формалашкан.

Цехлар хәтта иң катлаулы 1990 нчы елларда да эшләвен дәвам иткән. Ә бит ул чакта Татарстан тегү берләшмәсенә кергән дистәләгән фабрикадан нибары өчесе генә ябылмаган.

ЕЛЫНА ИКЕШӘР КОЛЛЕКЦИЯ

Бүген ассортиментның зур өлешен балалар киемнәре тәшкил итә: бәби комбинезоннарыннан алып яшүсмерләр өчен модалы өс киемнәренә кадәр бар. Биредә, кутюрье остаханәсендәге кебек үк, елына ике тапкыр өр-яңа коллекция тудырыла – кышкы һәм язгы. Ә бу – яз һәм көз өчен 35 модель һәм кыш өчен дә шуның кадәр диярлек!

Фотолар Кукмара тегү фабрикасыннан алынды. РЕКЛАМА

Һәр коллекция маркетинг бүлеге тикшеренүләреннән башлана. Белгечләр сатып алучыларда нинди киемгә ихтыяҗ зур булуын ачыклый. Аннары конструкторлар эшкә керешә.

– Киемне җитештерә башлаганчы, җентекләп сыныйбыз. Балаларга уңайлымы-юкмы, каптыргычкесәләре җайлымы икәнен тикшерәбез, – дип сөйли фабрика генераль директорының җитештерү буенча урынбасары Марина Сәмигуллина.

– Кирәк булса, катламнар санын һәм җылыткыч материалның тыгызлыгын үзгәртәбез. Сайлап алу мөмкинлегебез зур: тыгызлыгы 60, 80, 120, 140, 160 г/м^2 булган материалларыбыз бар. Барлык кимчелекләрне бетергәч һәм техник советта раслагач кына, күпләп тегүгә керешергә була, – дип җитештерү серләрен ачтылар предприятиедә.

Өлкәннәр өчен кием-салым ассортименты да шактый киң – махсус эш киемнәре дә, куртка, пальто, кыска пальто да, тау чаңгысы костюмнары да тегелә биредә.

СЫЙФАТЫ ШӘП!

Кукмара фабрикасында сыйфатны бик кайгырталар. Актив һава алмашын һәм парүткәрүчәнлекне тәэмин итә торган мембраналы тукымалар файдаланыла. Җылыткыч катлам да бик уңайлы һәм күп тапкырлар юуга чыдам. Балалар киемнәренең эчлеге киҗе-мамык тукымадан тегелә.

Сүз уңаеннан, җылыткыч материалны да Кукмара инженер һәм технологлары үзләре уйлап тапкан. Материал сертификатлаштырылган һәм башка предприятиеләрдә дә кулланыла. Мәсәлән, югары тыгызлыктагы синтепонны җиһаз ясаучылар бик теләп сатып ала.

Кукмара фабрикасының плащлык тукымадан тегелгән барлык киемнәре дә шулай ук ГОСТ буенча стандартлаштырылган һәм сертификатлаштырылган.

Предприятие Мәскәү, Екатеринбург, Чиләбе, Оренбург, Казандагы, шулай ук илебез һәм якын чит илләрнең башка шәһәрләрендәге күргәзмәләрдә уңышлы катнаша.

Заказ бирү өчен исә Кукмарага барып йөрисе дә юк: моны предприятие сайтында эшләү мөмкинлеге бар. Фабрикада «Озон» сервисын да актив үзләштерәләр. Т

КУКМАРА ТЕГҮ ФАБРИКАСЫ ТАССР җиңел сәнәгать министрыының 1956 елның 22 сентябре боерыгы белән оештырылган. Фабриканың ачылу көне – 1956 елның 1 октябре.

«Ярыш» сәнәгать артеленнән фабрикага күчерелгән йөзгә якын хезмәткәр коллективның нигезен тәшкил иткән.

Баштарак фабрикада 32 кеше эшләгән, алар киҗе-мамык чалбарлар теккән. Кисү цехы да булган – кулдан, зур пычак белән кискәннәр. Күпләп тегүгә күчәргә кирәк булган, әмма тәҗрибәсез моңа ничек ирешергә соң?

Хезмәткәрләрне Казан тегү фабрикасына укырга җибәргәннәр – тегү җиһазларын көйләүчеләр, тукыма комплектлаучылар, кисү цехы эшчеләре, бухгалтерлар анда практика үткән. Ә менә Кукмара бистәсендәге һәм якын-тирә авыллардан килгән тегүчеләрне эш урынында гына өйрәткәннәр.

«Кукмара тегү фабрикасы» АҖ. 422110, ТР, Кукмара ш., Эшчеләр тыкрыгы ур., 1. ОГРН: 1021607752913; 28.09.2002 ел.
«Интернет Решения» ҖЧҖ. 123112, Мәскәү ш., Пресня яр буе, 10, С блогы, «Башня на набережной» комплексы. ОГРН: 1027739244741; 24.09.2002

КУКМАРА МЕТАЛЛ САВЫТ-САБА ЗАВОДЫ – ЗАМАНГА ЯРАКЛАШУ

Кукмара табалары – бер генә шик тә юк: республикада яшәүче һәр хуҗабикәнең өендә бар ул. Әле әниләрдән, әбиләрдән үк калырга да бик мөмкин. Инде соңгы елларда Кукмара табалары гына түгел, казан, кәстрүлләре дә хуҗабикәләрнең күңелен яулады.

«Мәңгелек» савыт-саба ничек ясала? Россия, БДБ илләрендә яшәүче кулланучыны ничек җәлеп иткәннәр? Кукмара металл савыт-саба заводында булып, иң алдынгы технологияләр белән эшләүнең нәрсә икәнен үз күзләребез белән күрдек.

ЧАЛ ТАРИХЛЫ ЗАВОД

Кукмара металл савыт-саба заводының тарихы бик борынгы – XVIII гасырга барып тоташа. Үз чорының атаклы сәүдәгәре Иван Васильевич Тряпицын бакыр эретү заводы төзи башлый, чөнки Кукмара җирлегендә әлеге металл ятмалары табыла. Нәтиҗәдә, 1743 елда татарлар яшәгән Туеш авылында бакыр эретү заводы цехлары эшли башлый. Шунда ук күпсанлы крестьян утарлары да барлыкка килә. 1851 елда завод ябыла, чөнки бакыр ятмалары саега. Революциядән соң Кукмара районының берничә авылында металл эшкәртү буенча яңа артельләр оеша. Бөек Ватан сугышы елларында тимерчеләр фронтка арба, чана һәм аларга тимер детальләр ясый. Сугыштан соң әлеге артельләр тагын да зуррак көч белән эшли башлый, шул елларда дәүләт карамагына керә. Биредә күпләп алюмин савыт-саба ясый башлыйлар. 1966 елда остаханә Казан металл эшкәртү комбинатының бер цехына әйләнә. Ә бер елдан, ТАССР Минместпромы карары нигезендә, «Кукмара металл савыт-саба заводы» буларак оеша.

Әле илле-алтмыш ел элек кенә алюмин торбалар, лэйкеләр ясаган заводны хәзер KUKMARA бренды иясе буларак бөтен Россиядә беләләр. Шулай ук чит илләр тарафыннан да кызыксыну зур.

– Мәгълүм вакыйгаларга кадәр безнең товар Германия, АКШ, Израиль, Канада кебек илләргә дә китә иде, – ди Кукмара металл савыт-саба заводының маркетинг бүлеге җитәкчесе Эльвира Бикеева. – Хәзер алар белән эшләү авыррак, ләкин шулай да элемтәләр югалмады. Бүген әзер продукцияне күпләп Мәскәү, Санкт-Петербургка озатабыз. Завод районның бюджет оештыручы предприятиесе санала. Шуның белән барысы да аңлашыладыр: районның һәр өченче кешесе бездә эшли. Әле Киров өлкәсеннән килеп эшләүчеләр дә күп. Бүгенге көндә заводта барлыгы 1300 якын кеше хезмәт куя. Эшчеләр турында сүз чыккач әйтми мөмкин түгел: алар махсус киемнәр белән тәэмин ителгән. Заводның үзенең бер дигән ашханәсе бар (төшке аш өчен компенсация каралган). Кем зарарлы цехта эшли, аларга өстәмә ташламалар бар.

– Завод буенча уртача хезмәт хакы күпме? – дим Эльвира Азатовнага.

– 80 мең алучылар да бар, эшенә карап. Ә уртача хезмәт хакы бездә 45 мең сум.

ЯҢА ЗАВОД - ЯҢА МАКСАТЛАР

Кукмара металл савыт-саба заводы заман белән алга атлый, дидем. 2021 елда яңа завод салганнар. Биредә тутыкмый торган корычтан савыт-саба ясыйлар. Ассортиментта туризм өчен кирәкле савытлар да бар. Заводта булып, барысын да үз күзләребез белән күрдек. Иске бинадан аермалы буларак, биредә барысы да заманча: якты, иркен цехлар, авыр исләр юк. Кем әйтмешли, утырып чәй эчәргә мөмкин. Завод-

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

ның түбәләреннән дә кояш карый, махсус шулай эшләгәннәр. Монысы эшчеләргә тудырылган уңайлыклар. Ә кулланучыга килгәндә, тутыкмый торган корычтан эшләнгән яңа төр савыт-сабаны күтәреп тә, әйләндереп тә карадык. Исең китәрлек! Бу бездә эшләнгән, сыйфатлы кәстрүл, табалар, чүеннар бит! Иманым камил, бер генә хуҗабикә дә аларга битараф калмаячак.

– Яңа заводта эшләнгән әлеге савыт-сабалар безнең горурлыгыбыз, – диде Эльвира Азатовна. – Алар төрле линиягә бүленгән: SAFIA, LEON. Заводка яңа җиһазларны Кытайдан алып кайттык. Башта иң яхшы белгечләребез Кытайга барып, җиһазларның ничек эшләвен өйрәнде. Аннан исә монда кайтып эшләтеп җибәрделәр.

– Яңа төр савыт-сабалар линияләргә бүленгән, дидегез. Карап торышка барысы да затлы кәстрүл, табалар, мантый пешерә торган савытлар кебек, – дим.

– Алар формалары, дизайннары белән аерыла. Мисал өчен SAFIA линиясе югары сыйфатлы хромникель корычтан AISI 304 (18/10) ясалган. Анда әзер ризыкны әзерләү генә түгел, ә озак вакыт сакларга да мөмкин, ә металлның сыйфаты аллергия барлыкка килү куркынычын булдырмаска ярдәм итә. SAFIA линиясендәге савыт-сабаларның калынлыгы 0,8 мм, шуның өчен дә ныклыгы югары: температура үзгәрешләренә дучар ителми, тырналмый һәм деформацияләнми.

Гомумән, Кукмара металл савыт-саба заводы иң беренче сыйфатка игътибар бирә. Чимал җитди контроль уза, шул исәптән радиация куркынычсызлыгы буенча да. Савыт-сабаның үзенең штрих-коды бар: ЕАН-13 (халыкара классификациясе буенча), шулай ук ГОСТ-Р сертификатларына ия.

– Заводка кайткан чимал, ягъни зур кисәк алюмин табакларны кире җибәргән очраклар да бар, – дип дәвам итте Эльвира Азатовна. – Технологлар аны кат-кат тикшерә. Заводта әзер продукциясне дә тикшермичә сатуга чыгармыйбыз: тулы бер бүлек шуның белән шөгыльләнә. Һәр савыт-сабаны кулдан уздыралар. KUKMARA брендына тап төшәргә тиеш түгел!

Кукмара металл савыт-саба заводының ассортиментында бүген 800 төрле (!) товар бар. Тәүлек әйләнәсе эшләүче завод Россиядә коеп ясалган алюминий савыт-саба җитештерүче иң алдынгы өч компаниянең берсе булып тора. Алга таба планнар зурдан, иң мөһиме – үсеш өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. 2021 елда төзелгән яңа заводта бүген йөзгә якын кеше хезмәт куя, тора-бара эшчәнлекне бермә-бер арттырырга була.

Завод җитәкчесе Азат Ясәви улы Заһидуллин турында да берничә сүз әйтәсе килә. Әлеге вазыйфага ул күптән – 1995 елда билгеләнә. Иң авыр елларда, илдә барган үзгәртеп кору чорында заводны бөлгенлеккә төшүдән саклап калган кеше ул. Артык тыйнак Азат Ясәви улы бу турыда күп сөйләргә яратмый. Гәрчә аны якыннан белүче кешеләр барысы да бер сүзне кабатласа да: завод эшчеләрен кайгыртып торучы, кешелекле җитәкче ул. Ә Кукмара өчен эшләгән изгелекләрен санап бетерә торган түгел...

...Кукмара савыт-саба заводыннан бер горурлык хисе белән чыктык. Беренчедән, шундый затлы савыт-сабаның үзебездә эшләнүе, икенчедән, никадәр халыкка эш урыннары булу зур куаныч! Өченчедән, бай тарихы булган завод бүген икенче яшьлеген кичерә. Дүртенчедән... KUKMARA – үзебезнеке! Ул исем киләсе гасырларда да данга күмелеп яшәвен дәвам итәр. Башкача мөмкин түгел!

Интернет-кибетнең адресы:
market.kukmara.com

«Кукмара металл савыт-саба заводы» АҖ, 422111, ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 154. ОГРН: 1021607752286; 22.07.2002.

ТАЛ ЧЫБЫГЫ ГЫНА ДИМӘГЕЗ...

Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне барлауны дәвам итә. Монысында тал чыбыгыннан кәрзин үреп карадык. Физик көч сорый торган хезмәт икән! Шуның өчен дә тал чыбыгы белән күбрәк ир-атлар эш итә. Без дә бу юлы әбигә түгел, бабайга кунакка бардык.

«АБЫЙДАН ӨЙРӘНДЕМ»

Тал чыбыгыннан нәрсә генә ясамыйлар: кәрзин, ваза, башка төр савыт-саба, читән, бишекләр... Бермәлне кулланылыштан төшеп калса да, хәзер андый әйберләргә игътибар зур. Табигыйлек модага керде.

Яңа Чишмә районының Әдәмсә авылында яшәүче Рәзил Дәүләтов тал чыбыгыннан кәрзин, ваза, читәннәр ясый. Бу эшкә ныклап торып лаеклы ялга чыккач кына алынган. Үзе өчен, эшсез тормас өчен.

– Беренче тапкыр тал чыбыгын кулыма утыз биш яшемдә алдым, – дип сөйләде Рәзил абый. – Свердловск өлкәсенең Качканар шәһәрендә яшәүче абыем Данис кайткан иде. Безнең дачага килгәч, уйсулыкта үскән талларны күреп, аның исе китте. «Боларны эшкә җикмичә ничек түзәсең?» – диде. Һәм бергәләп тал чыбыкларын сындырып, чистартып, кәрзин ясап куйдык. Мин аны әле һаман саклыйм. Истәлек бит.

Абыйсы биргән дәрес Рәзил абыйга җитә калган: сирәк булса да, тал чыбыгыннан нидер ясаштыргалаган. Ләкин эштә булганга күрә, бу шөгыльгә бик вакыты калмаган.

– Тумышым белән Башкортостаннан мин, Тәтешле районыннан, – диде Рәзил абый. – Ләкин туган яктан яшьли чыгып киттем. Башта армиядә булдым, аннан кайткач исә, Түбән Камага килеп урнаштым. Ул чорда яшьләрне фатир биреп кызыктырдылар. Минем кебек бик күп егет-кызлар Түбән Камага килеп төпләнде. Шунда гаилә кордык, өч бала – ике ул, бер кыз үстердек. Тик җәмәгатем белән картлык көнгә кадәр яшәп булмады – бакыйлыкка күчте.

Бәхетенә, Рәзил абый Рузилә апаны очрата. (Аның да хәләл җефете үлгән була.) Ир белән хатын егерме елга якын бергә гомер итә. Лаеклы

Фото: Илмир Хәбибуллин

ялга чыккач яшәрбез дип, Түбән Камада эшләгән чакта Әдәмсәдә йорт җиткергәннәр. Сигез елдан артык әнә шунда яшиләр.

– Әдәмсә Рузиләнең туган авылы, – диде Рәзил абый. – Башкортостанда туган авылым бетте дисәм дә була, берничә йорт кына калды. Балалар Түбән Камада яши. Аларга да якын булыр дип, биредә йорт салдык. Без бит авыл балалары, шәһәрдә дүрт стена арасында ятасы килми. Рузилә дә, мин дә, фатирларны балаларга калдырып, үзебез салган йортка күченеп кайттык.

«КУЛ КӨЧЕ КИРӘК»

Без килгәнче Рәзил абый тал чыбыгын кайнатырга куйган иде. Баксаң, чыбыкны кайнап торган суга салмасаң, ул эшләгәндә сына икән.

– Дөресен генә әйткәндә, бездәге таллар җиһаз ясар өчен бик кулай түгел, – дип аңлатты оста. – Әнә, Саба районының Лесхоз бистәсендә махсус таллар үстерәләр, алар яхшы. Ярар инде, мин профессионал түгел, үзем өчен генә ясыйм.

– Ә ясаган кәрзиннәрне сатмыйсызмы? – дим.

– Файдасы юк аның. Бер кәрзин 300–400 сум тора, зурлыгына карап. Ә күпме утырырга кирәк.

– Бер кәрзинне озак үрәсезме?

– Ике сәгать тирәсе. Ләкин бит аның эше күп – чыбыгын алып кайт, тышын каезла, кайнат, аннары яса...

Башта кәрзиннең төбен ясыйсы икән. Аның өчен калын тал чыбыклары кирәк. Рәзил абый, кар бөртеге рәсемен ясагандай, чыбыкларны бер-берсенә беркетте. Кояшны хәтерләткән түгәрәк барлыкка килде, оста «нурларны», ягъни чыгып торган чыбыкларны секатор белән кисеп атты. Һәм шул түгәрәк тирәли уналты чыбык кертеп, аларны өскә күтәртеп, җеп белән бәйләп куйды. Шул вертикаль торган чыбыкларга горизонталь чыбыклар кертеп, кәрзинне үрде.

– Кәрзиннең биеклеген теләгәнчә ясарга була, – диде Рәзил абый. – Чыбыклар озын бит, үреп менәсең генә. Аннары калган чыбыкларны аска таба бөкләп, бизәкләр ясыйсың. Монда инде фантазия эшкә җигелә...

Безнең вакыт чикле булганга, биек кәрзин ясамадык. Күбрәк ул ипи савытын хәтерләтте. Ләкин эш тәртибе аңлашылды.

– Физик көч сорый икән, – дим.

– Әйе, көч кирәк монда. Чыбыкларны тезгәндә, яхшылап бармак белән басып куярга кирәк. Ара калса, нык булмый, матур да түгел.

– Сез үскәндә авылда тал чыбыгы белән эшләүчеләр бар идеме? – дим.

– Күп түгел, ләкин бар иде. Ә безнең әтиәниләр үскәндә һәр йортта диярлек кәрзиннәр, ана казлар өчен бадъялар, балык тоту өчен җайланмалар (мурда), тагын әллә ниләр ясаганнар. Элек-электән үрелгән кәрзиннәрдә азык-төлек саклаганнар, чөнки табигый материал, җил йөри. Без дә үрелгән кәрзиннәр белән җир җиләге җыярга барабыз. Анда җиләк изелми һәм, пластмасса чиләк белән чагыштырганда, суланмый. Озак торса да, кәрзиндәге җиләк-җимеш әле генә өзелгән кебек була.

МАТУРЛЫК ЯРАТУЧЫЛАР

Эш беткәч, Рузилә апа безне өйгә чакырды – ит бәлеше пешереп куйган иде. Рәзил абый тал чыбыгы белән тышта гына әвәрә килә. Кышын гына җылы мунчада эшли.

– Рузилә өйдә чүпләмәскә куша, – дип елмайды Рәзил абый. – Чыбыклар бит теләсә кая оча, пычрак эш. Шуның өчен «остаханәм» урамда. Хәер, тал чыбыгыннан кирәк-ярак ясау өчен казан белән өстәл булса җитә. Кирәкле эш кораллары да күп түгел: секатор, «бокорез», без, пычак, ыргаклар.

Өйгә уздык. Хуҗаларның матурлык яратучы, иҗади кешеләр икәнлеге күренеп тора: өйнең стеналарына милли бизәкләр төшерелгән. Рәзил абый эше икән. Бөтен җирдә гөлләр үсә, картиналар, бизәкле агач урындыкларда бәйләнгән япмалар... Заманча йортта бер җылылык бар.

– Шәһәр фатиры кебек булмасын дип, Рәзил йортны шулай агачтан төзеде, – диде Рузилә апа. – Үзем исә чәчәкләр, гөлләр яратам, алары минем өстә.

Ир белән хатын Әдәмсәгә күченеп кайткач, авылның мәдәни тормышына кереп чумган. Икесе дә мәдәният йортына репетицияләргә йөри, авыл һәм районда сәхнәдә чыгыш ясыйлар. Рузилә апа ансамбльдә җырлый, Рәзил абый гармунда уйный. Берничә тапкыр «Балкыш» фестивалендә катнашканнар.

– Гармунда уйнарга үзлегемнән өйрәндем. Алты яшемдә мунчага барып, гармун тарта идем, – диде Рәзил абый.

Рузилә апа спорт белән дә дус – «Өченче яшь» спартакиадасы активисты, йөгерү һәм йөзү буенча муниципаль этап призеры, Казанда үткән дартс ярышында бронза призер...

Язманың видеоварианты да бар.

P.S.

...Күңеле матур кеше генә гүзәллек тудыра ала. Дәүләтовлар әнә шуның ачык мисалы. Ике ялгыз йөрәкнең шулай бергә кушылып, иҗади гаилә булып яшәүләре исә үзе бер матурлык.

«ТАТЛИФТ»: ХӘРӘКӘТ, ЭНЕРГИЯ, ТӘРӘККЫЯТ

Гомуми мәйданы 8 мең квадрат метрлы лифт җитештерү заводын башыннан ахырына кадәр төзү, күтәргеч механизмнарны серияләп чыгару эшен оештыру, һәм боларның барысын да өч балалы ана башкаруын күз алдына китерә аласызмы? Бу сорауга җавапны Идел буе федераль округында шундый зурлыктагы тәүге лифт төзү заводы – «Татлифт» компаниясенең генераль директоры Гөлшат Альберт кызы Заһидуллина яхшы белә.

«АКЫЛЛЫ ТЕХНИКА» – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

– Гөлшат ханым, Татарстанда лифт җиһазлары җитештерү заводын төзү буенча амбициоз проект гамәлгә ашырыла. Американың OTIS һәм Финляндиянең KONE компанияләре илебездән киткән яңа чынбарлыкта бу – бик кирәкле проект. Предприятиедә эшләр ничегрәк бара?

– 2021 елда без проектны Татарстан Инвестицияләр советында яkладык, аннары исә республика безгә, «Яшел Үзән» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (АСИҮТ) резиденты сыйфатында, «Яңа Тура» технополисы территориясендә ике гектарлы җир кишәрлеге бүлеп бирде. Хөкүмәтебез ярдәме һәм гомумән Татарстанда бизнеска булышу чаралары нәтиҗәсендә без төзелешне югары темпта алып барабыз. 2022 ел башына бина төзелеп беткән иде инде. Хәзер аны эшләтеп җибәрүгә әзерлек бара. Быел 3–4 нче кварталда файдаланугa тапшырырга ниятлибез.

– Хәзер инде без күп катлы йортны лифттан башка күз алдына да китерә алмыйбыз, ягъни күтәргечләргә ихтыяҗ бик зур. Өстәвенә, РФ Хөкүмәте төзелеш күләмен ел саен арттыра бару бурычын куя, һәм Татарстанда әлеге планнар гамәлгә ашырыла: безнең төбәк илдә торак төзү лидерларыннан берсе булып тора...

– Әйе, әле тагын иске лифтларны алыштыру зарурлыгы да бар. 2024 елга Россиядә мондый җиһазларның 140 мең берәмлеге искергән саналачак. Россия Федерациясендә елына 45 мең лифт чыгарыла, һәм безнең өчен үрнәк күләмнәр бар: мәсәлән, Төркиядә елына 250 мең, Кытайда исә бер миллион лифт җитештерелә. «Татлифт» заводының номиналь куәте – елына 3 мең лифт.

– «Татлифт» җитештергән күтәргеч җиһазлар нинди булачак?

– Барыннан да бигрәк, сыйфатлы, димәк, көндәшлеккә сәләтле. Иминлек һәм ышанычлылык иң мөһим санала, әмма без энергия саклау һәм шома йөреш характеристикаларына да зур игътибар бирәбез. Моннан тыш, бүген лифт бина дизайнының бер элементы да булып тора. Төзелеш компанияләре

Фотолар «Татлифт» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

«ТАТЛИФТ» 2,5 ТОННАГА КАДӘР ЙӨК КҮТӘРӘ АЛЫРЛЫК ҺӘМ ХӘРӘКӘТ ТИЗЛЕГЕ СЕКУНДЫНА 2,5 МЕТРЛЫ ЙӨК-ПАССАЖИР ЛИФТЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРА.

дә, яңа йортларда яшәргә теләүчеләр дә бик таләпчән – аларга тормыш сыйфатын яхшырта торган, стильле, уңайлы һәм «акыллы» лифтлар кирәк. Шунлыктан бездә эстетика белән дизайнер шөгыльләнә, лифтның тышкы кыяфәтенбизәлешен исә берникадәр вакыттан соң бик җиңел яңартып булачак. Безнең конструкторлык бүлегенең бурычы – завод продукциясен заманча таләпләргә яраклы итү.

ИТ-чишелешләргә килсәк, «Татлифт» үз җиһазларына лифтның хезмәт итү чорын мониторинглау функциясен кертә. Әлеге опцияне күпләп кертү Россия өчен әле яңалык булып тора. Лифтның кулланыштагы вакыты озак - 25 ел, кайсы детальләрне төзәтү яки алыштыру кирәклеген реаль вакыт режимында күрү мөмкинлеге – бик зур файда. Идарәче компанияләргә һәм торак милекчеләре ширкәтләренә хезмәт күрсәтү оешмаларының эшен контрольдә тоту җиңелрәк булачак.

Киләчәк планнарда горизонталь хәрәкәт итә торган баскычсыз конвейер-траволаторлар (алар әлегә Россиядә чыгарылмый), шулай ук эскалаторлар җитештерү дә бар.

– Импортны алыштыру мәсьәләсендә эшләр ничегрәк бара?

– Без күптән инде әлеге юнәлешне кайгыртабыз, һәм хәзерге вакытта «Татлифт» продукциясе детальләренең 95 проценты Россиядә җитештерелә. Иң катлаулысы – электрониканы алыштыру, тик без моны да хәл итү юнәлешендә эшлибез.

«БЕР ТӘРӘЗӘ» СИСТЕМАСЫ ТУРЫНДА

– Үз продукциягезне кайларда тәкъдим итәчәксез?

– Якындагы зур вакыйга – майда үтәчәк «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum-2023» Халыкара икътисад форумы. Анда без үзебезнең җиһазларны күрсәтәчәкбез. Киләчәктә исә шоурум төзү планлаштырыла, заказчы шунда килеп, җиһазларны үз күзе белән күрә алачак. Сүз уңаеннан, киләчәктә безнең заводта сынау шахтасы да пәйда булачак, әлегә исә җиһазларны инде эшли торган заводларда сыныйбыз.

– Кадрлар мәсьәләсен ничек хәл итәсез?

– Кешеләр – предприятиенең төп байлыгы, шунлыктан без, булачак хезмәткәрләребезне өйрәтү өчен, инде моннан ике ел элек үк белгечләр чакыра башлаган идек. Безгә Россиянең төрле почмакларыннан – Екатеринбург, Омскидан, башка шәһәрләрдән, шулай ук Белоруссиянең Могилев каласыннан үз эшләренең чын осталары килде.

Безнең алда катлаулы бурыч тора – лифтлар җитештерү генә түгел, ә «бер тәрәзә» системасын кертү: заказчы җиһазны проектлаудан башлап монтажлауга һәм гарантияле хезмәт күрсәтүгә кадәр кирәкле барлык эшләрне башкаруны берьюлы алырга тиеш.

– Сез Роспатентта үзегезнең «ТЛМоторс» сәүдә маркагызны теркәдегез. Бу атамага нинди мәгънә салынган?

– «ТЛ» «Татлифт» дигәнне аңлата, мотор исә – теләсә кайсы лифтның йөрәге. Киңрәк алсак – хәрәкәт итү, энергия, тәрәккыят символы. Бу сүзләр брендның асылын бик төгәл чагылдыра.

– Сез лифт төзү тармагына ничек килеп эләктегез? Гаҗәп бит: лифтлар җитештерү буенча Идел буе федераль округындагы иң беренче зур заводны төзү белән хатын-кыз шөгыльләнә.

– Әтием Альберт Нури улы Заһидуллин, электромеханик булып эшли башлап, лифтларга 50 ел гомерен бирде, мин инде – 21 елымны. 2000 нче еллар башында әтием лифтлар монтажлау һәм аларга сервис хезмәте күрсәтү буенча фирма төзеде. Мин дә шул эшкә кушылдым. Бу бик кызыклы тармак, иҗади даирә, шунлыктан без барыбыз да бераз мавыгучан (*елмая*). Республикада лифт җитештерү заводын салу минем гаиләмнең хыялы иде.

ӨСТЕНЛЕК БУРЫЧЛАРГА БИРЕЛӘ

– Сезнең өч балагыз да бар бит әле. Гаиләгә дә, шундый катлаулы хезмәткә дә вакытыгызны ничек җиткерәсез?

– Мин һәрвакыт максимум буенча яшәргә телəдем – бер генә өлкәгә дә зыян килмәскә тиеш. Якыннарың һәм хезмәткәрләрең өчен җаваплылык тоясың, аларның хуплавын күрәсең икән, вакыт та, көч тә һичшиксез табыла ул.

– «Җитәкче әни» булуның тәрбияви мәгънәсе дә бар бит әле...

– Әйе, бөтен нәрсәнең кулдан килерлек булуын үз мисалында күрсәтәсең. Балаларымның минем белән горурлануларын тою миңа бик рәхәт.

– Безнең һәркайсыбызның тормышында өмет уяткыч нинди максатлар булырга тиеш?

– Башкалар өчен әйтә алмыйм, үземнекеләрне исә атап китәм. Мин проблемаларга гына кайгырып утыру файдасыз, дип саныйм. Миңа кичәге көн турында сөйләү яки зарлануны тыңлау бер дә кызык түгел. Мине киләчәктә ирешәсе үрләр күбрәк кызыксындыра. Икенчесе – үз эшеңне эшләргә, һаман алга барырга кирәк, шул чакта күңел төшенкелеге өчен вакыт калмаячак.

Йолдыз Свободина әңгәмәсе

ТАТЛИФТ
КОМПАНИЯ
ТЛМОТОРС

info@tatlift.com
tatlift.com
88007707984

АННА ГУРЬЕВА, ПРОЕКТ БАШЛЫГЫ, UD GROUP КОМПАНИЯСЕ

КҮПФУНКЦИЯЛЕ ПРОЕКТЛАР – ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

Хәзер без «Тормышында ничә көн булуы түгел, ул көннәрендә күпме тормыш булуы мөһим» дигән гыйбарәнең никадәр дөрес булуын аңлый башлыйбыз. Даими киеренкелек тудыра торган үзгәрешләр чорында, болгавыр заманда кеше өчен гап-гади куанычларның кыйммәте арта. Тышкы кризислар тормыш тотрыклылыгын какшата һәм, югалган көч-куәтне торгызу өчен, безгә күбрәк ял итәргә, уңай тәэсирләр алырга, матур хисләр кичерергә кирәк.

– Без кинәт эш – өй – ял төшенчәләре арасындагы балансның тышкы вазгыятькә түгел, ә үзебезгә бәйле булуын аңлап алдык. Моның һәрвакытта да үзебез сайлаганның нәтиҗәсе икәненә төшендек. Чын тормыш өчен вакыт калдырырга омтылу үзмаксатка әйләнде. Без фатирларыбыздан, эштән читкәрәк китәргә, яңа тәэсирләр эзләргә тырышабыз. Андый тәэсирләрне уята алырлык урыннар тормышыбызда мөһим роль уйный башлый.

Һәркайсыбызның, тулаем алганда, җәмгыятьнең дә омтылышлары, киләчәк буыннарның фаразланган ихтыяҗлары урбанистик трендларга, торак һәм иҗтимагый проектлар булдыруга бәйле фикерләргә этәрә. Безнең UD Group компаниясе инде 20 елдан артык шәһәр инфраструктурасын һәм киңлекләрен үстерү белән шөгыльләнә. Без коммерциячел күчемсез милек объектларын проектлау, төзү, алар белән идарә итү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә экспертиза, тәҗрибә тупладык һәм һәр проектыбыз, чыннан да, уникаль булды, вакыт таләпләренә һәм клиентларның ихтыяҗларына туры килде.

Компаниябезнең исемен тар даирәләрдә генә белүләре белән еш очрашам, шул ук вакытта төзелгән («ГоркиПарк», Kazan Mall, UDACHA ритейл-паркы) һәм төзелә торган (ART комьюнити-үзәге, UNO КФК) объектларыбызны бик күпләр белә. Хәзерге вакытта күпфункцияле комплексларны коммерциячел куәтсез милекнең бүгенге заман кешесе таләпләренә җавап бирә торган иң актуаль форматы, дип карыйбыз.

«Күпфункцияле» дигән исеме үк проектның берничә функцияне үтәргә тиешлеген белдерә. Анда килүчеләр, тагын башка беркая да бармыйча, бик күп ихтыяҗларын канәгатьләндерә ала. Монда фатирлар яки апартаментлар, социаль объектлар, эш урыннары, күңел ачу һәм ял урыннары бер-берсенә якын, янәшә урнашырга мөмкин. Функцияләр җыелмасы төрле була ала, алар көйләнгән инфраструктураны исәпкә алып билгеләнә, аңа теге яки мәсьәләдәге кытлыкны һәм фаразларны күздә тоткан проект кертелә. Шул ук вакытта һәр ихтыяҗга һәм аудиториягә үз сценарие каралган булырга тиеш.

Күпфункцияле проектлар белән кызыксыну очраклы түгел. Без шәһәрләр үсешенең төп трендын күпүзәклелектә күрәбез. Шәһәр хәзер бер тартылу урыны яки хезмәт объекты тирәсендә төзелми. Халыкның бөтен кирәк-яракны янәшәдән генә юнәтү, куллану мөмкинлеге булсын өчен, төрле районнарда үзенә күрә бер үзәк барлыкка килә. Мондый алым транспорт челтәренә йөкләнешне дә киметә. Шунысы да бик мөһим: әлеге үзәкләр кешенең вакытын һәм энергиясен янга калдыра.

Казанның Сибгат Хәким урамында төзелә торган UNO проектында без торак, балалар бакчасы, сәүдә галереясы һәм А классындагы бизнес-үзәкне берләштердек. Проект партнерыбыз «Унистрой» компаниясе белән берлектә тормышка ашырыла. Сүз ике гектар мәйдандагы чын микрошәһәрчек турында бара. Проектның концепциясен планлаштырганда, анда яшәячәк кеше турында уйладык: аңа тәрәзәдән нинди манзара ачылачак, балалар бакчасына, мәктәпкә, эшкә барырга күпме вакыт кирәк булачак? Кайда һәм ничек ял итә, дуслары белән очраша, спорт белән шөгыльләнә алачак? Ишегалдында үзен никадәр куркынычсыз һәм уңайлы хис итәчәк? Аның комьюнитида ихтыяҗы бармы? Машина кулланачакмы, ул электрокар булмасмы? Без кешенең үзе өчен, яңа тәэсирләр алу өчен, күпме вакытын янга калдыра алачагын уйлап эшләдек.

Проект составында бизнес-үзәкне планлаштырганда, Казанда сыйфатлы, бигрәк тә яхшы урыннарда офис мәйданчыкларына кытлык сизелүен аңлап эш йөрттек. А классындагы бизнес-үзәкләр өчен кирәкле барлык таләпләрне саклыйбыз. Проект концепциясендә каралган функцияләр җыелмасы һәм янәшәдәге объектлар резидентның кырыс таләпләрен, шул исәптән ял итүгә һәм сәләтләрен ачуга бәйле ихтыяҗларны да канәгатьләндерә алачак.

UNO проектында Urban Health алымы гамәлгә ашырыла. Бу исә физик, эмоциональ һәм рухи сәламәтлекнең бердәмлеген һәм балансын тәэмин итә. Янәшәдәге һәм комплекс территориясендәге спорт объектлары физик сәламәтлекне ныгыту мөмкинлеге бирә. Камил рухи үсеш өчен ишегалдында уңайлы ял итү һәм аралашу зоналары булдырылган, гаилә һәм дуслар белән очрашулар өчен – кафе һәм рестораннар, кибетләргә йөрү өчен сәүдә галереясы планлаштырылган. UNOда яшәүчеләр өчен рухи үсеш – гаҗәеп манзараларны күзәтеп ләззәтләнүдән, зәвыклы матурлыгы һәр детальдә – холл, подъезд, ишегалларында чагылыш тапкан проект эстетикасына һәм хуш исле бакчага карап сокланудан гыйбарәт.

Компаниянең тагын бер күпфункцияле проекты – Совет районында урнашкан ART комьюнити-үзәге. Аның составында фатирлар юк, әмма ул гамәлдәге торак мохитенә бик туры килеп тора. Әлеге проектның концепциясе UNO-ныкыннан аерыла, димәк, функцияләр җыелмасы да башка. Биредә район халкы өчен алдан уйлап эшләнгән ял, күңел ачу зоналары, фудмолл, офислар һәм коворкингтан гыйбарәт территория булачак. Көнкүреш товарлары һәм сәүдә галереясы булган тулы форматлы супермаркет өстәмә уңайлык тудырачак. Безнең бурыч – үз-үзеңне күрсәтү, аралашу, кызыклы шөгыльләр өчен мәйданчыклар булдыру, шулай ук көндәлек ихтыяҗларны да канәгатьләндерү.

ART комьюнити-үзәгенең үзенә генә хас атмосферасы һәм затлы лофт эстетикасы бар. Монда табигый материаллар, яшеллек, кояш яктылыгы һәм заманча технологияләр үзара ярашкан. Һәркемне үзенә тартып тора торган урын. ART комьюнити-үзәге – җылы әңгәмәләр, очрашулар, иҗат итү урыны. Без мондый проектларның мөһим социаль роль уйнавына ышанабыз.

Хәзер бизнес клиентка йөз тотарга тиеш. Кеше һәм аның өмет-теләкләре беренче планга чыга. Аның тормышы үзе өчен күбрәк вакыт калырлык итеп корылырга тиеш, моның өчен ул барырга теләгән янәшәдә булса әйбәт. Яңа буын инде мөмкин кадәр күбрәк тәэсирләр алуга һәм бертөрле, ялыктыргыч процессларны киметүгә йөз тота. Өйдән торып яисә янәшәдәге коворкингта эшләү, фатирда яки апартаментта яшәп, дусларың белән берәр урында очрашу. Яраткан шөгыльләрең һәм буш вакытыңны кызыклы уздыру өчен вариантлар булу. Фитнес-клубкамы яисә дусларың белән кафегамы – кая барырга икәнен сайлап тормау, чөнки барысына да өлгерергә мөмкин. Клиент ихтыяҗын үзәккә кую безне, шәһәр киңлекләрен үстереп кенә калмыйча, кала халкы, безнең һәрберебез өчен яңа мөмкинлекләр тудыра ала торган форматларны эзләргә этәрә.

UD Group
ud-group.com

Фотолар UD Group компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

ЖИЛИЩНЫЕ ТРАДИЦИИ

УНИСТРОИМ ГОРОДА
unistroyrf.ru
УНИСТРОЙ

30% БЕРЕНЧЕЛ КЕРТЕМ БЕЛӘН 7 ЕЛГА КАДӘР БҮЛЕП ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫНДА ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫ БУЕНЧА

- Ана капиталын кабул итәбез
- Trade-in
- Процентларсыз, поручительсез
- Паспорт һәм ИНН

ГАРАНТИЯЛӘР

- РФ ҮБ
- Росреестр
- ФСХ
- Төзүче
- Аудитор
- Ревизор

«Атмосфера» торак комплексында 1 бүлмәле фатир 28,57 кв. м

Бәясе: 3 920 000 сумнан башлана

Беренчел кертем: 1 176 000 сумнан башлана

Айлык түләү: 32 666 сумнан башлана

info@znkgt.ru www.znkgt.ru +7 843 216 45 00

420133, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гаврилов ур., 1

* Застройщик: ООО Специализированный застройщик « СК «УнистройДом-1»» (ИНН 1657246556, ОГРН 1181690046977).
** Предоставление рассрочки возможно при условии приобретения членства ЖНК «Жилищные Традиции», деятельность которого осуществляется в рамках Федерального закона от 30.12.2004 г. №215 «О ЖНК». Решение Банка России от 22.03.2018 г.: присвоить регистрационный номер 61 записи о ЖНК «Жилищные Традиции» и включить сведения о нем в реестр ЖНК. В целях обеспечения непредвиденных расходов и покрытия убытков кооператива формируется резервный фонд, размер которого определяется уставом ЖНК «Жилищные Традиции». Членом кооператива может быть гражданин, достигший 16-летнего возраста. Минимальный срок внесения членом кооператива части паевого взноса, после которого у кооператива возникает право на приобретение жилого помещения для члена кооператива составляет 2 года. Объемы, условия и порядок погашения рассрочки согласуются с членом кооператива. Более подробно о порядке участия в ЖНК «Жилищные Традиции» вы можете узнать на сайте znkgt.ru.
*** Настоящее предложение не является публичной офертой.

РЕКЛАМА

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ветеран Харис Салиховка әтисе **нинди** аманәт әйтә

Ульяновскида милләттәшләребез **ничек** яши

Гайнетдин Әхмәрев **нинди** мирас калдырган

Яңа Тинчәледә **ничә** күл бар

«ӘТИ СҮЗЕННӘН ЧЫКМАДЫМ...»

Руфия Фазылова

Харис Салихов хәрби хезмәткә унсигез яше тулганчы ук алына. Башта егетләрне элемтәче булырга укыталар, аннан сугышка җибәрәләр. Шундый авыр минутларда да Харис намазын калдырмый. Берсендә, татар егетләренең бергәләп сәҗдәгә киткәнен күргәч, командирлары килә: «Нишлисез сез?» – ди ул, аптырап. «Богу молимся», – ди яшь солдат. Шуннан Харис Салихов командирына бәйнә-бәйнә аңлата: «Сезнең исәнлек, үзебезнең исәнлек өчен дә «Бог»тан сорыйбыз...» Командир шактый гына карап торганнан соң: «Просите, просите», – дип китеп бара. Ул гомер буе Аллаһ исеме белән яши. Сугышка киткәндә әтисе аңа шундый әманәт әйтеп җибәрә. Әнә шул догалары Харис Салиховны берничә тапкыр үлемнән алып кала. Һәм 96 яшенә кадәр саклап йөртә...

– Харис хәзрәт, сез чагыштырмача «яшь» сугыш ветераны. Бөек Ватан сугышына 1944 елда киткәнсез. Белгәнебезчә, сугышның иң авыр еллары – 1941 елдан 1943 елга кадәр. Әллә инде сугышны авыр һәм җиңел елларга бүлеп карау дөрес түгелме?

– Сугышның иң авыр чоры 1941 елның ноябрь-декабреннән башланды. Шуннан ул Сталинград сугышына барып тоташты. Немецлар белән иң каты бәрелешләр 1943 елның февраленә кадәр дәвам итте. Аннан инде дошман чигенә башлады. Немецлар Мәскәүгә килеп җитәргә утыз чакрым ара калган иде. Ул вакытта бөтен ил сулаудан туктады, радиодан гел шул турыда сөйләделәр. Һәр гаиләнең дә газиз кешеләре сугышта, алар исән калырмы, юкмы... Ятсаң да, торсаң да уйда шул гына иде.

Әлбәттә, сугышта берәүгә дә җиңел булмады. Бөек Ватан сугышы 1945 елның 9 маенда тәмамланса да, безнең өчен тәгәлләнмәде ул. Безгә Көнбатыш Украинанага барып, бандерачыларны, качкан немецларны эзләргә дигән боерык бирелде. НКВДга караган бүлектә хезмәт иттек, элемтәчеләр идек. Сугышның иң авыр чоры минем өчен шул булгандыр.

– 18 тулганчы ук сезне хәрби хезмәткә алганнар. Әллә үзегез теләп гариза яздыгызмы?

– Ул чагында безнең кебек укуы булган егетләрне хәрби хезмәткә чүплиләр иде. Арча педучилищесының икенче курсында укыганда военкоматка чакырдылар. «Егет, синә вакыт», – диделәр. Тугыз сыйныф белеме булган егерме егетне элемтәчегә укытырга дигән боерык булган. Мәктәпнең җиде классы, педучилищеның ике курсы, барысы тугыз класс булып санала иде. Әнә шулай, салам матрасны бушатып, әйберләрне тулай торакның комендантына калдырып, өйгә кайтып киттем.

Сугыштагы хәлләрне сөйли китсәң, көн генә җитмәс. Менә бер генә очракны мисалга китерәм: 1945 ел, Австрия, Дунай елгасы. Күпер аша элемтә чыбыгы суздык. Эшне бетергәч, янә чыбыкны ялгарга дигән приказ булды – төнлә немецлар күперне шартлаткан, элемтә өзелгән. Сафка тезелеп, командирның кемне сайлаганын көтәбез. Беребез дә куркак түгел, ләкин барыбызның да яшисе килә – кырык метрлап өскә менәргә кирәк, фашистларның атып үтерәселәре көн кебек ачык. Командир көр тавыш белән: «Үз теләге белән алынучылар бармы?» – дип сорады. Шунда Саратов өлкәсендә элемтәчегә бергә укыган

Фото: Александр Ефремов

дустым Сәгъдулла сафтан чыкмасынмы! Һәм ике дә уйламыйча:

– Үземә ярдәмгә Харисны чакырам, – диде.

– Ә ник аны? – ди командир.

– Ул Аллага ышана. Мин күпергә менәм, ул астарак чыбык төргәген сүтеп торыр. Һәм Алладан минем исән калуымны сорар.

Командир елмаеп куйды һәм безгә приказны үтәргә боерды.

Сәгъдулла пуля яңгыры астында чыбыкны ялгады. Аның ничек елан кебек бормаланып хәрәкәт итүен күрсәң, исең китәр. Барыбыз да җиңел сулап куйдык. Әнә шул вакыт Аллаһы Тәгалә безне ярдәменнән ташламады.

– Харис хәзрәт, сез 2017 елда ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен алгансыз. Нинди хезмәтләрегез өчен мондый мәртәбәле бүләккә лаек дип табылдыгыз?

– Унбиш ел дәвамында китап яздым, «Дин вә фән» дип исемләп, аны бастырдым. Ул чорда бик күп галимнәр белән эшләдем. Улым – танылган физик, Америкада яши. Аның ярдәме белән Америкага барып, анда да тикшеренергә насыйп булды. Ул китапта баланы, ата-ананы дини һәм дөньяви мәдәниятләр нигезендә тәрбия кылу ысуллары тәкъдим ителә. Эшемне тарихчы Рафаэль Хәкимов, Энгель һәм Индус Таһировлар, Әнвәр Хуҗиәхмәтов, Айдар Хәлимнәр бәяләде. Тукай премиясен бирүне дин белән фән бергәлеген тану, дип кабул иттем.

Әйе, китап язарга алынганда Тукай премиясенә тәкъдим итәрмен дип башыма да китермәгән идем. Барлык максат – Габдулла Тукай, Александр Пушкин иҗатында Коръәннең, дини мотивларның чагылышын ачыклау иде.

Совет власте юк ителгәч, илдә идеология калмады. Үзләренә кыйбла таба алмаган кешеләр саны көннән-көн артты. Бу шартларда кешеләрнең әхлакый дәрәҗәсен дин вә фән белән генә күтәреп була иде. Әгәр тарихка күз салсак, мәҗүсилек чорында ук халыкны бер Алла тирәсенә җыярга тырышканнар. Безнең эрага кадәр яшәгән галим Аристотель, галәм сукыр бер очрак, могҗиза көче яисә күп алла тарафыннан идарә ителми, ә югары көчнең рациональ законнарына буйсына, дип әйтеп калдырган. Гасырлар үтү белән, гарәп дөньясы зур алгарыш кичерде. Җәдитчеләр динне фән белән дә аңлата башлады. Әл-Хәрәзми, Әбүгалисиналар дин белән фәннең бергәлегенә хезмәт итте. Бу бергәлек минем аңыма әтием тарафыннан сеңдерелде. Мәктәптән кайткач, әтинең беренче соравы: «Нинди дәрес үттегез?» Пушкин дисәң, аның Коръән турындагы шигырен укып күрсәтә. Тукай дисәң, халык шагыйребезнең иҗатында дини теманың нчек яктыртылуы турында сөйли. Минем беренче фәнни эшем дә Габдулла Тукай, Александр Пушкин иҗатларын өйрәнүгә багышланды. Ул вакытта шагыйрь атеист дип сурәтләнә, дини шигырьләре дөнья күрмәгән иде. Тукайның «Күктәге пар йолдыз кебек дин белән фән тора» дигән шигъри юллары хезмәтемнең төп принцибы булды. Татар фикере белән аңлатканда, дин ул – вөҗдан, фән ул – аң. Аларның икесе дә тигез булганда гына тәрәккыяткә ирешеп була. Тукай шушы тәрәккыят өчен көрәшкән.

– Сугыштан исән кайткан әтиегезне гел зур хөрмәт белән искә аласыз. Әтиегез шулай тирән белемле кеше идеме?

– Әтием Гыйбадулла улы Салихҗан Балтач районы Чутай авылының гыйлемле, алдынгы карашлы кешесе санала иде. Шуның өчен күп кыйналды, күп җәберләнде.

1941 елның сентябрендә әтигә сугышка китәргә чакыру килде. Алар авылда берничә кеше булып чыкты. Ул көнне һич онытмыйм: олы юл кырыена сугышка китәсе кешеләр җыелды. Озатучылар бик күп иде. Әнкәй коймак пешереп алып килде. Мулла абзый белән шунда бергәләп намаз укыдык. Аллаһтан хәерле сәфәрләр сорап, сугышка китүчеләрне озатып калдык. Алар башта Суслонгерда булды. 1941 елның азагында аларны Мәскәү янына җибәрделәр.

Әти 1942 елны сугыштан яраланып кайтты. Сул кулы скелет шикелле асылынып тора иде, исләнеп беткән... Мазь-фәлән түгел, яраны юарга сабын да юк. Әни, селте сулары ясап, әтинең кулын төзәтте. Әти миңа: «Безнекеләр барыбер җиңә, менә күрерсең. «Катюша» дигән машина уйлап тапканнар. Үз күзләрем белән күрдем: снарядларны секунд эчендә җибәрә», – дип сөйләде. Аннары колхозга эшкә чыкты. Әтинең миңа рухи йогынтысы турында сөйләп бетерә торган түгел. «Шул атаңны Сталиннан да зур күрәсең инде», – дип әйтә иде нәнә (әни). Сугыштан кайткач, әти бер фикер әйтте: «Татар үз илендә берсе икенчесенә көнче, ә менә татар иленнән аерылса, аз булсалар, ул очракта берсе икенчесенә ту-



Харис Салихов – батырлыгы өчен II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, утыздан артык медаль, җинаятьчелеккә каршы көрәштә казанышлары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән шәхес. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе. Бүгенге көндә «Хәтер» мәчетенең имам-хатыйбы.

ган», – диде. Чөнки сугышта бөтен татарлар дустату булып, ярдәмләшеп торган.

Әти белән бәйле тагын бер вакыйганы сөйлисем килә. 1944 елның декабрь башы, авылдашым Сәйфетдин белән сугышка китәбез. Әти безне ат белән озата барды. Зиратка җиткәч, атын туктатты да: «Улым, дөнья хәлен белеп булмый. Менә монда әбиең, башка бик күп туганнарың, авылдашларың ята. Аларның исемнәренә тап төшерәсе түгел. Командирыңны тыңла. Тәртипле булсаң, бәлки исән кайтырсың», – диде. «Әти, борчылма, синең сүзеңнән чыкмам. Син минем өчен әүлия», – дидем мин. «Бездә әүлияләр юк, бөтен кеше дә гөнаһлы. Мин сиңа һәр көн дога кылып торырмын, син дә намазыңны калдырма», – дип җавап кайтарды ул. Әтигә биргән вәгъдәне үтәдем...

– 1970 нче елларда Казан шәһәренең Совет районы эчке эшләр бүлегендә җитәкче урынбасары булгансыз. Илдә вазгыять ничегрәк, җинаятьчелек көчле идеме?

– Милициядә утыз ике ел хезмәт куйдым. Мин эшләгән чор – 1960–1980 нче еллар, Совет властенең чагыштырмача бик тә тыныч еллары иде. Бер генә мисал: Татарстан буенча 1990 нчы елларда елына алты йөзләп үтерү очрагы булды. Ә 1970 нче елларда бу сан йөз, иң күбе ике йөздән артмады. Менә шушы саннар илдә булган вазгыять турында сөйлидер. Без эшләгән чорда профилактика, ягъни җинаятьчелекне булдырмауга зур игътибар бирелә иде.

– Нинди профилактика ул?

– Һәр участковый үзенең территориясендәге җинаять кылырга сәләтле кешене белергә тиеш иде. Алар белән даими элемтәдә булып, контрольдә тотты.

Кул астымда 400 кеше эшләде. Мактану булмасын: минем вазыйфа бик «блатной», бөтен рөхсәт документларына кул куйдым. Теләсәм, үзем өчен әллә нинди файдалар эшләргә мөмкин иде, ләкин мин бер тиен дә алмадым. Әлеге дә баягы, әти биргән тәрбия, дини кыйблам – барысы да гаделбулырга өйрәтте.

– Димәк, сез дин ирегe кайтуны зур сөенеч белән кабул иттегез? Эчке эшләр органнарыннан киткәч, Татарстан мөфтие урынбасары булдыгыз. Һәм әле берничә тапкыр ТР мөфтилегенә кандидат та идегез. Бу югары постка биләргә нәрсә комачаулады?

– Дин ирегe булмаса да, гомер буе иман белән яшәдем, Аллаһка шөкер. Ә менә 1990 нчы елларда, авыл саен мәчет төзелә башлагач, ихластан сөендем.

Махсус дини белемем булмау сәбәпле, шул юнәлештә укырга кирәргә карар кылдым. Һәм 1993 елда Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсен тәмамладым. Һәм шуннан соң мине ТР мөселманнарының Диния нәзарәтенә рәис урынбасары итеп куйдылар.

ТР мөфтиенә кандидатлыкка килгәндә, бу вазыйфада эшләргә миңа насыйп булмаган, күрәсең. Соңгысында хәзерге мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җиңеп чыкты. Гаҗәп түгел, яшем дә бар иде. Юк, үпкә дә, үкенеч тә юк. Үземне бик бәхетле дип саныйм. Төрле җирләрдә эшләргә туры килде. Бүгенгә кадәр сау-сәламәт яшим. Дөньяның агын да, карасын да күрдем, Аллаһыма мең шөкер.

– Харис хәзрәт, бездә дин белән дәүләт аерым. Әмма дәүләт күпмедер дәрәҗәдә дини эшләрне контрольдә тотарга тырыша. Бу начармы, яхшымы? Ничек уйлыйсыз?

– Начар түгел дип саныйм. 1990 нчы еллар башында мине мәчеттә үтергәнче кыйнап киттеләр. Ул чорларны күпләр хәтерлидер, дин тирәсендә зур чуалышлар килеп чыкты. Ә бүген республикада дини вазгыять тыныч, димәк, дәүләт игътибарында булуы яхшы.

– Тиздән сезгә 96 яшь тула. Яшь барганын сизәсезме? Сәламәтлек ничек?

– Биш үлемнән калдым мин. Биш тапкыр һөҗүм иттеләр, икесе сугышта, аннары милициядә эшләгәндә, мәчеттә... Барысында да аякка бастым. Ә сәламәтлеккә килгәндә, үземне яхшы хис итәм. Билгеләнгән табибларым бар, алар әйткәнне төгәл үтим. Майлы, баллы ризыклар бөтенләй ашамыйм. Гомер буе тәмәке тартмадым, аракы эчмәдем. Аллаһ кушканча яшәдем. Әнә шулар барысы да әле дә сафта булырга ярдәм итәдер.

«Татмедиа» делегациясе Ульяновск шәһәрендә ике көнлек сәфәрдә.

КАЗАННАН СЕМБЕРГӘ СӘЯХӘТ

Фәридә Әхмәтҗанова

Элеккеге Сембер, бүгенге Ульяновск шәһәрен без дөнья пролетариаты юлбашчысы Владимир Ульянов-Ленинның ватаны буларак беләбез. Совет чорында ул авиация-сәнәгать комплексы, «УАЗ» машиналары, туристларның күпләп килүе белән дә дан тота иде. Бүген күршеләребез ни хәлләрдә? Андагы милләттәшләребез ничек яши? Шушы кызыксынуыбыз безне, «Татмедиа»ның бер төркем мөхәррир һәм журналистларын, Ульяновск каласына ике көнлек сәфәргә этәрде.

Фото: автор, tatar-inform.ru

Татар мәдәни үзәгенең икенче катында музей оештырылган. Шунысы кызык: кечкенә генә музейда оригинал экспонатлар шактый.

ТАТАР МӘДӘНИ ҮЗӘГЕ

Ульяновск шәһәре Татар мәдәни үзәгендә милләттәшләребезнең бөтен мәдәни һәм иҗтимагый тормышы чагылыш тапкан. Үзәк урнашкан бинада элек «Мир» кинотеатры булган. 1956 елда салынган бина каршында «Болгар яңарышы» оешмасы инициативасы белән урта гасырлар шагыйре Кол Галигә һәйкәл куелган. «Бу һәйкәл – үткән белән бүгенгене тоташтыра торган күпер», – дип аңлатты Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни мөхтәрияте җитәкчесе Рәмис Сафин.

Кинотеатрда 1990 нчы елларда кино күрсәтү туктатыла. Ишек-тәрәзәсез калган бу ташландык бинаны 2003 елда өлкә татарлары үзләренә сорап ала. Татарстан хөкүмәте, җирле эшмәкәрләр ярдәме белән бинаны чистартып, төзәтеп, татарлар җыела торган үзәккә әйләндерәләр.

– Үзәктә 22 хезмәткәр эшли, аларга өлкә бюджетыннан хезмәт хакы түләнә. Бу яктан без бик бәхетле, башка төбәкләр моның белән мактана алмый, – диде Рәмис Фарук улы.

Кинотеатр бинасы булганга, бүлмәләр бик аз. Аның каравы, менә дигән тамаша залы бар, анда Татар мәдәни үзәге каршында оештырылган җыр һәм бию ансамбльләре шөгыльләнә. Якын көннәрдә аның сәхнәсе заманга туры китереп яңартылачак икән, төзелеш материаллары инде кайтартылган.

Үзәк каршында дистәгә якын түләүсез түгәрәк эшли. Анда татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә шөгыльләнә. Бинаның икенче катында өлкәдәге татарлар тормышына, күренекле шәхесләргә багышланган музей экспозициясе оештырылган. Шунысы кызык: кечкенә генә музейда оригинал, төп нөсхә булган экспонатлар шактый. Якташлары – СССРның халык артисты Габдулла Шамуков, шагыйрь Сәхаб Урайский, язучы, тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллин, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Закир Кадыйри, сәнәгатьче Акчуриннарга кагылышлы шәхси әйберләр, халыктан җыелган фронт хатлары һәм газеталары бар. Татар районы саналган Иске Кулаткының «Күмәк көч» дип аталган газетасы тупланмасы игътибарны җәлеп итә. 1930 елдан бирле басылып килгән бу басма бер мәртәбә дә исемен үзгәртмәгән. Хәер, бу аның төп эчтәлегенә дә кагыла. Газета һаман да татар халкының фидакарь хезмәтен, аның уй-фикерләрен чагылдыра...

МӘКТӘП

Сәфәребезне Ульяновск шәһәренең 28 нче мәктәбендә дәвам иттек. Милләт җанлы директор, РФнең атказанган укытучысы Әсхәт Фәизов җитәкләгән бу мәктәп калада татар теле дәресләре алып барыла торган өч уку йортының берсе. Килеп керүгә, биредәге тәртипкә, җылы мохиткә игътибар иттек. Казаннан кунаклар киләсен белгәннәр: татарчалатып исәнләшүче балалар да булды. Мәктәпне тәмамлаган алдынгы укучылар арасында татар фамилияләрен күреп тә сөендек. Татар теле дәресләре, мәктәп расписаниесенә кертеп, 7 нче сыйныфка кадәр дәрес буларак укытыла. Ни кызганыч, татар телен укучылар саны кими төшкән. Укытучылардан да бер генә мөгаллим калган, гәрчә моннан берничә ел элек алар өчәү булса да. Төп сәбәп – ата-аналарның милли үзаңы түбән булу, дип аңлатты бу хәлне мәктәп җитәкчесе. Чуваш телен дә укытырга тырышып караганнар. Шул ук хәл. Югыйсә, укытучылар да, дәреслекләр дә, хакимият ягыннан аңлау да бар... 6 нчы сыйныфта узган татар теле дәресендә укучылар безгә туган телдә җырлап та, сөйләп тә күрсәттеләр.

«БИЛӘР» МӘДРӘСӘСЕ

«Биләр» мәдрәсәсе Ульяновск шәһәре мөселманнарына белем бирү үзәге булып тора.

– Биләр борынгы бабаларыбыз яшәгән бөек шәһәр булган. Шуңа күрә без бу атаманы да мәңгеләштерергә уйладык, – диде Ульяновск өлкәсе

– Ата-бабаларыбыз борынгыдан ислам динен тоткан. Менә бу басма һәм кульязма китаплар да нәкъ шул турында сөйли, – диде безгә мөфти Илдар Сафиуллин, китап киштәләрен күрсәтеп.

мөфтие Илдар Сафиуллин, мәдрәсәнең исеме турында сүз чыккач.

Мәдрәсәдә булачак имам-хатыйбларны, ислам фәннәре һәм гарәп теле укытучыларын әзерлиләр. Бүген монда «Чишмә» балалар бакчасы эшли: 3–7 яшьлек нәниләр өчен барлык шартлар да тудырылган. 6-10 яшьлек балалардан Коръәнне өйрәнү төркеме тупланган. (Без кергәндә дә алар дәрестә иде.) Мәдрәсә зур планнар белән яши: өч катлы яңа бина салынган, аның өченче катында кызлар өчен дә мәдрәсә ачарга ниятлиләр.

Мәдрәсәнең китапханәсе бик бай, фондларда тупланган дини китаплар арасында чит илләрдән бүләк буларак килгәннәре дә шактый.

– Кайберәүләрнең фикеренә каршы шуны әйтәсе килә: дин безгә бүген генә килмәгән, ата-бабаларыбыз борынгыдан ислам динен тоткан. Менә бу революциягә кадәрге чорга караган басма һәм кулъязма китаплар да нәкъ шул турында сөйли, – диде мөфти безгә, китап киштәләрен күрсәтеп.

Әлеге иске китап һәм кулъязмаларны татар авылларыннан җыйганнар, кайсыларын кешеләр үзләре дә китереп биргән. Китаплар юкка чыкмасын өчен, мәдрәсә җитәкчелеге аларны цифрлаштырырга, шул рәвешле бу мирасны киләчәк буыннарга тапшырырга уйлый.

«ӨМЕТ» ГАЗЕТАСЫ

Ульяновск каласына килеп, каләмдәшләребезгә кунакка кермичә китү дөрес булмас иде. Редакция, кечкенә бүлмәләрдә урнашса да, зур эш башкара. «Өмет» өлкә татарлары газетасы 1989 елдан бирле чыгып килә. Ул өлкә хөкүмәтенең финанс ярдәме белән бастырыла.

– Газетаны Казанга интернет челтәре аша җибәреп, шундагы типографиядә бастырабыз, әзер продукцияне машинада алып кайтабыз, – дип сөйләде безгә «Өмет» газетасының баш мөхәррире Исхак Хәлимов.

Бүген газетаны 4500 ләп татар гаиләсе укый. Редакциянең рәсми сайты, социаль челтәрләрдә үз аккаунты бар. Каләмдәшләребез белән аралашканда уртак проблемалар – газетага язылу, аны тарату, укучылар санын арттыру, чыгымнарны киметү юллары турында сөйләштек, тәҗрибә уртаклаштык.

2 НЧЕ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

Ульяновскида мөселман җәмгыяте актив үсештә. Без моның шулай булуына 2 нче Җәмигъ мәчетенә баргач та инандык. Өлкә мөфтиенең яшьләр сәясәте буенча урынбасары Рәсүл Фәткуллов тагын бер кат шуңа басым ясады. Мәчеткә ремонт үткәрелгән, янәшәдә генә тагын бер бинаны сатып алганнар. Анысында ислам балалар бакчасы ачарга ниятлиләр. Ишегалдында балалар өчен уен мәйданчыгы каралган. Менә монда йокы, уен бүлмәләре, дип күрсәтеп йөрде безгә мәчет имамы. Агач тәрәзә рамнарын пластикка алыштыру өчен акчаны 15 минут эчендә җыйдык, диде ул. Гомумән, Ульяновск өлкәсе мөфтие Илдар Сафиуллин да, 2 нче Җәмигъ мәчете имамы Рәсүл Фәткуллов та һәр эшне мөселманнар, татар эшмәкәрләре белән бергә, аларның матди һәм финанс ярдәменә таянып башкаруларына басым ясады. Бик күркәм күренеш.

Коръәннең иңе (ачылган килеш) – 130 см, буе – 95 см. Изге китапны Ливиянең элекке лидеры Муаммар Каддафи үзенең Россиягә соңгы сәфәре вакытында Мәскәү мөселманнарына бүләк иткән. Хәзер исә ул Ульяновск өлкәсе мөфтиятенә тапшырылган.

Мәчет территориясендә шулай ук заманча чишмә казыячаклар икән. Бораулау эшләре шушы көннәрдә башланачак. Суны бушлай, бөтен шәһәр халкы ала алачак.

Мәчет залында рамазан аенда көн саен ифтар мәҗлесләре үткәрелгән. 150–180 кешелек табын корылган. (Бер ифтар якынча 30 мең сумга баскан). Ифтар үткәрергә теләүчеләр бик күп булган.

Җәмигъ мәчетендә кызыклы вакыйганың шаһиты булдык: нәкъ шул көнне дин йортына Мәскәүдән үзенчәлекле Коръән кайтты. Рәсүл хәзрәт зурлыгын үлчәп тә күрсәтте: иңе (ачылган килеш) – 130 см, буе – 95 см. Коръәннең тарихы да кызыклы. Изге китапны Ливиянең элекке лидеры Муаммар Каддафи үзенең Россиягә соңгы сәфәре вакытында Мәскәү мөселманнарына бүләк иткән. Хәзер исә ул Ульяновск өлкәсе мөфтиятенә тапшырылган.

ЭКСКУРСИЯ

Ульяновск каласы Акчуриннар, Алиевлар, Бәхтиевләр, Закир Кадыйри кебек күренекле татар шәхесләренең эзләрен саклый.

– Сәнәгатьче Акчуриннар, мәсәлән, Сембер губернасында беренчеләрдән булып, үз предприятиеләренә ялланып эшләүне кертә. Заманы өчен бу бик прогрессив адым санала. Эш шунда ки, татарларга крепостнойлар тоту тыелган була. Кыска гына вакыт эчендә крепостной хезмәткә караганда ялланып эшләүнең нәтиҗәлерәк булуы ачыклана. Шул рәвешле Акчуриннар үзләренең постау, корыч кою һәм агач эшкәртү җитештерүләрендә индустриальләштерүне башлап җибәрә. Шунысы да кызыклы: 1880 нче елларда губернадагы өч 1 нче гильдия сәүдәгәренең өчесе дә татар булган, – дип сөйләде

– Шунысы да кызыклы: 1880 нче елларда губернадагы өч 1 нче гильдия сәүдәгәренең өчесе дә татар булган, – дип сөйләде безгә туган якны өйрәнү белгече Римма Вильданова.

безгә туган якны өйрәнү белгече Римма Вильданова.

Атаклы якташларының тормыш юлы җентекләп өйрәнелгән. Бу зур эшнең нәтиҗәсе буларак «Татары Симбирско-Ульяновского края» дип аталган энциклопедик эчтәлекле басма да дөнья күргән. Татар сәүдәгәрләренең йортлары сакланып калган Федерация урамына урнашкан агач йортларның матурлыгына, төсләренең җетелегенә, тәрәзә йөзлекләре, фасадларындагы бизәкләргә хәйран калдык. Йортларның күбесе төбәк әһәмиятендәге саклауга куелган. Шулай да араларында бүген үк төзекләндерүгә мохтаҗ йортлар бар.

Сәнәгатьче Акчуриннар йорты.



УНИВЕРСИТЕТ

Ульяновск дәүләт университеты җитәкчелеге белән очрашу бик җылы атмосферада үтте. Бинага килеп керүгә, гөлбакчага эләгәсең. Түгәрәк өстәл вакытында ректор Борис Костишко уку йортының үсеш юнәлешләре, өлкәдә нинди һөнәрләргә ихтыяҗ булуы турында сөйләде, уку йортының ачылу тарихы белән таныштырды.

Университет 1988 елда Мәскәү дәүләт университеты филиалы буларак ачыла. Бу башкаладан читтә ачылган беренче филиал була. Хәзер университет мөстәкыйль уку йорты, анда 14 мең студент укый. Алар арасында чит илләрдән килеп укучылар да шактый, бигрәк тә медицина юнәлеше буенча. Мәктәпне тәмамлаучылар читкә китәргә («вализм» диде, шаяртып, бу турыда ректор) яратса да, студентларның саны арта бара. Яшьләрдә белем алуга, һөнәр үзләштерүгә кызыксыну уяту өчен 40 тан артык иҗат мәйданчыгы булдырылган. «Яшьләр хәзер соң өлгерә, уку йортын тәмамлаганда үзенең кем булырга теләвен төгәл аңласа да әйбәт», – ди ректор, уенын-чынын бергә кушып. Шуңа күрә бүген студентларга төрледән-төрле компетенцияләр бирү актуаль. Университет үсештә, хәзерге вакытта медицина факультеты өчен бина төзелә.

КИТАПХАНӘ

Күренекле тарихчы-якташлары Карамзин исемендәге җәмәгать китапханәсе Сембер шәһәренең горурлыгы була. Ул 1848 елда оештырыла. Китапханә фондының нигезен шагыйрь Николай Языковның 2325 томнан торган шәхси китаплары тәшкил итә. Теләге булган һәр кеше, китапханәгә кереп, бушлай китап укый алган. Өйләренә укырга алып киткән өчен генә 5 сум акча калдырганнар, гәрчә ул вакытта бу шактый акча саналса да. Ләкин 1864 елда көчле янгын чыга. Өч атна котырган янгында шәһәрнең өчтән ике өлеше янып бетә, шул исәптән Дворяннар җыелышы бинасының берничә бүлмәсен алып торган китапханәгә дә бик зур зыян килә. Китаплар фондының биштән бер өлеше – кеше кулында булганнары гына сакланып кала. Әмма заманның зыялы шә-

Русских белән очрашу булды. Очрашуда «Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев катнашты.

Губернатор үзенең Татарстан турында мәгълүматлы булуы белән шаккатырды.

– Мин дә бит очрашуга әзерләндем, – диде ул елмаеп. – Төбәктә 100 дән артык милләт яши, соңгы җанисәп буенча татарларның саны 112 меңгә якын. Әмма алар күбрәктер дип уйлыйм.

Сүз уңаеннан, халык санын алу нәтиҗәләре өлкәдә татарларның 38 меңгә кимүен күрсәткән. Җитәкче татар халкының мәдәниятенә, традицияләренә хөрмәт белән каравына да басым ясады.

– Губернатор булып эшли башлап, берничә ай үтүгә, Алексей Юрьевич милли мөхтәриятләр җитәкчеләре белән очрашты. Һәм гомумән, без һәрвакыт хакимият ягыннан кайгыртучанлыкны тоеп яшибез, – дип өстәде очрашуда катнашучы Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни мөхтәрияте җитәкчесе Рәмис Сафин.

Очрашуда Татарстан Республикасы белән Ульяновск өлкәсе арасындагы икътисадый, сәүдә, мәдәни элемтәләр турында сүз чыкты. Алексей Русских Казан–Буа–Ульяновск–Димитровград – Тольятти–Самара маршруты буенча югары тизлекле поезд җибәрү проекты турында сөйләде. Җир өстендә генә түгел, су юлын яңарту турында да фикер булды. Бөек елга ярында яшәп, су транспорты булмау дөрес түгел, диде ул. Киләчәктә «Метеор»лар сатып алып, елга транспортын эшләтеп җибәрү планнары белән уртаклашты. Эшкуарлык өлкәсендә берничә тәкъдим яңгырады. Шул исәптән губернатор Татарстан бизнесын махсус порт икътисадый зонасына керергә чакырды.

Мемориаль музейның утырышлар залы. Пыяла ишекле шкафларда Карамзин, Гончаров, Аксаковлар, Языковлар нәселе, булачак император Александр III укыган китаплар урын алган.

хесләре ярдәме белән китапханә фонды яңадан туплана.

– Китапханәче Иван Благодаров фондларны торгызуга, аларны тәртипкә китерүгә зур көч куя, гаиләсе ишле булуга да карамастан, хезмәт хакының бер өлешен китапханәгә биреп бара. Сүз уңаеннан, ул вакытта китапханәдә күбрәк ир-атлар эшләгән. Китапханәче берничә чит телне белергә тиеш булган, – дип сөйләде безгә Мемориаль китапханәнең сирәк басмалар бүлеге мөдире Людмила Ивашкина.

Бүген исә бу – Ленин исемендәге фәнни китапханә составындагы Мемориаль музей. Ул өч өлештән тора: швейцар бүлмәсе, уку залы һәм утырышлар залы. Бүлмәләрдәге иске шкаф, өстәл, урындыклар, диварлардагы портретлар – барысы да чын. Алар, борынгылык рухын үзләренә сеңдереп, китапханәдә аерым бер атмосфера тудыра. Иске китаплар шул замандагыча итеп – темалап урнаштырылган. Пыяла ишекле шкафларда Карамзин, Гончаров, Аксаковлар, Языковлар нәселе, булачак император Александр III укыган китаплар урын алган. Карамзинның «История государства Российского» хезмәтен язганда кулланган китаплары да биредә саклана. Бу – китапханәнең аерым бер горурлыгы.

Безне атаклы сәнәгатьче Акчуриннар китаплары кызыксындырды. Революциядән соң башка мөлкәтләре белән бергә аларның китаплары да дәүләт хисабына тартып алына. Әлбәттә, бу Акчуриннарның гаять бай китапханәсенең бер өлеше генә була, чөнки француз, немец телендәге китаплар арасында без татарча, гарәпчә язылган китапларны күрмәдек. Бүген биредә аларның 200 ләп китабы саклана. Людмила Ивашкина сүзләренә караганда, Акчуриннар китапларының тышлыгына яисә беренче битенә мөһер сугылган була. Китапларның темасына караганда, аларны тарих, ислам, дин тарихы турындагы китаплар кызыксындырган.

ГУБЕРНАТОР ХОЗУРЫНДА

Ульяновск каласы белән танышу сәфәренең соңгы тукталышы өлкә губернаторы Алексей

Ульяновск өлкәсе губернаторы Алексей Русских белән очрашу.

...Сәфәр барышында өлкәнең татар эшкуарлары белән дә таныштык. Татарстаннан китеп, күрше өлкәдә җиһазлар ясап, сыйфатлы киемнәр тегеп, төбәктә генә түгел, ил күләмендә зур уңышларга ирешкән, дус-тату булып яшәүче милләттәшләребез өчен сөенеп, аларга сокланып кайттык.

ТИРӘН ТАМЫРЛАРНЫ БАРЛАУЧЫ

Илдус Заһидуллин

«Гайнетдин әфәнде анадан мөәррих (тарихчы) булган иде... Волга вә Урал буйларында торучы мөселманнардан бу көнгә кадәр өч мөәррих килеп китте. Болардан берсе – мелла Хөсәен Фәезханов, икенчесе – фазыйль Мәрҗани, өченчесе ошбу Гайнетдин әфәндедер». Ризаэтдин Фәхретдин 47 яшендә вафат булган Гайнетдин Әхмәревкә карата мондый югары бәяне Россия гуманитар фәнендә урта гасыр төрки-татар мәмләкәтләре турында яңа сүз булып яңгыраган «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» китапларын күздә тотып әйтә.

УЧИТЕЛЬ ӘХМӘРЕВ ҺӘМ АНЫҢ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ

Гайнетдин 1864 елны Казан губернасы элекке Зөя өязе Наратлы авылында крестьян Әхмәр Нәҗметдин улы гаиләсендә дөньяга килә. Зиһенле малайны 8 яшендә Тәтеш өязе Болын-Балыкчы авылындагы (хәзерге Апас районы) Бикчәнтәй хәзрәт мәдрәсәсенә укырга китерәләр. 17 яшендә Казанга килгәч, Татар укытучылар мәктәбе мөгаллиме Шакирҗан Таһиров киңәшен тотып, рус теле укытучысы булырга карар кыла.

Гайнетдин Татар укытучылар мәктәбендә дәүләт хисабына укый, шуңа күрә укуын тәмамлагач, 6 ел мәктәптә эшләргә тиеш була. Хезмәт юлын Алабуга өязендәге Биектау авылында рус-татар мәктәбендә укытучы булып башлый. Бу елларда мөселманнар арасында рус телен өйрәнү балаларны диннән, гореф-гадәтләрдән аерып, чукындыруга әзерләү буларак кабул ителә. Әлбәттә, авыл руханилары каршылыгын җиңеп, укытуны оештыру яшь педагогка җиңел бирелми. Әмма тәртипле һәм тырыш учительнең мәдрәсә белеме һәм мөселманча тормыш рәвеше Биектау халкында хөрмәт уята. Укытудан тыш, Гайнетдин Әхмәрев рус-татар мәктәпләре өчен әсбаплар да әзерли. Аның «Татарлар өчен беренче урыс әлифбасы» (1890) һәм «Татарлар өчен беренче кыйраәт китабы» (1890) исемле дәреслекләре нәшер ителә. Бу басмалар өчен автор 1890 елгы Казан фән-сәнгать күргәзмәсенең Мактау кәгазьләренә лаек була.

Гайнетдин 1891 елны гаиләсе – хатыны Бибисара Сакаева һәм 3 яшьлек улы белән Тәтешкә күченә. Шәһәрдәге рус-татар мәктәбендә укыта башлый. Биш дистә укучының күпчелеге тирә-як авыллардан килгән малайлар була, чөнки шәһәр мәхәлләсе мулласы Хәсәнгата Бикташев рус-татар мәктәбенә, аның укытучысына каршы көчле пропаганда алып бара. Әмма Гайнетдин Әхмәрев 1899 елда рус-татар кызлар мәктәбен ачуга да ирешә. Шул ук елны татарлар арасында рус телен таратудагы уңышлары өчен педагог Кече көмеш медаль белән бүләкләнә. Ә 1900 елны Әхмәрев җитәкләгән Тәтеш рус-татар мәктәбе, Париж Бөтендөнья күргәзмәсендә катнашып, Мактау дипломына лаек була.

1903 елда Әхмәревләр гаиләсе Казанга күченә. Педагог татар балалары өчен ачылган рус башлангыч мәктәбенә эшкә урнаша. 1905 елны Иске татар бистәсендәге мәдрәсә каршында эшләүче рус классына эшкә килеп, вафатына кадәр рус теле һәм математика дәресләрен укыта.

Әхмәрев татар балаларына башлангыч җәдиди белем бирүне кайгырта. 1909 елда, татар мәктәпләрендә кулланууда булган 15 әлифбаны тикшереп, мәкалә яза. Аларның сыйфаты

Фотолар автордан алынды

белән канәгать булмыйча, 1910–1911 елларда ике кисәктән торган «Төрки әлифба» әзерләп бастыра. 1911 елда учительнең уку өчен хикәяләр һәм шигырьләр тупланган «Кыйраәте төрки», «Гарәби әлифба», «Хөсне хат нәмунәсе» исемле әсбаплары нәшер ителә. Әйтергә кирәк, алар барысы да берничә кат бастырыла һәм 1915 елда Уфада узган мөгаллимнәр киңәшмәсендә мактала. Профессор Николай Катанов хәтта, «Төрки әлифба»ны русчага тәрҗемә кылып, Казан рухани академиясенең миссионерлык бүлегендә укучылар өчен махсус нәшер итә. Кызганыч, педагогның авыруы һәм иртә вафаты сәбәпле, «Кыйраәте төрки» (икенче кисәге), «Җәгърафия», «Хисап», «Тарих» исемле уку әсбаплары кульязма хәлендә кала.

Биредә шулай ук Гайнетдин Әхмәревнең милли тарих буенча язган, алда сүз булачак китапларының мәдрәсәләрдә дәреслек сыйфатында кулланылганына басым ясау да мөһим. Алай гына да түгел, Габдулла Тукай «Казан тарихы»ның аерым өлешләрен үзенең «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле хрестоматиясенә кертә.

МӘГЪРИФӘТЧЕ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Гайнетдин Әхмәревнең үзенең педагогик һәм гыйльми эшчәнлегенә бәйле рәвештә миссионерлар һәм татар китап-газеталарының цензорлары булган шәхесләр белән якыннан аралашуын әйтеп китү зарур. Бу Гайнетдин Әхмәревнең үз милләтенең күренекле улы булуын инкяр итми. Киресенчә Казанда эшләү чоры моның шулай икәнен раслау өчен күпсанлы дәлилләр бирә.

Учительнең сәяси карашлары турында мәгълүмат сакланмаган. Шулай да, башка рус теле укытучылары кебек үк, аның либерал карашлы шәхес булуы шик уятмый.

XX гасыр башында милли матбугат теле турындагы бәхәскә мөнәсәбәтле, ул, Гаяз Исхакыйга кушылып, ана телендә язуны һәм укытуны яклап чыга, Исмәгыйль Гаспралының уртак төрки тел турындагы фикеренә каршы була. Бу уңайдан язмалары аның «төрекче» түгел, «татарчы» булуын бик ачык күрсәтә.

Аның кайбер язмалары татар укучысына гыйлем-мәгълүмат җиткерү, мәгърифәт тарату буларак карала. Әйтик, 1906 елны басылган мәкаләләрендә газетаның һәм акчаның килеп чыгышы, бәрәңге игү тарихы турында гомуми мәгълүмат бирелә.

Инкыйлаб елларындагы сүз ирегеннән файдаланып, учитель яңа темаларга да мөрәҗәгать итә. Бу уңайдан, аның Алтын Урда дәүләтендә Рус православие чиркәвенең «полная автономия» шартларындагы иркен хокукый халәте («Диндә хөррият») һәм XIX гасырда бабалары диненә кайткан керәшен татарлары күргән җәбер-золым хакында («Мәкрүхлар хәленнән») язмаларын атап китү урынлы булыр. Автор мәкаләләрендә кайбер милли һәм дини тигезсезлек турында мисаллар китерә. Әйтик, 1836 елда миссионерлар котыртуы буенча язылган патша указын үтәп, Вятка губернасы Нократ төбәгендә Сабан туен бәйрәм итүне тыюы һәм XX гасыр башында да бу тәртипнең үз көчендә булуы, шулай ук XIX йөзнең урталарында Зөя өязендәге берничә татар авылында Җыен бәйрәме бетерелү хакында хәбәр итә. Ул кавемдәшләренең хәлен төрле яклап бәяли. Әйтик, мәктәп-мәдрәсә, мәчетләр белән училище, чиркәүләр көнкүрешен чагыштырып, соңгыларын җылыту өчен утынның бушка бирелүенә басым ясый; шул рәвешле игътибарны дәүләтнең аерым диннәргә өстенлек бирүенә юнәлтә.

Аның татар игенчеләре тормышына кагылышлы фикерләре дә игътибарга лаек. Әхмәрев баштан ук җир азлыктан интеккән крестьяннарны илнең башка төбәкләренә күчерүне күздә тоткан Столыпин реформасы мөселманнар арасында яклау тапмаячак, дип белдерә. Татар авылларында имана кишәрлеге җитми, урманнар юк һәм халык һөнәрләр белми, шуңа күрә татар авылы хәерче хәлдә яши, дип саный. Башка төбәкләргә китеп эшләү тискәре күренеш-гадәтләр таралуга сәбәп була, дип яза.

Әхмәрев 1896 елдан Казан губернасы рус, рус-татар уку йортлары укучылары һәм укытучыларына ярдәм оешмасында әгъза булып тора. Татар җәмгыятендә ул милли тарихны өйрәнүче күренекле галим һәм оештыручы буларак танылa. «Шәрык клубын» нигезләгән 12 зыялы шәхеснең берсе була. 1908 елдан бу иҗтимагый оешманың өлкәннәр советына, китапханә һәм фатир комиссияләренә сайлана. 1909 елда рәис урынбасары һәм лекцияләр уку комиссиясе әгъзасы була, ә 1910 елда рәис вазыйфасын башкара.

ЭТНОГРАФ ӘХМӘРЕВ

Гайнетдин Әхмәрев – татар тарихчылары арасында беренче булып рус телле тарихи әдәбиятны һәм чыганакларны киң кулланып эш иткән галим. Аны этнограф буларак таныткан өч күләмле хезмәте дә рус телендә дөнья күрә.

«О языке и народности мишарей» (1893) исемле мәкаләдә татар-мишәрләрнең яшәү ареалы, кәсепләре, киенү рәвешләре, торак пунктлары исемнәре, кулланылышта булган рус сүзләре һәм төрки архаизмнар хакында хәбәр ителә, сөйләм үзенчәлекләрен фонетик яктан бәяләп, телнең көнчыгыш төрки сөйләме, ә грамматик төзелеше татар теленеке кебек үк дигән күзәтү ясала. Шул рәвешле мишәрләрнең килеп чыгышын финнар белән бәйләү дөрес түгеллеге дәлилләнә. Автор, мишәрләрне Бату белән Азиядән килгән Алтын Урда күчмәннәренең варислары, дип саный. Тарихи әдәбиятта өстенлек иткән мишәрләрнең килеп чыгышы Мещера төбәге белән бәйле дигән фикерне әйтеп, бу теманы ныклап өйрәнәсе бар, дигән нәтиҗә чыгара.

Аның, Ризаэтдин Фәхретдин киңәшен тотып, Уфа губернасы Стәрлетамак өязе авылларында берничә ай яшәп һәм тарихи әдәбиятны тирәнтен өйрәнеп язган «Тептяри и их происхождение» (1908) исемле мәкаләсендә ясаган нәтиҗәләр

Гайнетдин Әхмәрев эшләгән Тәтеш рус-татар мәктәбе. XX гасыр башы фотосы.

бүгенге фән тарафыннан расланды. Казан ханлыгы җиңелгәннән соң, Идел-Чулман төбәгеннән чукындырудан һәм өстәмә салымнардан качып килгән этник төркемнәр башкорт җирләренә «припущенник» сыйфатында урнашкан. Әхмәрев «типтәр» сүзенең «дәфтәр» (ясак түләү турында исемлек – автор) дигән сүздән килеп чыкканлыгын әйтә. Галим типтәр сословиесенең өч этник төркемнән торганын ассызыклый: мөселман динендәге татарлар, мәҗүси марилар һәм удмуртлар. Шул рәвешле, «типтәр» дигән халык юк, дип белдерә.

«Свадебные обряды Казанских татар» (1907) исемле мәкаләсендә бик тәфсилләп татарларда өч өйләнү ысулы – кызны мәҗбүриләп урлау, кызның ризалыгы буенча урлау һәм яучы җибәреп туй ясау – тасвирлана. Әхмәрев фикеренчә, XX гасыр башында татарларның күпчелеге икенче ысулны кулланып өйләнгән. Автор шулай ук туганнар арасында никахлар, күпхатынлылык, аерылышу мәсьәләләренә күзәтү ясый. Мәкаләнең соңгы ике бүлегендә, мисаллар китереп, Карл Фукснең язмалары, артык тупас хаталар булмаса да, Казан шәһәрендәге татар туе хакында дөрес булмаган күзаллаулар тудыра, дигән фикерне әйтә.

БЕРЕНЧЕ ТАТАР АРХЕОЛОГЫ

Гайнетдиннең тарих белән кызыксынуы Татар укытучылар мәктәбендә укыганда ук башлана. Бирeдә тарих, география дәресләрен төбәк тарихын өйрәнүче Петр Траубенберг укыта.

Биектау авылында эшләгәндә Гайнетдин Әхмәревнең өч хезмәт язганы билгеле. Беренчесе – татарлар арасында иң бай алпавытлар булган Тәфкилевләр (XVIII гасыр), икенчесе Көбнә елгасы буендагы Болгар чоры Япанча шәһәрлеге турында. Өченче китапта автор, Шиһаб Мәрҗани язган ориентир буенча Кузнечиха авылы янында Суар шәһәрлеген өйрәнеп, аның шушы кала булуын археологик табылдыклар белән дәлилли. «Экскурсия на место древнего Сувара» исемле язмасы 1893 елда Казан университеты каршында эшләүче «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә дөнья күрә. Мәкалә авторы башта Җәмгыятькә - әгъза-хезмәткәр, ә 1904 елда тулы хокуклы әгъза итеп кабул ителә.

Әхмәрев эзләнүләрен комплекслы алып бара. Әйтик, 1894–1895 елларда Тәтеш, Спас өязләренә археологик һәм этнографик экспедицияләр ясый. Бу вакытта тарихи риваятьләр туплый, кабер ташларын өйрәнә, Шоңгаты шәһәрлеге урынын ачыклый, тарихи ядкәрләрне сатып алып, Җәмгыять музеена тапшыра. XIII–XIV гасыр мөселман кабер ташлары язуларын өйрәнеп, өч төркемгә бүлә: 1) Казан төркичәсендә язылган; 2) Казан төркичәсендә язылып, ахырында вафат булган елы һәм көне чувашча куелган; 3) тулысы белән гарәпчә язылган текстлар.

Шулай ук АТЭҖ тәкъдиме буенча 1909 елда Тау ягына ясалган экспедиция вакытында хәзерге Тәтеш районына кергән Богдашкино авылы янында Болгар чоры шәһәрлегенә юлыга. Соңрак галимнәр бу тарихи һәйкәлнең Ашлы каласы калдыклары икәнен ачыклый.

ӘХМӘРЕВНЕҢ ТАРИХИ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

Галимнең төп фәнни хезмәтләре булган «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» китапла-

ры 1908–1909 елларда «Шәрык клубы» утырышларында сөйләгән лекцияләре нигезендә языла.

Шиһабетдин Мәрҗани, татар халкы оешуда төп рольне Идел-Чулман төбәгендә яшәгән болгарлар һәм өлешчә күрше халыкларның мөселманлашкан өлеше уйнаган дисә, Әхмәрев, Казан һәм керәшен татарларын турыдан-туры Идел буе Болгар дәүләтен корган болгарларның варислары, дип саный.

Автор «Болгар тарихы» хезмәтен күптөрле чыганакларны анализлап яза. Беренче чиратта болгарларның диннәрен, гадәт-йолаларын, кәсеп-шөгыльләрен, күрше халыкларны өзек-өзек сурәтләгәндә Ибне Фазлан, Ибне Рөстә, Әбү Хәмид әл-Әндәсеми, Ибне Батутта кебек көнчыгыш сәяхәтчеләре язмаларына, Болгар шәһәрлегендә сакланып калган архитектура һәйкәлләренә (аларны гарәпләрнең биналарына охшата), археологик табышларга таянып тасвирлый. Болгар ханнары исемнәрен акчаларда сугылган атамалары буенча ачыклый. Болгар һәм славян/рус мөнәсәбәтләренә кагылышлы рус елъязмаларын тәнкыйди анализлап, татар-монгол яуларына кадәр һәм аннан соңгы дәвердә булган күпсанлы хәрби бәрелеш-сугышларның даталарын санап үтә. Ул Хисаметдин Мөслиминең Мәрҗани хәзрәтләре нык тәнкыйтьләгән «Тәварихы Болгария» исемле хезмәтен дә файдалана. Шул сәбәпле болгарлар ислам динен Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук кабул иткән булулары мөмкин, дигән сүзне әйтә. Шул ук вакытта Болгарны Аксак Тимер җимергән дигән версия белән килешми. Хәзерге татар авыллары янында ике зират булуны ислам кабул иткәнче һәм аннан соңгы көнкүреш ядкәрләре, дип аңлата. Шулай ук нәтиҗәләр ясаганда мисаллар буларак экспедицияләр вакытында үзе тапкан дистәдән артык кабер ташы язмаларын җәлеп итә, фәнни әйләнешкә кертә.

Галимнең күп кенә күтелмәгән тарихи нәтиҗәләре бар, аларның кайберләре бүген дә раслауны яки кире кагуны көтә. Тарихи риваятьләр, фольклор материаллары, шәхси күзәтүләре нигезендә, әйтик, Болгар дәүләтенең мәркәзе булган Тәтеш, Спас, Чистай өязләрендә чувашлар бөтенләй булмаган, алар төбәккә соң заманнарда күчкән, шул сәбәпле бу өязләрдә «Кушке» (күчмеш) исемендә авыллар бик күп, дип яза. Чувашларның килеп чыгышы турында төрле версияләр әйтә, «Болгар тарихы»нда аларның ерак бабаларын Тау ягындагы болгарлар белән хәзәрләр арасында көн күргән бортас кабиләләре белән бәйли (бу фикер фән тарафыннан расланмады). Шулай ук Болгар хәрабәләренә килеп зиярәт кылучылар нигездә Казан татарлары, ә башкорт һәм мишәр таифәләреннән килүчеләр бик сирәк, дип ассызыклый. Казан татарларының кайбер әйтем-гыйбарәләрен, тарихи фактлар белән беркетеп, Болгар чоры белән бәйләп куя.

Автор Җүкәтау, Болгар, Суар, Бүләр (Биләр), Кашан, Ашлы шәһәрләре, Тубылгытау кирмәне турында мәгълүмат бирә, Ибраһим кирмәне Түбән Новогород урынында, Тәтеш өязедәге Олуг Әтрәч авылы Шоңгыты шәһәре булган дип саный. Урыннары билгеле булмаган Тухчин, Саба Күл, Чалматы, Кирмәнчек шәһәрләре исемнәрен атый, Болгар дәүләтенең чикләрен үзе күргәнчә билгели.

«Казан тарихы» китабын автор бу вакытка тупланган барлык тарихи мәгълүматны һәм билгеле булган тарихи чыганакларны кулланып яза. Китапның структурасы зур булмаган һәм аерым темаларга багышланган 14 өлештән тора. Автор Казан татарлары – болгарларның дәвамчылары дигән фикерне үткәрә. Иске һәм Яңа Казан, Казан мәмләкәтенең чикләре, идарәсе, ханнары, халкының кәсебе, мәдәнияте һәм мәгърифәте, күрше мәмләкәтләр һәм кавемнәр белән мөнәсәбәтләре һ.б.лар хакында бәян итә.

«Үткән заманның хәленнән, ата-бабаларының вә падишаһларының тереклегеннән хәбәрдар булу – бик мактаулы сыйфаттыр. Тарих белгән кемсәләр артык тәҗрибәле вә тәдбирле булалар. Дөньяның һәр заманда булган вакыйгаларын, хәлләрен шул заманнарда көн иткән кеби белеп торалар. Тарих белмәгән кеше, үткән заманның хәленнән хәбәре булмагач, киләчәктәни булачагын аңламый, чөнки гыйбрәт алыр нәрсәсе һәм үлчәве юк. Бөтен галәмдә вакыйг булган әхвальне вакыт вә заманы белән бәйан итү тарихе гомуми вазифасыдыр» – «Ватан вә милләт тарихы хакында» (1906) исемле мәкаләсендә Гайнетдин Әхмәрев язган бу сүзләр бүген дә актуаль.

«Болгар тарихы» китабының тышлыгы.

«Казан тарихы» китабының тышлыгы.

ЗАКОННАР ЧЫГАРУ КЫРЫНДА

Идарәче таланты, тормыш тәҗрибәсе, законнарны шәп белү һәм какшамас әхлакый принциплар – менә шушы сыйфатлардан башка конструктив закон чыгару эшчәнлеген күз алдына да китереп булмый. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетын җитәкләүче Александр Тыгинда бу сыйфатларның барысы да бар.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Шәһәр төзелеше сәясәте, автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге, күпфатирлы йортларда капремонт оештыру һәм җәмәгать транспорты эшен көйләү... – Александр Васильевич Татарстан парламентында тәкъдим итеп, закон чыгару инициативасы чыганагына әйләнгән тармакларны санап китү генә дә аның иң катлаулы, иң мөһим социаль бурычларны хәл итүгә алынуы һәм осталыгы турында сөйли. Кагыйдә буларак, аның тирәнтен уйланылган закон чыгару инициативалары депутатларның күпчелегендә яклау таба һәм, нәтиҗәдә гамәлдәге закон статусына ирешеп, эзлекле рәвештә тормышка ашырыла. Нәкъ менә шундый законнар безнең тормышыбызны яхшырак, уңайлырак, мәгънәлерәк итә дә инде.

Александр Тыгинның тормышның үзәгеннән нәкъ менә шундый – парламентарийларның җентекле игътибарын, закон чыгару өлкәсендә конструктив һәм нәтиҗәле карарлар кабул итүне дәгъвалый торган тармакларны сайлап ала белү осталыгы кинәт кенә пәйда булмаган, билгеле. Дәүләт Советы комитеты җитәкчесе бәһаләп булмаслык тормыш тәҗрибәсенә ия. Биш ел буе хокук саклау органнарында закон сагында тугры хезмәт итү, республиканың төп министрлыкларында җаваплы урыннарда эшләү, ниһаять, Яшел Үзән районы хакимияте башлыгы һәм Яшел Үзән шәһәре мэры вазыйфасы – аның лаеклы хезмәт биографиясенең кайбер этаплары гына. Болар барысы да аңа татарстанлыларның ихтыяҗларын яхшылап өйрәнү, аларның тормышын яхшыртырлык эшләрне гамәлгә ашыру мөмкинлеген биргән.

Моннан берничә ел элек, ТР Дәүләт Советына сайлануга бәйле рәвештә Александр Васильевич район башлыгы вазыйфасыннан киткәндә, Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин: «Александр Васильевич Яшел Үзән районында 11 ел эшләде, шулардан 7 елга якынында хакимият башлыгы булды. Бу дәвердә хакимият районлагы тормышны яхшырту өчен уңышлы эшләде, шәһәр һәм районның тотрыклы икътисадый үсешен тәэмин итте», – дип йомгак ясады. Премьер-министрның мондый югары бәясе очраклы гына түгел, шулай ук Яшел Үзән халкы да район һәм шәһәрнең бу чорда яхшы якка гына үзгәрүеннән бик канәгать. Нәкъ менә бу елларда «Яшел Үзән» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (АСИҮТ) төзү буенча актив эш алып барылды, шәһәрдә «Безнең ишегалды» стандарты кабул ителде, ул йорт яны территорияләрен төзекләндерүгә старт бирде.

ТР Дәүләт Советында «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе урынбасары Александр Тыгин, киеренке закон чыгару эшчәнлеге белән беррәттән, социаль мәсьәләләрне хәл итү белән дә бүген дә актив шөгыльләнә. Аның җәмәгатьчелек белән конструктив диалог алып бару, иң кискен проблемаларны хәл итү осталыгы да гел кирәк булып тора. Ул Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тизйөрешле автомобиль юлының Татарстандагы участогы проектын җирле халык белән тикшерү буенча ТР Дәүләт Советында үткән түгәрәк өстәлләрнең модераторы булды, нәтиҗәдә ике якны да канәгатьләндерә торган вариант сайланды.

Александр Васильевичның тәҗрибәсе, белеме һәм аналитикага сәләтенең закон чыгару өлкәсендә әле күп еллар буе файдаланылачагында бернинди дә шик юк. Ул Татарстаныбызның гөрләп үсүе, халкыбыз тормышының яхшыруы өчен көчен кызганмый тырышачак.

Хөрмәтле Александр Васильевич!
Сезнең хезмәт эшчәнлегегез – республикага, аның халкына фидакарь хезмәт итү үрнәге ул. Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәм һәм закон чыгару инициативаларыгызның депутат коллегаларыгыз арасында һәрвакыт яклау табуын, эшчәнлегегезнең сайлаучыларыгызның тормыш сыйфатын тагын да яхшыртуга булышуын телим.

Фото: «Татэнерго» АҖ матбугат хезмәте

КӨЧЛЕ ШӘХЕС, БӘҺАСЕЗ ТӘҖРИБӘ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, республика парламентының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгинга май аенда 50 яшь тула. «Татарстан» журналы аны юбилее белән котлый.

Эдвард Абдуллаҗанов,
Казан дәүләт энергетика университеты ректоры

– Александр Васильевич Тыгин – мин белгән иң көчле һәм күпкырлы шәхесләрнең берсе. Аның бай тәҗрибәсе һәм тирән белеме Татарстанда иң җаваплы вазыйфаларда уңышлы җитәкче булырга мөмкинлек бирде.

Үзенең бөтен тормышы дәвамында ул дәүләт хезмәтенең алдынгы сафларында бара. Аның хезмәт юлында – Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары, Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары вазыйфалары, шулай ук Яшел Үзән мэры һәм Татарстанның иң әһәмиятле муниципаль районнарының берсендә хакимият башлыгы булып тору. Ул Яшел Үзән районында барлыгы 11 ел эшләде, шуның 7 елында район белән җитәкчелек итте. Бу чорда хакимият әлеге территориянең күп кенә мөһим тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен уңышлы хәл итте, шәһәр һәм районның тотрыклы икътисадый үсешенә иреште.

Александр Васильевичка һәр мәсьәләнең асылына төшенү сәләте, тиз һәм акыллы карарлар кабул итү осталыгы, ә иң мөһиме, профессионализм һәм башкалардан да шуны ук таләп итү хас. Аның бу сыйфатларына мин Татарстан Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетында бергә эшләгән вакытыбызда күп тапкыр инандым.

Практик эшчәнлекнең кыйммәтле тәҗрибәсе, республика төзелешенең төрле якларын белү, профильле – финанс һәм юридик белем сезгә, Александр Васильевич, Татарстанны социаль-икътисадый яктан үстерүдә масштаблы бурычларны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирә. Парламентарийларның нәтиҗәле синергиясен тәэмин итә алырлык идарә тәҗрибәсенә ия шәхеснең комитет белән җитәкчелек итүе без, комитет әгъзалары өчен, бик мөһим. Энергетика өлкәсендә җитештерүчеләрнең һәм бу тармакта белем бирүнең проблемаларын бик яхшы аңлавыгыз да гаять әһәмиятле.

– Александр Васильевич, сезне юбилеегыз белән котлап, бетмәс-төкәнмәс энергия, нык сәламәтлек һәм яңадан-яңа уңышлар телим!

Фото: КДЭУ матбугат хезмәте

ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ КАДЕРЛИБЕЗ, БАШЛАГАННЫ ДӘВАМ ИТӘБЕЗ, КИЛӘЧӘКНЕ ТӨЗИБЕЗ

Михаил Афанасьев,
Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы, Яшел Үзән мэры

Юбилей – һәр кеше тормышында яңа сәхифә ул. Ирешкәннәрне бәяли, киләчәккә максат-бурычлар куя торган вакыт.

Яшел Үзән районы республикада иң эре муниципалитетларның берсе, халык саны буенча бишенче урында тора. Территориябездә Серго һәм Горький исемендәге заводлар кебек оборона һәм сәнәгать тармагы предприятиеләре урнашкан, һәм алар тотрыклы эшли, «Зеленодольск», «М7», «Яшел Үзән» сәнәгать парклары үсеш алган, яңа җитештерүләр пәйда була. Ләкин, иң мөһиме, монда социаль яктан актив, тиктормас кешеләр яши һәм эшли. Алар кече Ватаннарын ихлас ярата. Бүген без элгәрләребез салган ныклы нигезгә таянып эш итәбез. Шундый шәхесләрнең берсе – Александр Васильевич Тыгин. Башкарма комитет җитәкчесе һәм муниципалитет башлыгы вазыйфаларында хезмәт иткән елларында ул районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертте.

Хөрмәтле Александр Васильевич!

– Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм! Сезгә бары тик уңышлар гына юлдаш булсын! Туачак һәр көн уңыш-казанышлар шатлыгы уятып, яңалары өчен бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман алып килсен. Сезгә нык сәламәтлек, иминлек телим!

Фото: tatar-inform; Яшел Үзән администрациясе матбугат хезмәте

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Где купить журнал «ТАТАРСТАН»
Редакция кухнясы
новое на сайте
Новости
Финансовая грамотность
Реклама 16+

БОРЫНГЫ ЯҢА ТИНЧӘЛЕ...



Фото: Александр Ефремов

ЯҢА ТИНЧӘЛЕ

Дүрт-биш ел элек кенә авыл уртасында чүп чокыры булган урында бүген күл тора. Аның тирә-ягы тотып алынган, шушы матурлык белән хозурланырга беседкалар да ясалган. Моннан тыш, авылда бик матур ял паркы да бар. Гадәти булмаган әлеге күңелле күренешне Буа районының Яңа Тинчәле авылында күреп кайттык. Аларны кем ясаган? Нинди акчага? Сораулар күп туды...

Руфия Фазылова

«ИГАНӘЧЕЛӘР КҮП»

Яңа Тинчәле – Буа районының иң матур авылларыннан берсе. Хәер, иң каралган дисәм, дөресрәк булыр. (Чөнки һәр авыл үзенчә матур бит.) Биредә урамнарга асфальт түшәлгән. Юл кырыйларына куаклар утыртылган. Ялгыш кына да бер җирдә аунап яткан әйбер күрмәдек.

– Берничә елдан бирле каралмаган, ишелеп бара торган нигезләрне үзсалым акчасына калай белән киртәләп алабыз, – ди Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы Радик Мадышев. – Ел саен берәр урамны карыйбыз. Әле андый урамнар шактый. Нишлисең, авылларда хәзер кеше яшәмәгән йортлар күп. Закон буенча, бик иске булса да, безнең аларга кагылырга хакыбыз юк. Менә шуның өчен киртәләп булса да алабыз.

Радик Мадышев безне авыл уртасындагы күлгә алып китте. Балык тотар, ял итәр өчен тимер беседкалар бар. Авыл халкы суга балык җибәргән.

– Элек монда кое булган, – диде авыл җирлеге башлыгы. – Әби-бабаларыбыз аннан су алган. Әмма ул кое ишелеп юкка чыккан. Без аны өлкәннәрдән сорашып, чыганагын таптык. Шуны казып, чишмә ясадык. Нәтиҗәдә, бүген бу урын – авылның күрке.

– Күлне үзсалым акчасына казыдыгызмы? – дим.

– Юк. Авылларны төзекләндерүгә юнәлтелгән махсус дәүләт программасы бар, без шунда эләктек. Иганәчеләр дә булышты. Бу халыкның яраткан урыны. Кичен монда гел кеше: коймак пешереп концертлар куялар, биешәләр. Бала-чага да күп була...

Күлнең янәшәсендәге ял паркын күреп янә гаҗәпкә калдык: сәхнәсе, уен мәйданчыклары, фонтаны булган заманча урын бу! Декоратив агачлар күп. Әчтәрәк исә шомырт, алмагачлар шау чәчәктә утыра. Шунда тукталып, быз-быз килгән бал кортларының тавышына эреп, ял итеп алдык. Биредә яшәүчеләр бу матурлыкны күрә, аңлыймы икән? (Мондый парклары түгел, юлы да булмаган күпме авыл бар бит!)

– Паркны нинди акчага ясадыгыз? – дип, әрсезләнеп сорыйм Радик Мадышевтан.

– Иганәчеләр акчасына. Әнә исемлеге тора, карый аласыз... Аллага шөкер, Яңа Тинчәледән танылган кешеләр күп чыккан. Министрыбыз да бар бит. (ТР финанс министры Радик Гайзатуллин шушы авылдан. – Авт. иск.)

Чынлап та, иганәчеләренең исемнәре, кемнең күпме акча биргәнлеге язып куелган. Берничә кеше 250 шәр мең сум, кайсылары 100 әр мең сум, кайберләре 30 ар мең сум, 5 әр мең сум... Тамчыдан күл җыелган. Паркны карау, чүптән арындыру исә авыл җирлеге, мәдәният йорты хезмәткәрләренең вазыйфасы икән.

Яңа Тинчәленең тагын бер матур, дөресрәге, изге җиренә тукталдык – авылның беренче мәчете урыны. Биредә яшәүче халыкның зур горурлыгы – Татарстанда иң борынгы мәчет Яңа Тинчәледә салынган. 1753 елда императрица Елизавета Петровна мәчет төзергә рөхсәт биргән. XVIII гасырда төзелгән мәчет совет чорында кадерсезләнеп юкка чыккан. Һәм ике гасыр вакыт үткәннән соң, аның урынын киртәләп, капкалап, гөмбәз ясап куйганнар. Алай гына да түгел, юкка чыккан мәчетнең таш нигезен җир астыннан казып алып, пыяла астына урнаштырганнар. Яңгыр да, кар да тими. Киләчәк буыннар өчен чын мирас ул!

...Мондый матурлыклар тудырылгач, авыл үсәргә тиеш кебек. Тик ни кызганыч, алай түгел – халык саны ел саен 20–25 кешегә кими икән.

– Шәһәргә китүчеләр байтак, өлкәнрәкләр вафат була, – диде авыл җирлеге башлыгы. – Бөтен шартлар тудырылган югыйсә, урта мәктәп тә бар. Тик быелдан тугызъеллыкка калыр дип көтелә. Эшлим дигән кешегә эш тә бар, ләкин авылдан китү ягын карый шул яшьләр. Бик кызганыч...

1
Дүрт-биш ел элек кенә авыл уртасында чүп чокыры булган урында бүген күл тора.

2
Күлнең янәшәсендәге ял паркын күреп янә гаҗәпкә калдык.

3
Борынгы мәчет урынын киртәләп, капкалап, гөмбәз ясап куйганнар.

4

– Үзләре теләмәсә, оланнарны җир эшенә якын да китерә алмыйсың, – ди Фәргать Сибгатуллов.

5

Яңа Тинчәлегә барганда, чәчү өсте иде.

ЯЗНЫҢ БЕР КӨНЕ ЕЛ ТУЙДЫРА

Яңа Тинчәледә 369 кеше яши, 232 хуҗалык бар. Мал асраучылар күп, ике көтү чыга, хуҗалыкларда савым сыеры - 178 баш. Тагын монда крестьян фермер хуҗалыклары киң җәелеп эшли, андыйлар унау. Нигездә алар игенчелек, үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Иң кечкенә фермерда 100 гектар җир булса, зурларында бер мең ярым гектарга якын җир исәпләнә.

Яңа Тинчәленең җирләре «Заря» агрофирмасына карый. Биредә аларның зур, заманча фермалары бар, анда 280 баш нәселле савым сыеры тора. Ә мөгезле эре терлек саны 800 гә якын. Авылның 18 кешесе фермада хезмәт куя.

– Агрофирмада бүгенге көндә авылдан 35 кеше эшли, – диде Радик Мадышев. – Үзебездә янгын сүндерү бүлекчәсе бар. Анда ике ир-ат эшли, хезмәт хакын «Заря» агрофирмасы түли. Ә янгын сүндерү машинасы авыл җирлегенеке. Кышын да, җәен дә машина, ут-күз була калса, һәрвакыт әзер тора.

Авылның үзенең тракторы да бар, аны 2020 елда үзсалым акчасына сатып алганнар. Кышын аның белән юллардагы карны эттерсәләр, җәен юл кырыйларын, зират тирәләрен чабалар.

– Баштарак үзсалымны 500 әр сумнан җыйдык, хәзер 300 сумга гына калдырдык, – дип дәвам итте авыл җирлеге башлыгы. – Иганәчеләр бар бит. Үзсалымны авыл җирлеге бинасына һәр кеше үзе китереп бирә, сорап йөргәнебез юк. Халык шундый бездә.

Яңа Тинчәлегә барганда, чәчү өсте иде. Шуңа да кызу эш барышын күрми калу дөрес булмас, дип уйлаштык. Ун фермер хуҗалыгыннан берсе Фәргать Сибгатулловныкы. Ул, авылда беренчеләрдән булып, 1991 елда ук пай җирләрен алып эшкәртә башлаган. Бүгенге көндә 1000 гектар җире бар. Аның бер өлеше

пай җирләре, бер өлеше дәүләттән арендага алынган, үзенә рәсмиләштергән җирләре дә бар.

– 1991 елда пай җирләрен аерып алу сирәк күренеш иде. Сез ничек бу адымга бардыгыз? – дидем Фәргать абыйга.

– Иптәш малай – Расыйх Мифтахетдинов үзенең пай җирләрен алган иде, мин аннан күрдем. Хәзер сөйләргә генә җиңел, башта нужа шулпасы күп эчтем – колхоз җир бирми интектерде. Хәтта чәчә башлаган җиремә үз техникасын кертте. Ләкин мин тиз генә бирешә торган кеше түгел – пай җиремне икенче кырдан бүлеп алдым. Иң начар җирне бирделәр шул чагында. Аннары инде дөньялар үзгәрде, мөмкинлек булган саен җирләрне арттырдым.

Утыз ел эчендә Фәргать абыйның тулы бер техника паркы барлыкка килгән. Егермеләп трактор-комбайны бар аның. Нигездә иген үстерә, чөгендер, көнбагыш чәчә. Ашлык сакларга амбарлар төзеткән. Кыскасы, фермер аягында нык басып тора.

Хуҗа кеше бүген дилбегәне ике улына тапшырган. Үзе исә, кырга чыгып, эш барышын гына күзәтеп йөри. Сирәк күренеш – егетләр икесе дә авылда калып, әтиләренең эшен дәвам иттерә. Юк, алар кыйммәтле машинага утырып, матур күлмәк киеп кенә йөрми, ә батырып эшли. Язгы чәчүне тулысынча үзләре башкарып чыга икән.

– Кешегә ышанмыйм, – дип елмайды Фәргать абый. – Монда туры чәчәргә кирәк, бигрәк тә чөгендер, көнбагышны. Комбайн белән дә шул ук хәл. Безнең малайлар кечкенәдән техника белән дус, шуңа күрә эш тәртибен беләләр. Дөресен генә әйткәндә, авылда аның хәзер эшләргә кешесе дә юк. Әнә, ярдәмгә, ашлама, орлык салып торырга яшьтиләрне чакырдым. Яшьләр юк, булганнары да эштә.

– Улларыгызны ничә яшьтән техникага утырттыгыз? – дим.

– Ун яшьләреннән. Башта минем белән утырып йөрделәр, аннары үзләре генә. Техниканы тиз оталар, ул яктан икесе дә сәләтле.

Ул да түгел, тракторы белән бер кат әйләнеп Фаил (өлкән уллары – авт.иск.) килеп җитте.

– Әтиегезнең уң кулы кайсыгыз? – дим Фаилгә.

– Икебез дә инде. Энем Илмир белән аерма өч кенә яшь, бергә үстек.

– Эшләп үстек, дип әйт. (Көлешәбез). Авылда калырга әтиегез тәкъдим иттеме?

– Мин ерак китмәдем дә, Буада укыдым. Ә менә энекәш Казан дәүләт энергетика университетын тәмамлады. Кулына диплом алгач, ул да кайтты. Хәер, студент чагында да җәй буе кырда эшләдек. Башка эшне карамадык та. Әти олыгая, моның кадәр җирне үзе генә эшкәртә алмый бит. Икебезнең дә гаиләбез бар.

– Үзләре теләмәсә, оланнарны җир эшенә якын да китерә алмыйсың, – дип сүзгә кушылды Фәргать абый. – Берсен дә мәҗбүриләмәдем, бары үз теләкләре. Кешегә эшләгәнче, үз-үзләренә хуҗа, шуны аңладылар. Ә мин менә хәзер шулай читтән күзәтеп кенә торам. Эш җайланды, Аллага шөкер...

АВЫЛНЫҢ АКЪӘБИСЕ

Авылның акъәбисе белән дә таныштык – Зәүҗия Төхфәтуллова ике дистә елдан артык Яңа Тинчәледә абыстай булып тора. Ашларда Коръән укый, мәетләрне озата. Аңа кадәр күп еллар авылның урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыткан. Хәләл җәфете дә укытучы булган. Ләкин яшьли кавышып, ике бала үстерешкән кадерле кешесе күптән вафат инде. Кызын да югалткан ана кеше. Бүген бөтен юанычы, таянычы – улы белән килене, оныклары. Алар Казанда гомер итә.

– Апамны үзебезгә алып килдем, икәү яшибез, – диде Зәүҗия апа. – Аның аяклары начар йөри. Сигез дистәне тутырсам да, Аллага шөкер, үзем йөрим әле, бакчада да эшлим, кош-кортларым, сарыкларым бар. Әнә шулар юаныч биреп тора. Улым белән киленем кайтып булыша: сарык йонын да алалар, башка эшләрдә дә ярдәм итәләр.

Зәүҗия апа тормышта күпне күргән: яп-яшь килеш урын өстендәге әнисен карап соңгы юлга озаткан. Соңрак исә югары белем алып, укытучы һөнәрен үзләштергән.

– Мәрхүм ирем мөгаллимнәр гаиләсеннән иде, – диде Зәүҗия апа. – Укытучы булуымны ул бик теләде. Мәктәптә яхшы укысам да, әнием авыргач, укый алмый калган идем.

6
Авылның акъэбисе белән дә таныштык – Зәүҗия Төхфәтуллова ике дистә елдан артык Яңа Тинчәледә абыстай булып тора.

Кияүгә чыккач исә тәвәккәлләдем, бер кулда китап, икенчесендә бала булды.

Зәүҗия апа авыл тарихын яхшы белә, музейны мәрхүм ире оештырган. Мәчет тарихыннан да хәбәрдар. Авылның акъәбисе Яңа Тинчәленең Чүпрәле районына караган чакларын да хәтерли.

– Мәктәпне тәмамлап, курсларда укып кайтканнан соң, колхозга бухгалтер булып эшкә кердем, – ди Зәүҗия апа. – Атаклы, миллионер колхоз иде, кәгазь эше дә күп булды. Документлар артыннан Чүпрәлегә барасы, кире як, ара да ерак – алтмыш чакрым. Ә Буага утыз биш чакрым гына, аннары, ул Казан юлы өстендә, станция дә бар бит. Гомуми җыелышта шушы теманы күтәреп, халык авылны Буа районына кертергә кирәк дигән фикергә килде. Шуны рәсмиләштереп, имза куйдырдылар. Төгәл елын хәзер әйтә алмыйм, 1970 нче еллар азагында Яңа Тинчәле шулай Буа районына күчте. Бар халык шуңа сөенде. Әмма Чүпрәле районы җитәкчеләре көенде – Иске Шәйморза белән безнең авылда гына бай колхозлар, калганнары ярлы иде. Ләкин ничек итсә иттек, Чүпрәледән аерылдык.

– Халык үткен булган сездә, – дим Зәүҗия апага.

– Үткен дә, белемле дә. Шуның өчен дә безнең авыл белән санлашканнар. Тирә-якның бөтен авылларыннан килеп безнең мәдрәсәдә укыганнар. Аннары, ул чагындагы колхоз рәисе Шәүкәт абыйның абруе зур иде – хәрби җитәкче. Сугышта бер аягын өздереп кайткан кеше. Аның сүзенә дә каршы килмәгәннәрдер дип уйлыйм.

ЙӨЗЛӘП КЕШЕ КОРЪӘН УКЫЙ

Яңа Тинчәледә бүген ике мәчет эшли. Берсе аның 1991 елда салынган, икенчесе – 2008 елда. Соңгысы бигрәк заманча – ике катлы, бөтен җире каралган. Ул «Рәүф» исемен йөртә. ТРның финанс министры Радик Гайзатуллин әтисе исеменә атап салдырган.

– Бу – Гайззатуллиннарның төп нигезе, – диде «Рәүф» мәчете имамы Илдар Шәрифҗанов. – Бер мәчеткә сыймый башлагач, Радик Рәүф улына мөрәҗәгать иттек: «Яңа мәчет салырга ният бар. Матди яктан азрак ярдәм итә алмассызмы?» – дидек. Ул каршы килмәде. Алай гына да түгел, Радик Рәүф улы, әнисе белән киңәшләшкәч, үзләренең төп нигезләренә мәчет салырга тәкъдим итте. Аны берничә ай эчендә сафка да бастырдылар. Быел мәчетнең унбиш еллыгы була, шул уңайдан Радик Рәүф улы гыйбадәтханәне яңадан төзекләндерде, Аллаһка мең шөкер.

Дингә тартылу авыл халкының канындадыр. Ике мәчеттә дә җомга саен егерме-утыз ир-ат була. Дүрт төркем хатын-кыз исә «Рәүф» мәчете каршындагы мәдрәсәгә укырга йөри. Авылның йөздән артык кешесе Коръәнне гарәпчә укый белә икән. Күбесенең дини белеме бар. Шуның белән бергә алар дөньялыкны да онытмый. Сокланырлык...

Буага баргач, ак көнләшү туа. (Көнләшүнең агы буламы икән?!) Беренчедән, кап-кара туфраклы җирләреннән көнләшү. Икенчедән, үз сүзен әйтергә курыкмаучы халкыннан. Өченчедән, бердәмлек сокландыра, алар бер-берсен бирми, ә киресенчә, тартырга, ярдәм итәргә тырыша. Яңа Тинчәлегә баргач та, тагын бер кат шуңа инандык.

7

2008 елда салынган заманча мәчет «Рәүф» исемен йөртә.



8

– Аллаһ йортын берничә ай эчендә сафка да бастырдылар, – ди мәчетнең имамы Илдар Шәрифҗанов.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Тинчәле – ак тәнле, укымышлы, зыялы кеше мәгънәсен белдерә, дип әйтә иде әти. Тинчәледә башка авылларга караганда гыйлем һәм мәгариф алда булып, күп авыллардан, күрше районнардан килеп шәкертләр укыган.

Авыл картлары, борынгы бабаларыбыз Татар Согыты авылыннан (хәзерге Чувашия Республикасы) күченеп килгән, дип сөйли иде. Казан ханлыгы алынгач, татарлар, яхшы җирләрен ташлап, бу якларга килеп урнашкан. Ул чакта бу җирләрдә чувашлар яшәгән. Ләкин алар татарларны яхшы кабул иткән, һәм ике милләт бик дус булып бергә гомер сөрә башлаган. Соңрак монда татарлар гына калган.

(Язучы Касыйм Бикколов истәлекләреннән)

ай кәефе: күтәренке

ЧӘЧӘКЛЕ ЯЗ...

Быелгы яз кебек язлар сирәк була. Апрель азагында ук чия-шомырт, алмагачлар чәчәккә күмелде. Бермәлне үзебезне көньякта яшәгәндәй хис иттек. Апрельдә үк күлмәктән йөр әле син! Май ае салкын булмасмы дигән борчулы уй бар иде, мең шөкер, маебыз да җылы, рәхәт. Быелгы яз матур гына түгел, гаҗәеп матур. Бер айдан бирле шау чәчәкле агач, куакларга карап әсәрләнәбез... Бу могҗизага һәркөн сөенәбез. Җиһанда, янәшәбездә озаграк тор, яз! Без Сине көттек! Без Сиңа гашыйк! Без Сиңа рәхмәтле!

Фото: Александр Ефремов



ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама